Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 16 (1432) 28 апрель 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

1995 елның июленнән башлап чыга

12

Төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең чираттагы конференциясендә катнашу максаты белән Белоруссиягә юл тоттык.

14

Акмулланың фаҗигале үлемен тикшерү күп кенә тарихи фактларны, шәхесләрне барлауга юл ача.



24

Рәссам Әнвәр Сәйфетдинов үз эшләрендә милли киемдәге хатын-кызларны сурәтләргә ярата.

Милләт аналары кулындадыр Ана телебезнең язмышы!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- 1 майга кадәр Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясына бушлай керергә мөмкин.

- Әфганстанда балалар өчен татар интернаты укытучысы Кари Мөхәммәд Хәсән Хәсәнзада Катарда Коръән укучыларның 36 илдән йөздән артык кеше катнашкан халыкара конкурсында җиңүче булды.

- «Мелодия» фирмасы җырчы, Татарстанның халык артисты Әлфия Авзалованың 1973 һәм 1981 елда яздырылган язмаларын берләштереп, альбом чыгарган.

- Ленинград өлкәсе Халыклар дуслыгы йортында бөек татар шагыйре Габдулла Тукай иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә узды.

- Мәскәүдә язучы һәм журналист Нәзифә Кәримова җитәкчелек иткән «Интеллектуал» татар клубы үзенең зур юбилеен билгеләп үтте.

- Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә узган «Гает моңы» бәйрәмендә «Рухи моң» фестиваль-бәйгесенә нәтиҗә ясалды.

- Яшь драматург Айдар Әхмәдиев Салих Сәйдәшев музее директоры итеп билгеләнде.

- 3 майда Казанда Мостай Кәрим повесте буенча төшерелгән «Ярлыкау» фильмының премьерасы була.

- «Былбыл» татар халык театры Санкт-Петербургның «Рыбацкий» мәдәният йортында француз язучысы Роберт Томның «8 хатын» пьесасын татар телендә сәхнәләштерә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Салават Фәтхетдинов, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты:

«Татарстанда яшәгән татарның кадерен белергә кирәк. Монда калган бит ул. Монда эшли, монда яши. Юк, без төкереп чыгып киткән татарның артыннан барабыз. Нәрсәгә кирәк ул? Мондагы татарның хәлен белик, монда яшәгәннекен!»

СЫНАМЫШЛАР

29 апрельдә күчереп утыртыр өчен (рассадага) кәбестә чәчү яхшы ● 30 апрельдә сәрви чәчәк атса, кыяр чәчәргә була ● Май салкын булса, игеннәр уңа ● Майда юеш булса, июньдә коры була ● 1 майда чөгендер һәм кишер чәчәләр ● Майда яңгырлар күп яуса, арыш уңар.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 09 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 14 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 05 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында төнлекнең якты вакыты **29 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **5 майда 15 сәгать 34 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

28 апрель – язучы Мин Гариф улы Шабайның тууына 110 ел (1913–1963).

29 апрель – Халыкара бию көне;

– актриса, Башкортстанның халык артисты Гөлчәчәк Тәбрис кызы Шәриповага 65 яшь (1958).

1 май – уйлап табучы галим, Советлар Союзында беренче компьютерларны эшләүчеләрнең берсе, техник фәннәр докторы, Сталин премиясе лауреаты Бәшир Исхәндәр улы Рәмиевнең тууына 105 ел (1918–1994);

– гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Дамир Әхмәт улы Илдаровка 75 яшь (1948).

3 май – Бөтендөнья матбугат иреге көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Апрель-майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 28, 29 апрель, 2 май.**

* * *

Газеттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(28 апрель – 5 май)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 8 нче көне

КӨН КАДАГЫНА

Илнур ЯРХӘМОВ,
тарихчы һәм политолог

Ят камыт кидерү тукталырмы?

Ут күршебез булган Башкортстанның байтак районнарында татар халкының гасырлар буе гомер кичерүен инкяр итү һаман дәвам итә. Хәтта инде рәсми чаралар үткәргән вакытларда да татар вәкилләрен башкортлаштырудан һич тарсынып тормыйлар.

Мисалга, ике ел чамасы элек кенә Благовар районы үзәге булган Языково авылында патша армиясендә генерал-майор дәрәҗәсенә ирешкән Хаҗиәхмәт Ишбулатовның 170 еллык юбилеена багышлап «Шәҗәрә бәйрәме» үткәрелгән иде. Аны «тиешле югарылыкта» уздыру өчен район башлыгы Марат Азаматовтан тыш, Уфа каласыннан Бөтендөнья башкорт корылтаеның башкарма комитет рәисе Галим Якупов, үзләрен фән эшлеклеләре дип санаучы Искәндәр Сәетбатталов белән Рафил Асылхуҗин килгән. Соңгыларның берсе – тел белгече, икенчесе фәлсәфәче саналса да, алар – «Башкорт ырулары тарихы» атлы уйдырма хезмәт тудыручылар, «ысын тарихчылар» булып йөри. Әле 20-30 еллар элек кенә башкорт милләтенең нигезен сигез ыру тәшкил итә, ошбу сан хәтта гербларында да урын алган иде, әмма Салават Хәмидуллин, И.Сәетбатталов, Р.Асылхуҗин «тырышлыгы» белән ырулар саны хәзер 40 тан артып китте...

Ә генерал Ишбулатовның асыл язмышына кайтсак, ул 1851 елда туган, 1866 елда Оренбургтагы Неплюев кадетлар корпусының азиатлар бүлегендә белем алган. Аның патша армиясендәге хезмәте 37 ел буе дәвам итә һәм 1908 елда генерал-майор дәрәҗәсендә отставкага китә. Әмма Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, 1915 елда 64 яшьлек генералны янә хәрби хезмәткә чакыралар. 1917 елгы февраль инкыйлабыннан соң ул Уфа губернасында Бәләбәй гарнизоны башлыгы итеп билгеләнә. 1918 елның 8 гыйнварында ул 1 нче мөселман укчы бригаданың командиры итеп тәгаенләнә, ләкин апрель аенда большевик комиссарлар бригаданы куып тараткач, хәзерге Благовар районындагы үзе үскән Үдрәкбаш авылына кайтып китә.

Әхмәтзәки Вәлиди үзе үк игълан иткән Кече Башкортстанны яклап калу өчен, мәҗбүриләп сугышчан полклар җыя башлаган атналар бу. Башкорт Үзәк Шурасы фәрманы буенча, Хаҗиәхмәт Ишбулатов та Башкорт гаскәре сафына чакырыла, аны 1918 елның 28 июлендә 1 нче башкорт пехота дивизиясе, ә бераздан Башкорт корпусы башлыгы итеп билгелиләр. Октябрь аенда Ишбулатов Башкорт гаскәрендә генерал-лейтенант дәрәҗәсенә үстерелә (Ә.Вәлиди үзе – полковник), 22 ноябрьдә Башкорт гаскәренең идарә башлыгы итеп билгеләнә. Ләкин патша армиясендә сугышчан тәҗрибә туплаган һәм 67 яшен тутырган генерал вакыйгалар агышын дөрес чамалагандыр, 1919 елның 14



РЕВИЗСКАЯ СКАЗКА.

1850 года ... дня, ...

Семьи.	МУЖЕСКІЙ ПОЛЪ.	По последней ревизіи состояло и после оной прибыло.	Изъ того числа выбыло.	Нынѣ на лицо.
№		Лѣта.	Когда именно.	Лѣта.
28.		49.		65.
		9.		25.
		6.		22.
		4.		20.
		1.		
				13.

февралендә ул Башкорт гаскәре белән бергә Кызыл армия ягына чыга һәм хезмәт итүдән туктый.

Милләте буенча Х.Ишбулатов – татар морзалары нәселеннән, аларның туган оясы – Үдрәкбаш авылы. Морза дәрәҗәсе үзе үк әлеге нәселнең татарлыгын раслый, чөнки башкортлар арасында бер генә шәхес тә андый дәрәҗәгә лаек булмаган, өстәвенә морзалык – ул тәнендә бөек Чыңгызхан каны йөртүеңне раслау. Ишбулатовларның татар булуы Башкортстан архивы белән дә раслана. Аннары хәтта Кече Башкортстанга нигез салучы Ә.Вәлиди шәхсән үзе дә «Истәлекләр» китабында: «Безнең армиягә татарлар арасыннан генерал Ишбулатов, полковник Бикмаев, бертуган Терегуловлар, Ильяс Алкин, Янбактин, Чанышев, Сөендеков кушылды һәм тугры хезмәт итте», – дип искә ала. Ишбулатовлар әле 1850 елгы 10 нчы җанисәп вакытында ук үзләрен татар дип таныта. Менә ул җанисәп кәгазьләрендә Ишбулатовлар теркәлгән бит.

Үз нәселенең тарихы белән кызыксынучы Филүсә Харис кызы Ишбулатова ерак бабаларының җепләрен архивлардан эзләп таба һәм «Үдрәкбаш: Ишбулат нәселе башлаган тарих» атлы китап чыгаруга да ирешә. Филүсә ханым үз нәселләренең бабасы булган Ишбулат Мәмәкевнің үз уллары Нәдер, Муса һәм Габделкәрим белән 1722 елда уздырылган ревизия вакытында ук Яубазы елгасы буенда, үзләре нигезләгән хуторда исәпкә алынуын һәм мишәр катламында саналуын раслый. 1917 елның яз һәм җәй айларында А.Керенский җитәкләгән Вакытлы хөкүмәт ашыгыч авыл хуҗалыгы исәбе үткәргәндә, генерал Х.Ишбулатов үзе тутырган карточкага «баш» дип язып куйса да, бу аның башкорт милләте түгел, ә башкорт катламында саналуын һәм зуррак җир мәйданына дәгъва итүен генә күрсәтә. Аннары ул «баш» дигән язу да карандаш белән генә язылган бит, аны «ата» милләтчеләрнең гаять оста итеп өстәве дә мөмкин.

Мондый шикне раслау өчен Благовар районында үткәрелгән җанисәп нәтиҗәләренә күз ату да җитә. Йә, санагыз. 1939 елда уздырылган җанисәп районда 21,7 мең татар һәм 4,7 мең башкорт гомер итүен ярып сала. Бу – районда яшәүчеләрнең 46 проценты – татар, 10 проценты башкорт дигән сүз.

Әмма 1959 елда инде татарларның саны ни өчендер 28 процентка гына кала, ә башкортлар күләме 35 процент чиген дә узып китә. 1970 елда татарлар саны 21 процентка кадәр кими, аның каруы башкортлар үре 46 процентка кадәр менеп җитә. 1979 елда татарлар – 23 процент, башкортлар – 45. Ә 1989 елда инде бары да киресенчә: татарлар – 60 %, ә башкортлар нибары 8 % кына. Бу – политбюро секретаре Егор Лихачев яман тәнкыйтьләп чыкканга күрә, элеккеге өлкә комитетның беренче секретаре, «сатлык татар» Мидхәт Шакиров кәнәфиеннән алып ташланганнан соң ирешелгән нәтиҗә. Ләкин аның урынына менеп утырган шундый ук милләтче Мортаза Рәхимов хәлне тиз «төзәтә», 2002 елда үткәрелгән җанисәптә Благовар районы буенча татарлар тагын 23 %ка гына калдырыла, ә башкортлар 48% үрен яулый. 2010 елда, югары кәнәфидә Рөстәм Хәмитов утырган вакытта да үзгәреш зур түгел: татарлар – 28%, башкортлар – 43.

Җәберләү һәм кимсетү монда гына да тукталмый. Шул ук ике ел элек үткәрелгән «Шәҗәрә бәйрәме» яки кичә-бүген оештырылган мәдәни чараларда, районнарга чит җирләрдән килгән кунакларны каршылау тантаналарына һәрчак диярлек фәкать башкорт киемнәренә генә төренгән хезмәткәрләрне тезеп бастыралар. Благоварда, Бүздәктә, Кушнаренко, тагын дистәләгән районнарда халыкның күпчелеге булып татар милләте вәкилләре яши, ләкин алар үз милли киемнәренә төренеп, кунакларны каршына чыгып күренә алмый. Пешергән ашлары да «башкортныкы», җыр вә көйләре дә «башкортныкы» икән.

Менә, Благовар районы мәдәният йортларында да элек дистәләгән татар коллективлары һәм татар ансамбльләре эшләп килә иде. Ә берничә ай элек район мәдәният йортындагы татар ансамбле вәкиле Элиза Шәфиеваны Башкорт корылтаеның шушы район бүлеге җитәкчесе итеп билгеләп куйганнар да, кичә генә «Энҗеләр» татар ансамбле әйдәп йөргән кыз күз ачып йомган арада «Әманәт» башкорт фольклоры ансамбле «башлыгы»на әверелде дә куйды. Һәм хәзер инде фестивальләрдә дә, кунаклар каршылаганда да сәхнәгә «башкортлар»ның «Әманәт» ансамбле генә чәчрәп чыга, татар мәдәниятчылары сәхнә артына этеп куелды, аларга сан бетте. Йөрәк әрни, ут күршебез булган башкортларның табигый байлыкларын да, елга булып аккан салымнарын да татар халкы килеп таламый бит, татар белән башкорт җирләрен һәм халкын да бер үк камчы изә. Ут туганнарыбыз кайчан шуны аерыр хәлгә килер икән?..

Тәкъдир таләбен хаклау

Таләпне указ, әмер яки законнар аша гына кабул итәргә күнеккән бәгъзеләр өчен бу язмага баш итеп куелган тема хәтта бераз сәеррәк тә күренергә мөмкин. Чөнки тәкъдир таләбе, чыннан да, башкачарак белдерелә. Әмма аны аңлау өчен, дөньяда һәм ил-көндә бара торган процессларга күзләрне (күңел күзен дә, чөнки, «Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге», ди мәкаль) зуррак ачып карап, Аллаһ биргән акылың белән, төплерәк итеп фикер йөртеп алу да җитә. Ә хәлләр хәзер көннән-көн катлаулана гына бара. Юкса, моның төп сәбәпләре һәм кыен хәлдән чыгуның бердәнбер вә универсаль юлы да инде күптәннән билгеле: абсолют кыйммәтләр системасына кучеп, илаһият кануннары буенча яши башлау. Ә ошбу изге эшнең бары тик Урталык җирләреннән генә башланып китә алуын һәм аны гамәлгә куюда үрнәк вә әйдәп баручы көч булу вазыйфасы татар халкына йөкләнүен, тарихи һәм илаһи фактларга таянып, үткән язмаларыбызда инде кат-кат та дәлилләгән идек. Шуңа күрә бу юлы төп игътибарны инсаният өчен үтә дә мөһим булган конкрет мәсьәлә – илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүнең метасәяси механизмнарын булдыруга бирербез.

Әүвәл, аның нигезе корыла торган реаль шартларны күрсәтик: бүген урнаштырыла торган яңа дөньяви тәртип, абсолют кыйммәтләр системасына күчүне дә, илаһият кануннары буенча яши башлауны да кузалламый һәм дөньяда әлегә бер генә дәүләт тә (ислам илләрен дә кертеп) үзенең эчке вә тышкы сәясәтендә метасәяси максатлар куймый; ни гаҗәп, андый максатлардан дөньякүләм танылган диннәр дә әлегә ерак тора, чөнки алар әле дә, асылда, геосәяси ниятләргә хезмәт итә (руханилары исә, илаһи кануннарга караганда, дәүләтнең эчке тәртипләренә буйсынып яшәүне өстен күрә); ә дөнья тотучылар үз мәнфәгатьләрендә һәм геосәяси нигездә үткәрә торган мәҗбүри глобальләштерү сәясәте бүген үзе дә глобаль кризис кичерә; тәкъдирдә язылганча барырга тиешле илаһи нигездәге глобальләшү процессы исә, мөшриклек диннәрендә әзерлек җитмәү сәбәпле, Хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын аңлап эш итүне көтә. Аңлашыла булыр, мондый шартларда инде илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте түбәннән югарыга (шәхес-мәхәллә-нәзарәт-өммәт-диннәр) таба үткәрелергә тиеш була. Мондый хәл исә, илаһи яшәешкә күчүнең метасәяси механизмнарын булдыру бурычының да, тәкъдири миссияле милләт буларак, татарга йөкләнүен аңлата.

Шөкер, моның өчен аңа метасәяси мөмкинлекләр дә мулдан бирелгән: ислам варисы буларак, хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы дәрәҗәсендә аңлау һәм аңлату сәләте; Урталык җирләрендә күп гасырлар дәвамында хакимлек итү һәм көчле дәүләтләр тоту тәҗрибәсе; татарның Урталык җирләрендә (үз тарихи ватанында) һәм бөтен дөнья буйлап таралып яшәве; милләтнең тәкъвалыгы һәм Аллаһ тарафыннан бирелгән асыл сыйфатларын гасырлар дәвамында саклап кала алуы; тупланып яшәгән төбәкләрендә аның мәхәлләләр корып яшәргә омтылуы; төрле төбәкләрдәге татар авылларының әле бүгенге кризис шартларында да (гомуми җимерeклек фонында!) булганлык, уңганлык вә тәкъвалык утравы булып калуы; Урталык җирләрендә кайчандыр күп гасырлар дәвамында табигый рәвештә милләтара аралашу чарасы булып хезмәт иткән татар теленең урыны әле бүген дә уңайлыгы ягыннан ЮНЕСКО исемлегендә дөньяның 14 теле арасында булуы; Тукай теленең төрки халыкларны берләштерә һәм изге эшләргә дә рухландыра торган иҗтиһат теле булып калуы һ.б. Метасәяси механизмнарда бу мөмкинлекләрнең нәтиҗәле кулланылуы лязем.

Гомумән алганда, метасәяси борылыш процессын ике этапка бүлеп карарга кирәктер: Урталык җирләрендә һәм ислам дәүләтләрендә илаһи яңарыш; глобаль метасәяси борылыш. Күргебезчә, ачыласы теманың шактый ук катлаулы булуы шәйләнә һәм, шуңа күрә, аңа инде аерым да тукталу таләп ителә. Әлегә сүзебезне метасәяси борылышның тәкъдир таләбе һәм кешелек цивилизациясенең алга таба Җирдә яшәү шарты да булуын искәртү белән чиклик. Ә метасәяси борылыш процессларының илаһи нигездә Урталык җирләреннән башлануы һәм алга куйган максатлары бу тарихи җирләрдә яшәүче барлык халыклар, шул исәптән бүген үз тарихында гаять кыен чор кичерә торган урыс халкы өчен дә отышлы. Чөнки яңа шартларда әлеге процесслар ул халыкларны уртак максат тирәсендә берләштерә һәм килочәкләрен дә ышанычлы итә, ул гына түгел, соңгы чорда геосәяси кризис нәтиҗәсендә барлыкка килгән бихисап һәм төрле дәрәҗәдәге проблемаларының универсаль чишелешен табу чаралары да булып тора. Метасәяси борылышның уңышлы тәгәлләнүе исә бары тик андагы халыкларның үзләреннән (аларның рух ныклыгыннан, тәкъвалыгыннан, үзоешу дәрәҗәсе, максатчанлыгы һәм тырышлыгыннан) торачак.

Фоат УРАЗАЙ.

Татарстан Республикасы Рәисе УКАЗЫ

2023 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссиянең 2023 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимнәрен карап, **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) Кумысникова Наилә Халит кызына – милли темага багышланган һәм күн мозаикасы техникасында башкарылган декоратив паннолар сериясе өчен;

2) Сибгатуллин Шәүкәт Гаделша улына (Шәүкәт Гаделшага) – «Аучы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Себерем – үз җирем» шигырь җыентыклары өчен;

3) Ханов Фирдәвес Гайнетҗан улына – архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә ватан һәм татар милли мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. МИҢНЕХАНОВ.
Казан, Кремль 2023 ел, 25 апрель, № 255

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татарстан Рәисе карары белән Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Флера Гыйззәтуллина һәм Наил Касыймовка «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде. Дәрәҗәле исемнең махсус билгесен Рөстәм Миңнеханов аларга шәхсән тапшырды.

Олимпиадага нәтиҗә ясалды

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә Татар теле һәм әдәбиятыннан халыкара олимпиаданың җиңүчеләрен бүләкләделәр.

Быел олимпиадада Татарстан Республикасыннан – 220, чит илләр (Казахстан, Кыргызстан, Азәрбайҗан, Үзбәкстан) укучылары һәм студентлары – 11 кеше; Россия Федерациясе төбәкләренең мәгариф оешмалары һәм мәктәпләреннән 8-11 сыйныф укучылары – 220 кеше, Татарстан Республикасы югары уку йортлары һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары студентлары – 49 кеше катнашты.

Олимпиаданың гран-при ияләре:

Азат Әхмәтҗанов, Казахстан Республикасы;

Ләйсән Галимова, Башкортстан Республикасы;

Ихтыяр Кыямов, Татарстан Республикасы.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Рәисе Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Казан мэры Илсур Метшин һ.б. шагыйрь Габдулла Тукайның Казандагы һәйкәленә чәчәкләр салды.

Җырларның үз тарихы

Казанның 5 нче музыка мәктәбендә Татарстанның атказанган сәнгать хезмәткәре, композитор Гөлнара Беляеваның «Халык энҗеләре» дигән концертында татар халык җырларының эшкәртмәләрен төрле уен коралларында уйнадылар. Пианино, балалайка, курай, скрипка, аккордеон өчен эшкәртмәләрне музыкант үзе эшләгән.

Концертта сирәк башкарыла торган җырлар да яңгырады. Г. Беляева «Актаныш басмалары» халык җырын табып, аны пианино өчен эшкәрткән. Аны укытучы, вокалист Гөлназ Абдусова башкарды. «Бу җырны 1952 елда Актаныш районы Бурсык авылында композитор, музыкант Җәүдәт Фәйзи язып ала. Җырның көе аның күз алдында туа. Музыка фольклорын җыеп йөргәндә ул яшьләр белән очраша. Яшьләр ишеткән-белгән җырларын җырлый. Фаягөл Нуркаева дигән кыз «Агыйдел басмалары»н җырлап күрсәтә һәм Җәүдәт Фәйзи аны шунда ук үзгәртерә, шунда булган Таҗи Гыйззәт «Актаныш басмалары» дигән исем белән атарга тәкъдим итә», – диде Г. Беляева.

Композитор «Галиябану» җырының тарихын да сөйләде: Җырны баштан «Сәгадәтбану» дип атаган булганнар. Аңа нигезләнеп, драматург Мирхәйдәр Фәйзи «Сәгадәтбану» дигән драма яза, ул 1917 елда Оренбургта куела. Пьесаны сәхнәгә куючы Вәлиулла Мортазин-Иманский тәкъдиме белән «Сәгадәтбану» исеме «Галиябану» дип үзгәртелә. Салих Сәйдәшев һәм Александр Ключарев спектакльгә оригиналь музыка язганнан соң, «Галиябану» беренче татар музыкаль драмасы булып санала башлый».

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

1 нче биттә – бу атнада Казанда узган III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съезды кунаклары. С. Кашапова фотосы.

Алар беренчеләр иде

Г.Камал театрының дирижер Данияр Соколов җитәкчелегендәге оркестры һәм артистлар бик кирәкле музыкаль мәгърифәтчелек эшенә кереште, моңа кадәр «Театр һәм музыка» шәлкеменнән олуг композиторыбыз Рөстәм Яхинга багышлап тулы концерт программасы әзерләгән булсалар, күптән түгел С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында «Алар беренчеләр иде» дип исемләнгән өр-яңа театральләштерелгән тамаша белән сөендерде. Аның беренче өлеше талантлы аһәңсаз Фәрит Яруллин һәм аның «Шүрәле» балетына багышланган булып, композиторның атасы Заһидулла ага һәм бертуганы Мирсәет Яруллиннар музыкасын да үз эченә алса, икенче бүлегендә спектакльләр өчен музыка һәм Р.Яхинның гаҗәеп нәфис романслары башкарылды. Музыкаль әсәрләр «Шүрәле» балетының иҗатителү тарихы һәм Фәрит Яруллинның тормышы турында мәгълүматлар белән үрелеп барды. Артистлар композиторның радиокомитетта эшләгән елларыннан күренеш тә уйнады. Бөек Ватан сугышына кадәр ук радиокомитетта симфоник оркест була һәм атнасына дүртәр концерт бирә. Сәхнә өстендәге экранда композиторларның портретлары күрсәтелде, башкарылган әсәрләр язылып барды.

Икенче бүлектә, тамашачы күзалдында 1920 еллардагы татар театры җанлангандай булды. Бер-бер артлы иҗат ителгән музыкаль драма, комедияләр халыкта зур популярлык казанганын беләбез. С.Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасыннан Батыржан һәм Гөлйөзем дуэтын төрле концертларда да башкара башлыйлар. Камал театрының концертында исә тамашачы аны Ришат Әхмәдуллин һәм Рәйхан Габдуллина башкаруында ишетте. Рәйхан Гөлйөзем ариясен башкарып та, бөтен тамашачыны таң калдырды. Мирсәй Әмир әсәре буенча куелган «Тормыш җыры» спектакленнән Басыйр җырын җырлаганда, артист Ирек Кашаповның да осталыгына сокланмый мөмкин түгел иде. Әйтергә кирәк, татар музыкаль драмалары халыкны симфониягә, ария, сюиталар тыңларга әзерләп кенә калмый, опера театрының нигез ташы була. 1939 елда ачылган опера театры 1956 елга кадәр академия театры белән бер бинада урнаша. Бүген опера театры җитәкчелеге, милли спектакльләр куюны онытып, Европада зур акча куып йөргәнче, үзенең чишмә башын, нигезен исенә төшерсен иде.

Р.Яхин романслары сирәк булса да, радиодан, концертларда ишетелә әле. Ә театр музыкасы, шушы концерта башкарылмаса, тыңлаучыларга тагын ничек барып ирешер иде икән? Әллә нинди матур музыкаль әсәрләребез бар икән ләбаса! Композитор Н.Җиһановның Н.Исәнбәт әсәре буенча куелган «Җирән чичән һәм Карачәч-сылу» спектакленә иҗат ителгән музыкасы, Р.Еникеевнең Нурихан Фәттах әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Кол Гали» драмасына язылган сюитасы шундыйлардан.

Г.Камал театры оркестры һәм артистлары башкарган бу концертларның әһәмияте әйтеп бетергесез зур, чөнки беренче профессиональ композиторларыбызның әсәрләре көннән-көн сирәгрәк яңгырый, милли җәүһәрләребезне ишетүдән мәхрүм булган яшь буын, татар гармуннан башканы белми, дигән ялгыш фикерне сеңдереп үсә.

15 майда С.Сәйдәшев исемендәге залда кабат Камал театры оркестрын ишетергә мөмкин булачак. Бу юлы күренекле артистыбыз Әсхәт Хисмәт, оркестрга кушылып, халык җырларын башкарачак.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Рәхмәт сүзе

70 яшьлек гомер бәйрәмемне республика күләмендәге әдәби-мәдәни чаралар кимәлендә билгеләп үтүләре уңаеннан, Татарстан Республикасы хөкүмәте, Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары, Актаныш муниципаль районы җитәкчелеге, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте карамагындагы «Казан утлары», «Мәдәни җомга», «Мәйдан» басмалары, ТНВ, «Татарстан» телерадиокомпанияләренә, Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте, С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концертлар залы иҗатчыларына, остазларыма һәм галимнәребезгә, «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию коллективына, мәдәни чараларда катнашкан барлык каләмдәшләремә һәм сәнгать осталарына чиксез рәхмәтләремне юллыйм. Дөньялар тыныч булып, һәрбарчабызга иминлектә бәрәкәттә гомер итәргә язсын.

Шагыйрь
Мөхәммәт МИРЗА.

«Сөембикә»гә 110 яшь

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Сөембикә» хатын-кызлар журналының 110 еллык юбилеена багышланган кичә узды. Чарада III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съезды делегатлары катнашты.

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев журналны бәйрәм белән котлады. «110 ел – бик зур җаваплылык. Беренчедән, коллективка рәхмәт әйтәм. Бай мирасны саклап, заманча, халыкчан булып эшләү – зур казаныш. Эш тиражда гына түгел. Мин моны беләм. Язылу башлангач, әни: «Улым, «Сөембикә»гә язылырга онытмадыңмы», – дип шалтырата. Ул журналны бөтен урам белән чиратлашып укыйлар. Журналның проектлары да җәлеп итә, бик җылы кайтавазлар килә», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлау сүзләрен җиткерде. «Сөембикә» зур дәрәҗәдә чыга торган басмаларның иң озын гомерлесе. Ул безнең гаиләдә дә – «әни журналы». Әнием 92 яшендә дә журналга тугры калды», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Камил Ногаев сүзләренчә, «Сөембикә» – халыкның иң яраткан журналы. «Азат хатын» журналын әниләр көтеп ала иде. Журналда сыер савучы, табиб, укытучы, зыялы хатыннар – барысы да бар иде. «Сөембикә» бу традицияне саклап калган. Мин Спас, Балтач, Сарман, Буа районнарында китапханәләргә кергәч: «Кайсы журналны укыйлар?» – дип сорыйм. «Сөембикә»не атыйлар», – ди депутат.

«Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков журналның татар халкы өчен мөһим роль башкаруын искәртте. «Күз алдына китерегез: 3-4 буын хатын-кыз шушы журналны укып, тәрбияләнеп үскән. Ул бүгенге татар милләтен барлыкка китерүдә төп корал булгандыр. Мисал өчен, минем гаиләдә өч буын хатын-кыз: әбием, әнием, тормыш иптәшем тәрбияләнгән. Хатын-кыз татар халкында төп рольне уйный, аның кулында һәрвакыт шушы журнал булган», – диде ул.

Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерү фонды башкарма директоры Нурия Һашимова да журналның тәрбияви ролен ассызыклады. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров журналның юбилее 10 ел элек тә Бөтендөнья татар хатын-кызлары корылтае кысаларында узуын искә алды. «Сөембикә» журналының аудиториясе затлы, зәвыклы, белемле, абруйлы, дәрәҗәле. Милләт язмышын чагылдырган журналларыбыз булу белән без бәхетле», – диде Д.Шакиров.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.

● Forbes журналы дөньяның иң бай кешеләре исемлеген бастырган. Анда быел беренче урынга Louis Vuitton Moët Hennessy хуҗасы француз Бернар Арно куелган, 74 яшьлек эшкуарның барлыгы 211 миллиард долларлык мөлкәте бар. Tesla һәм SpaceX хуҗасы 51 яшьлек Илон Маскның (АКШ) байлыгы былтыргыдан 39 миллиард долларга кимегән, һәм ул хәзер 180 миллиард долларлык мөлкәте белән икенче урынга куелган. Өченче урында – Amazon.com Интернет-кибете хуҗасы, 114 миллиард долларлык байлыкка ия 59 яшьлек Джефф Безос (АКШ).

● Дөньядагы иң бай 25 кеше барлыгы 2,1 триллион долларлык мөлкәткә хуҗа, бу былтыргыдан 200 миллиард долларга кимрәк. Быел планетабызда барлыгы 2640 миллиардер исәпләнә. Әлеге исемлеккә 105 россияле кертелгән, бу былтыргыдан 17 кешегә күбрәк. Россиянең иң бай өч кешесе: исемлектә 58 нче урынга Андрей Мельниченко ($25,2 млрд), 62 нче урынга Владимир Потанин ($23,7 млрд), 70 нче урынга Владимир Лисин ($22,1 млрд) куелган.

«КӨЗГЕ КАЙТАВАЗ»

яки Татарча сөйләшә беләсеңме?

Баланы кем күбрәк тәрбияләргә тиеш – ата-анамы, әби-бабаймы? Шәһәр шартларында баланы татарча сөйләшергә ничек өйрәтергә? Ата-анасы бер якта тормышның очын-очка ялгаган арада, әби-бабасы бүтән якта тормыш куган мәлдә, бала чит-ят мәдәният йогынтысына бирелмәсме, виртуаль дөньяга чумып, интернет киңлекләрендә югалмасмы? Мондый җитди сорауларны гадәттә зур күзлекле ханымнар, пеләш башлы әфәнделәр катнашындагы җитди фәнни-гамәли конференцияләрдә күтәреп тә, җавап таба алмыйлар. Бер көн исә әлеге мәсьәләләр тирәсендә режиссер Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелегендә Г.Камал театры артистлары эзләнде. Язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллинның пьесасы буенча куелган «Көзге кайтаваз» спектакленең премьерасы иде ул. Заман үзе алга сөргән сорауларга җавап табылды да кебек.

Иң элек шунысын әйтик: һәр татарның бәгырен телгән, милләт язмышын хәл итәрдәй мәсьәләләр хакында сүз барса да, спектакльдә берәүгә дә таш атмыйлар, берәүне дә кимсетмиләр. Юкса милләт мәсьәләләренең милләтебезне җитмешкә бүлгәне-аерганы, киңәшеп эшли белмәвебез күзалдыбызда. Спектакльнең исә дусларча шаяртуга корылган җиңел рухы күңелгә хуш килде.

Биредә кайтаваз ике төрле мәгънәгә ия: профессор Зөфәр Мөхәммәтовичның тормышында моннан 30 ел элек булган бер мәхәббәт тарихының яңаруы һәм фән дөньясына чумып гомерләрен уздырган карт белән карчыкның тормышларына бер авыз татар сүзе белмәүче бердәнбер оныкларының килеп керүе.

Әсәрдә телнең байлыгына, матурлыгына игътибар итмичә мөмкин түгел. «Хатынны һәм сыерны үлгәч кенә мактыйлар», «7 сендә ни булса, 70 ендә шул булыр», «Бала заманына охшар», «Ата-анасын тыңлаган – адәм булган, тыңламаган әрәм булган» һ.б. шундый мәкаль-әйтемнәр, гыйбарәләр байтак ишетелә.

Җиде яшьлек Азаматның бер авыз татар сүзе белмәвендә кем гаепле, дигән сорауга җавапны спектакльнең сценографиясеннән үк укырга мөмкин. Азу теше ярган сәхнә рәссамы Сергей Скоморохов һәрвакыттагыча анык итеп үз фикерен белдергән. Сәхнәдә гел аксыл, пастель төсләрдән һәм ике кеше озынлыгында аркылы-торкылы тезелгән китаплардан гыйбарәт галимнәр фатирын күрәбез. Рәссам төс ярдәмендә профессор ир белән хатынның аерымланган бер дөньяда яшәүләрен ассызыклаган. Биредә ник бер гаилә фотосурәте, улларының балачакларын хәтерләткән уенчык, йә булмаса бер милли бизәк булсын. Балаларга тел өйрәтү өчен исә үзеңнең филология фәннәре докторы булу гына җитми.

Тукта, нигә бөтен гаепне әби-баба җилкәсенә аударып калдырырга? Зөфәр Мөхәммәтович һәм Минзилә Зәкиевнаның ике улы Аваз һәм Азамат татар телен су урынына эчмимени? Профессорларның милләт алдында йөзләре ак, димәк. Шулаен-шулай да, алай ук түгел шул. Ник дигәндә, Аваз да, Азамат та телне авылдагы әби-бабасыннан, аларның әкиятләрен тыңлап, тәмле пәрәмәчләрен авыз итә-итә өйрәнгән. Әмма әби-бабай – еракта, профессор әти-әнисе исә һәрвакыт янәшәдә. Аваз һәм Азамат Зөфәр Мөхәммәтович һәм Минзилә Зәкиевнаның эшен дәвам итәргә тиеш түгел идемени? Галим булмаса, татар милләтенә файда китерердәй бүтән берәр һөнәрне үзләштерергә тиеш булгандыр алар. Сәүдә юлыннан китмәсә, Аваздан башка алыш-биреш итүчеләр беткән ди. Шулай да Аваз үз һөнәрен тапкан әле. Азамат исә 28 яшендә булса да, һаман тормышта үз сүзен әйтә алмый. Ни эше, ни хатыны юк. Бүген Оля, иртәгә Марина белән типтерә. Гаилә мәсьәләсендә милләт алдында җаваплылыгы Авазда да юк. Хатыны Глеб кызы Алина аңа татар балалары табып үстермәве көн кебек ачык лабаса! Болар гына җитмәгән иде: «Татар халкы – бетә торган халык, татар теле – юкка чыга торган тел», – дип, Азамат ачыктан-ачык ата-әнкәсенең гомерлек эшләрен бетереп ташлый.

Әтисе Аваз – сәүдәгә чумган, абыйсы Азамат татар теленә ясин укый, әби-бабасы китаптан аерыла алмый. Шуңа күрә җиде яшьлек Айваз әнисе Глеб кызы Алина тәрбиясендә сыек буынлы, чыпчык пырт иткәндә дә һушы китә торган чирләшкә булып үсә. Өй ризыгы ашамый. Пешерүче булса ашар иде, бәлки. Әмма Глеб кызы үзе дә пәрәмәч, кыстыбый түгел, тозлы кәбестә ашап үскәнгә охшап тора. Җиде яшьлек балага ризыкны – витаминнар, тормыш-чынбарлыкны виртуаль дөнья алыштырган. Менә шундый хәлдә Айваз әби-бабасы тормышына килеп керә.

Галимнәрнең пастель төсләрдән торган идеаль тормышын бозган журналист кыз Зөһрәнең иңнәрендә кызыл җилән күрәбез. Рәссам тагын төсләр белән уйный. Зөһрә профессор Зөфәр Мөхәммәтовичка моннан 30 ел элек булган мәхәббәт тарихын исенә төшерүче буларак сөю төсе – кызылдан киенгән. Азакта Зөһрәнең әнисе Разыяның муенына кып-кызыл мәрҗән тагуы һәм аягына кызыл туфли кидертүе белән сценограф яшьлек, мәхәббәт темасын көчәйтә төшкән. Разыяның башында нәни генә калфагы да булуы аны профессорлар гаиләсеннән аерып куя. Чыннан да, ирле-хатынлы профессорлар фән дөньясына чумып яшәгәндә, Разыя кызы Зөһрәне үзебезчә тәрбияләгән һәм бүген кыз татар телевидениесендә эшли, Зөфәр Мөхәммәтовичның гаиләсе турында тапшыру төшерергә дип килгән.

Тамашаның ахыры ничек булып бетә соң? Айваз виртуаль дөньясыннан чыгып, әби-бабасы белән авыз тутырып татарча сөйләшергә өйрәнәме? Өйрәнә! Ничекме? Анысын театр сөюче газета укучыларыбыз үзләре барып күрсен.

Уенын-чынын кушып әйткәндә исә, балаларыбызның телне белми үсүләрендә гаеп атта да, тәртәдә дә. Тел өйрәтүне гаиләгә генә кайтарып калдырсак, җәмгыятьтә ана телебезгә бернинди ихтыяҗ булмаса, татар балалар бакчалары, милли мәктәп, университетлар ачмасак, «Көзге кайтаваз» спектаклендәге Азамат кебек, милләткә ясин чыгарга гына кала. Әнә шундый җитди проблема күтәрсә дә, җиңел, шаян рухлы спектакльләр дә халыкны театрга җәлеп итәргә ярдәм итәчәк. Театрга килгән тамашачы исә телдән бизмәс, иншаллаһ.

Һәр гаиләдә телне өйрәтүнең үз ысуллары бардыр. Әлегә артистлар Фәнис Җиһанша, Эльза Моратхуҗина, Алмаз Гәрәев, Рәдиф Галимов, Гөлчәчәк Хәмәдинурова, Раил Шәмсуаров, Айгөл Хәйруллина, Алинә Мөдәррисова, Айгөл Абашева тәкъдим иткән рецептны кулланып карыйк! Спектакльдә Айвазның милләткә якынаюы музыка белән дә оста бирелгән. Аны тел белән аңлату мөмкин түгел, барып тыңларга кирәк. Музыкаль бизәлеш авторы исә – Йосыф Бикчәнтәев. Спектакльдәге милләткә файдалы шәхес тәрбияләү темасы аны сәхнәләштерүче аталы-уллы Фәрит һәм Йосыф Бикчәнтәевләр тандемы аркылы да ачыла...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Көлкеле күргәзмә юл уңаенда

Казанның Фестиваль бульварында, «Татмедиа» бинасы янында, «Чаян» сатира һәм юмор журналының йөз еллыгына багышланган «Еллар аша көлү» карикатуралар күргәзмәсе ачылды. Казанлылар һәм башкала кунаклары төрле еллардагы журнал тышлыкларыннан ике

дистәдән артык карикатураны күрә ала.

«Без журналның тарихын 1923 елдан алып бүгенге көнгә кадәр күрсәтергә тырыштык. Журналыбыз сәхифәләрен карап, илебезнең бөтен тарихын күрергә мөмкин. Республика безнең журналны тарих, традицияләр, мәдәни код итеп кабул итә», – диде күргәзмәне ачып, басманың баш мөхәррире Рафаэль Хәлилуллов. Ул илебездә башка юмор-сатира журналларының ябылуын, Татарстан җитәкчелегенең «Чаян»ны саклап калуын искә алды.

Башкала халкын һәм шәһәр кунакларын «Татмедиа» АҖ холдингы басмалары белән таныштыру һәм аларны ачык һавада күргәзмәләрдә күрсәтү хәзер традициягә әвереләчәк, дип вәгъдә итте «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков.

«Безнең газета һәм журналларның яхшы тарихи багажы бар. Бу джекпот, «Татмедиа» холдингында эшләүче һәркемнең бәхетле мөмкинлек билеты. Йөз ел – күз алдына китерәсезме, безнең ата-бабаларыбыз бит безгә нинди мирас калдырган?.. Безнең бурыч – кешеләр монда йөри, ял итә һәм басмаларыбызга соклана алсын өчен аларга якынрак бару», – диде Ш.Садыйков, холдинг урнашкан урынның бик уңайлылыгына игътибар юнәлтеп.

Сүз уңаеннан, сатирик журналда берничә дистә еллар элек дөнья күргән карикатураларның күбесе бүген дә актуальлеген югалтмаган, шуңа күрә алар халыкта кызыксыну уятмый калмас.

БӘЛӘБӘЙ ӨЯЗЕНДӘ БАШКОРТЛАШТЫРЫЛГАН АВЫЛЛАР

Патшалар фәрманы буенча, Уфа өязендә «башкорт катламы»на язылган крестьяннарга 40-60 шар дисәтинә имана җирләрен бүлеп бирү, әлбәттә инде, зирәк татар старшиналарын һәм крестьяннарын да кызыл чүпрәк урынына кызыктырып тора. Башкорт вотчинникларыннан ким яшәмәскә омтылган татар крестьяннары нинди ысул белән булса да «башкорт» катламына күпләп күчә башлый. Уфа өязенең үз эчендә генә түгел, ә «чит җирдә» – Казан өязендә яшәгән крестьяннар да ут күрше янәшәсенә күчеп, зуррак мәйданда имана җирләре эләктерә. Әлеге адым соңыннан галимнәр һәм милләтчеләр арасында кайнар бәхәс тудырмыйча калмый.

Менә Ә.Әсфәндияровның 7 нче ревизия үткәрелгән 1816 елдагы тарихи документны үзенчә боргалавына ачык мисал: «Атнагол (Туймазы районында) 1920 елда типтәр һәм татарлар яшәгән авыл буларак җанисәпкә алына. Ләкин анда 1815 елгы Манифест буенча беркетелгән башкорт типтәрләре дә яшәгән бит. 1816 елгы җанисәптә Мөхәммәтшәрип Ярмәкев, Исмәгыйль Әбҗәлилов, Йосыф Мөхәммәдияров, Габделгаффар Сәйфуллин, Миңлебай Батыршин нәкъ шул катламда саналган».

Иң әүвәл, Ә.Әсфәндияровның 1920 ел җанисәп документларыннан гел кыек-гаеп эзләргә маташуын исебездә тотыйк. Ул бу юлы да Атнагол авылында «башкорт типтәрләре» санап үтелмәгәнгә власть ияләрен гаепләмәкче була. Хәзер аңа каршы Уфа галиме М.Родновның шушы Атнагол авылы турында 1920 ел мәгълүматларын ни рәвешле санап чыгуын күрсәтик: «Авылдагы 201 хуҗалыкта 1028 кеше яши, аларның 664 е – татар, 28 е – рус, 10 ысы – мещан.» Шуларга өстәп, ул әле «татар типтәрләре», «дәүләт татарлары», ягъни ясаклы татар категорияләрен дә өсти һәм «10 карточкада «башкорт типтәрләре» төркеме дә язылган», дип ачыклый. Мәгълүм ки, большевиклар тарафыннан катламнарга бүлеп санау кискен туктатыла, шулай да 1926 елгы җанисәп кәгазьләрендә өлешчә генә барыбер сакланыла. Ә 1939 ел мәгълүматларында бөтенләй искә алынмый.

Ә.Әсфәндияров үз китабында «чит ил башкортлары» дип телгә алган төркем турында да сүз кузгата бит, ә алары – әсирлеккә эләккән чит ил хәрбиләре. Мисалга, Бәләбәй өязенең Катай авылындагы әсир булып калган һәм шушы авылга килеп төпләнергә мәҗбүр булган кыргызларны, төрекләрне дә «башкорт» катламына язып куйганнар. Ә Атнагол авылында менә элек «башкорт типтәрләре» булып йөргән крестьяннарны да 1859 елгы җанисәптә «асаба башкорт» итеп яза башлаганнар. Бертуган Дәүләтбай һәм Өмәрбай Мөхәммәтҗановлар, уллары белән бергә Җиһанша Җиһангиров – җәмгысы 10 кеше әле Атнагол, әле Ярмөхәммәт авылына беркетелгән «башкорт» булып киткән.

Мишәрләр белән дә шулай. Әсфәндияров бүген Ярмәкәй районында исәпләнүче Әбделкәрим авылы турында болай яза: «1809 елгы килешү буенча Байлар волосте башкортлары 17 хуҗалыктагы мишәр һәм типтәрләрне үз җиренә кертә. Килешү кәгазен мулла Садыршаһит Гомәров һәм типтәр Ярмөхәммәт Кузеев кулына тапшыралар. Ясаклы Хәбибулла Габделкәримов һәм казна крестьяннары булган Габделмәҗит Габбасов белән Байбак Кормашев ел саен һәр хуҗалыктан 10 ар тиен акча түләп барырга тиеш була». Әмма 1816 елгы җанисәптә үк мишәр мулласы С.Гомәров «башкортлар» исемлегенә беренче итеп язып куела. Элек 5 нче мишәр кантонында исәпләнгән аның күршесе дә, бар гаиләсе белән, ә барлыгы 15 кеше моннан ары «башкорт» булып йөри башлый.

Мишәрләр, гомумән, «башкортлар» сафына бик еш, күпләп күчә. Мисалга, 4 нче мишәр кантонындагы 70 яшьлек Рәхмәтулла Габдуллин 1814 елда үзенең уллары, киленнәре, оныклары белән хәзерге Бүздәк районындагы Кәпәй-Күбәү авылына, 8 нче «башкорт» кантоны составына күчерелә һәм шушы 13 кеше 21 нче башкорт кантоны «башкортлары»на әверелә.

Сыерыштыбаш авылында (Чакмагыш) яшәгән Бикташ Габделкасыймов 1815 елда Оренбургның хәрби губернаторы Г.Волконский фәрманы буенча Уфа өязендәге Мәмәк авылына күчерелә һәм 1834 елгы җанисәптә үк «башкорт» булып языла, ләкин никтер фамилиясе Касаевка әйләнә. Нәкъ шул ук фәрман буенча һәм шул ук елда Күбәү-Бигәнәш авылын да Шәмигол Биккенин атлы «башкорт» тулыландыра.

«Өстенлекле башкорт» катламын тулыландыру өчен атаклы татар алпавытлары Тәфкилевлар да үз өлешен кертә. Ул Килем авылында үзенең шәхси коллары саналган Мөхәммәтәмин Ишкинин, Гомәр Сөешев һәм Мөэмин Якуповны балалары белән бергә (барлыгы 9 кеше) иреккә җибәрә һәм алар Г.Волконский фәрманы буенча 1815 елдан соң 8 нче башкорт кантоны «башкортлары» булып исәпләнә башлый.

Күргәнсездер, бер 1811-1815 еллар арасында гына да кешеләре мишәрлектән «башкорт» катламына күчерелгән Атнагол, Әбделкәрим, Кәпәй-Күбәү, Күбәү-Бигәнәш, Килем, Сыерышбаш авылларын санап чыктык. Мишәрләр, татарлар, типтәрләр һәм хәтта хәрби әсирләр хисабына да «башкорт» халкының санын арттыру XIX гасыр буе дәвам итә. Әле без бер Бәләбәй өязен генә санадык бит, ә Оренбург губернасының башка өязләрендә дә нәкъ шушы рәвешчә «башкортлаштыру» сәясәте бер дә туктамаган.

Йомгаклар алдыннан, бүгенге Туймазы районындагы Кәлшәле авылына тукталыйк. 1816 елгы җанисәптә указлы мулла Тәминдар Гомәров, есаул Шәфи Гомәров, азанчы Габдрахман Әлмөхәммәтов, тагын берничә гаилә – барлыгы 12 хуҗалыктагы 64 кеше «башкорт» булып исәпкә алына. Гәрчә алар 1814 елда гына 5 нче мишәр кантоныннан 12 нче «башкорт» кантонына күчерелгән була. Алар Бөгелмә өязе документларында да «12 нче башкорт кантонына күчерелгән мишәрләр», дип телгә алына. Ләкин ни сәбәпледер күчмәннәргә «асаба башкорт»ка әверелү бәхете эләкми һәм алар 1834 елгы җанисәптә инде янә мишәрләр булып теркәлә. Дөрес, 1859 елгы җанисәп документлары буенча, Кәлшәледә мишәрләр дә, типтәрләр дә яши – барлыгы 501 кеше.

Әсфәндияров үзенең 744 битле «История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий» китабында да хәрәмләшүдән качып кала алмый. Кәлшәле авылы буенча да 1834 елда исәпкә алынган мишәрләрне күрсәтми. Шушы ук ялганы соңыннан «История башкирских родов. Канглы» китабына да һичбер үзгәрешсез көе күчерәләр. Шуңа күрә Уфа галимнәре язган яисә укучыларга «төрткән» «Башкорт авыллары тарихы»н да фәнни, лаеклы һәм гадел тарихи хезмәт, дип бәяләп булмый.

Таһир КӘРИМОВ,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

Чыганаклар:

1. Асфандияров А.З. История сел и деревень Башкортостана и сопредельных территорий. Уфа, 2009.
2. История башкирских родов. Канглы. Том 5. Уфа, 2014.
3. НА РБ. Ф. И-138. Оп. 2. Д. 151, 152, 156, 456, 515, 734, 735 а,в.
4. Роднов М.И.Крестьянство Белебеевского уезда по переписи 1920 года: этнический состав. Москва, 2009.

Мәхмүт ХӨСӘЕН

Аермагыз әни сөтен, Әни телен бәбидән!..

(Танылган шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең туына 100 ел)

* * *

Ватан миңа –
Курай моңы,
чишмә җыры,
Кузгалаклар тулы үзәнлек.
Ул – көмеш күл,
толымлы тал,
кара урман,–
Туган яктагы бар гүзәллек.

Ватан миңа –
Ерак болгар бабаларым,
Нигез ташын салучылар Казанымның,
Саклап калучылар канлы сугышларда
Аязлыгын,
ямен Ирек язларының.
Ватан миңа –
Яшьнәү,
яну,
хәләл хезмәт;
Эштә маңгай тирең сеңгән
фидакарьлек.
Кояш тулы мөстәкыйль ил киңлекләре,
Үз язмышын үз кулына алган халык.

ТАУЛАРЫГЫЗ ШАҺИТ

Шәһри Казан белән Кырым бүген
Көрештеләр Кара диңгездә,
Бәгърегезне телгән гарьлек хисен
Бүлешергә килдем мин сезгә.

Ипи-тоз вә якты йөз белән сез
Туганнарча каршы алдыгыз.
Сездән башка Кырым ятим иде,
Өзгәләнде шуңа җаныгыз.

Тауларыгыз шаһит:
Очраштык без
Йөзне куеп тозлы җилләргә.
Ихлас котлыйм кайтуыгыз белән
Мәңге газиз туган җирләргә.

Ата-баба туфрагыннан сезне
Бүтән йолып кем дә аталмас!
Идел белән Кара диңгез –
Рухи игез,
Казан белән Кырым – ватандаш.

УЛ БЕР ГЕНӘ

Туган тел газиз анадай –
Күпер рухи дөньяңа.
Иманың камил сакланса,
Кунмый һичбер кер аңа –
Ул һәрвакыт өр-яңа!..

Әни – туган телебездә
Иң тансык сүз балага.
Үз телендә әйтелмәсә,
Әверелә ярага.
Яралый ул иманыңны,
Язмышыңны яралый.
Җуя җаның кешелеген
Һичбер нигә карамый.
Газиз баласын чын ана
Мәхрүм итми теленнән.

Тел, аның күкрәк сөтедәй,
Изге туган көненнән.
Тел җуйган –
Иман гөлләнең
Өзелеп төшкән чәчәге...
Бүгенгесе аның ятим,
Юк аның киләчәге.

Бәбине, тел ачылуга,
Аермагыз әнидән.
Аермагыз әни сөтен,
Әни телен бәбидән!..

ЯНУ

Җирне күмеп алтын көшелләргә,
Кинәндерә илне кешеләр.
Ә шагыйрьләр җирдә кешеләргә
Бүләк итә рухи энҗеләр.
Мин дә шагыйрь.
Гомер буе, димәк,
Каләм белән кое казыла.
Бел, укучым: янса гына йөрәк,
Илһамланса гына языла.
Мине шагыйрь иткән изге илгә
Акыл көчем фида, вөҗданым.
Шәп җыр язсам, Туган ил сөенә,
Төн чигенә, тетри дошманым.
Яз һәм яшьлек җырда алып килəм
Туган җиргә, газиз халкыма.
Туар көннең урләренә җиләм
Атланып мин заман атына!
Тик кызганыч:
Гел атыла туплар!..
Тыныч йоклый алмыйм һаман мин.
Сугышларсыз көн хакына, дуслар,
Гомер буе ихлас янам мин.
Янам!..

ЯКТЫ МОҢ

Җибәргәнсең бик үтенгәч.
Көткәч,
Ике рәсем салып хатыңа:
«Унҗидедә чагым»...
«Җитмеш яшем җиткәч»...
Дип язылган рәсем артына.

Күргәч синең аксыл чәчләреңне,
Күзгә кырдан шәрә пәләшем
Түбәтәен җәһәт башка элде,
Тиз таныды тиңен, күрәсең.

Яшен утына тиң карашыңнан
Әллә нишләп китте йөрәгем...
Арынып ул гыйшык ярасыннан,
Сиздә кебек яшьлек егәрен.

Тонып барган күзләр ялкынланды,
Сүзсез калды аек акылым...
Хәтеремдә тәүге яр җанланды,
Биләп алды җанны якты моң!..

ҖИР КУНАГЫ

Кырпак карлар, гүя, җир өстенә
Каз йонынан ястык түшәгән!
Шул түшәктә йолдызлар ял итә
Төшеп төнлә зәңгәр түшәмнән...
Бик тә ямьсез булыр иде дөнья,
Кышлар килеп карлар яумаса...
Кырпак карлар кебек без дә җирдә
Вакытлыча кунак лабаса!..

ДИҢГЕЗ ИСЕ КИЛӘ КАРЛАРДАН

Бездә хәзер кырпак карлар ява:
Кара төсе җирнең агарган...
Куыра кыш җиле...
Күңелдә – яз!
Диңгез исе килә карлардан.
Җанга якын булсаң да син, диңгез,
Шактый ерак безнең аралар.
Буран купкан мәлне
Телә арган тәнне
Сугышларда алган яралар!..
Рәхәт иде җәен,
Диңгез офыгында
Җылы таңнар аткач сызылып,
Онытыла иде бар яралар
Яткан чакта комда кызынып.
Ә хәзер кыш бездә:
Оча карлар...
Усал җилләр исә сызгырып...
Мин утырам өйдә, мич кырында
Япь-яшь җырчыларның, яшел
чыршыларның
Сүнмәс яшьлегенә кызыгып...

КӘЛӘПҮШЕМ

Нишләп әле син кәләпүш киден:
Әллә уең мулла булумы?
Милләтчеләр михрабына таба
Борасыңмы әллә юлыңны?
Дорфа дәшеп шулай,
Саруымны
Юри кайнатасың шикелле.
Уйлап сөйләш, зинһар,
Такма миңа
Тамырыннан ялгыш фикерне.
Гомер сөрәм Идел туфрагында,
Ил өчен ут кичтем җитмәсә.
«Милләтченең хәтта «м» хәрефе
Ят бер аваз миңа, чит нәрсә.
Юл маягым минем – аяз таңнар,
Туган телем – кыйблам, иманым.
Тулы канлы татар кешесе мин
Бөтен төбәгендә дөньяның.
Кәләпүшле кыяфәтем белән
Милли булып алга басканда,
Җаным-тәнем белән мөселман мин
Кайнап торган тормыш-дастанда.
Баш заманча, гел яңача уйлый
Асыл кәләпүшем астында...
Ә кәләпүш кию – күркәм гадәт
Борынгыдан татар халкында.
Бүгенгебез аша карыйк та,
Күз төшерик милли тарихка.
Күр Апушны:
Бәрхет кәләпүшле...
Әле зуп-зур Тукай булгач та,
Ихтирамлап аны,
Кырын салып,
Горурланып йөрткән ул башта.
Кәләпүшем, димәк, Тукай төсе,
«Тәфтиләү»ем, «Әллүки»ем ул.
Мәрҗаниләр, Гаяз Исхакыйлар,
Кариевлар кигән кием ул.
Кәләпүшем – милли баш киеме,
Халык өлгесе ул, ил заты.
Ата-баба истәлеге итеп
Саклый аны татар ир-аты,
Халык өлгесе ул, ил заты.

СҮНМӘС ЯШЬЛЕК

Дәрман бирдең, яшьлек,
Давылларны,
Ябырылган ауны җиңәргә,
Давыл түгел, ярсу дәрьялар да
Тиң килəлми синең җегәргә.

Хисең белән, яшьлек, мин дә яндым
Мин дә сөйдем, мин дә көнләдем.
Дәртең белән уттан исән чыктым,
Текә кыяларга үрләдем.

Пәрәвезен сала биткә еллар,
Тоныклана төшә хәтер дә...
Ә шулай да какшадым дип йөрәк,
Картайдым дип кыймый әйтергә!

ВАКЫТ ТУКТАМЫЙ!

Мизгелләрне генә түгел,
Гасырларны коча Вакыт.
Кирәк чакта ул туктасын иде...
Юк, туктамый!
Оча Вакыт,
Иңнәреңдә заман йөген тартып!
Вакытка ук атып, туп атып
Караса да дөнья,
Ул гел оча –
Берничек тә булмый туктатып.
Безгә насыйп газиз мизгелләрне
Агызабыз суга кайчакта...
Вакытның һич аңа исе китми,
Үлем белән ялгыз калсак та...
Ул гел оча!..
Ирегәнә баш буларак кеше,
Вакытны бар дип тә белми – санламый...
Вакыт серен өйрәнмичә ныклап,
Үз эшенең күплегенә сылтап,
Яшәү асылын ул аңламый.
Ашыкса да һаман каядыр,
Вакыты гел җитми каладыр.
Ә ник өйрәнмибез
Вакытның без очу серләрен?!
Ашыгабыз, кулдан ычкындырып
Әхлакый аң, иман йөгәнен.
Кеше килә Җиргә,
Яши...
Аннан китә.
Ә киткәнче иҗат итә.
Ашыга ул тизрәк яулар өчен
Тәхет түрен, текә бәхет ярын...
Ашкынмыйк без,
Ашыкмыйк без гүргә,
Онытмыйк без җирдә ләхет барын.
«Яманның түрендә булганчы,
Яхшының гүрендә булыйк».
Без онытмыйк:
Кеше тик бер туа,
Тик бер тына аның йөрәге...
Үлгән җанны, юк, терелтә алмый
Ни табибләр, ни таң җилләре...
Ә Вакыт гел оча...
Оча-а-а!!!

* * *

Мәңгелеккә, зинһар, табынма,
Әҗәл яуу һәрбер минутта.
Тормыш дигән олы табында
Кунак икәнеңне онытма.
Кунак йорты сана җирне дә,
Канәгать бул аның сыена.
Өтелсәң дә язмыш җилендә,
Кешеләргә кашың җыерма.
Илгә багла йөрәк җылыңны,
Уйла җирне, зурла халыкны.
«Мин!..» – дип чөймә күккә борыңны,
Суфи димәс халык сарыкны.
Пешка икәнеңне тактада
Онытма син король чакта да!

ТАЛАНТЛАРНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛИК!..

1954 елның кышкы бер иртәсе. Казанда техникумда укып йөргән чагым. Радиодан Сәйдәш моңнары агыла. Диктор хәбәр итә: «Татар халкының күренекле композиторы Салих Сәйдәшев вафат, М.Горький урамындагы татар театры бинасында аның белән хушлашу мәрасиме булачак». Киенеп, театр бинасына киттем, юл уңаенда киосктан газета сатып алдым. Газетадан сокландырырлык чибәр бер кеше – Салих Сәйдәшев карап тора.

Театр янындагы тамашаны күреп хәйран калдым. Мәрхүмне озатырга килгән кешеләр, колонна булып, Горький урамыннан бер кварталга сузылган. Театр бинасына керү өчен тезелгән колоннадагы халык, татарча да, русча да сөйләшеп, бинага агыла. Ниһаять, театрга кереп, икенче катка менәбез. Оркестр, үзәкне өзәрлек итеп, С.Сәйдәшев музыкасын уйный. Зур фойеда, чәчәк бәйләмнәре арасында, мәшһүр композитор ята. Ян-ягында мактаулы каравыл, күренекле кешеләр, мәрхүмнең якыннары. Колонна, гадәттәгечә, тараеп, әкрен генә Сәйдәшевне урап, чыгу юлына бара.

Мин, йөрәк түрләрен айкап чыгарлык сагышлы моң эченә күмелгән мондый мәрасимне беренче тапкыр күргән авыл малае, аңлата алмаслык тетрәндергеч бер халәттә булдым. Яшермим: газетадагы гаять чибәр кешене күз алдында тоткач, мәрхүмнең сулып агарган йөзен күрү авыр булды. Ул, бик каты авырып, Мәскәүдә җитди операциядән вафат булган, диделәр.

Соңрак, берникадәр мәгълүмат туплагач, кайбер юньсез кемсәләрнең шушындый бөек композиторны, юкка гаепләп, кагып-сугып йөргәнлекләрен белеп, йөрәгем әрнеде, әле дә нәфрәтләнәм. Аның үлемсез «Кызыл армия маршы» гына да ни тора бит, ә тетрәндерерлек моңлы көйләре! Үзләре исән чагында ник кадерләрен белмиләр, нигә тиешле югары бәя бирмиләр икән бездә бөек шәхесләргә?! Әшәке, явыз, көнче кешеләр аз түгел шул бездә...

Сәйдәш музыкасын тыңлаганда, күз алдыма еш кына аның еракта калган 1954 елның кышкы көнендә газетада күргән сокландыргыч йөзе күз алдыма килә. Аны фани дөньядан киткәч булса да күреп кала һәм соңгы юлга озатуда катнаша алуыма шатланам.

Менә хәзер бу бөек кешенең бөтен тормышын күз алдына китереп, зиһенем аша үткәрү мөмкинлеге туды: кулымда күренекле шагыйрь һәм прозаик Рафис Корбанның яңа гына басылып чыккан «Артык кешеләр» исемле романы. Бу әсәрдә татар халкы музыкасының алтын баганасы – үлемсез җырлар-көйләр авторы Салих Сәйдәшевнең, аның иҗади хезмәттәшләре – күренекле сәнгать әһелләре һәм язучыларның тормышына бәйләнешле вакыйгалар сурәтләнә.

Р.Корбанның бу әсәре – ифрат кыйммәтле һәм бүгенге катлаулы вәзгыятьтә яшәүче татар халкының рухи иминлеген саклауга ярдәм итәрлек хезмәт. Хәзерге милли мәдәният мохитендә төрле чуалышлар, кирәксез, зыянлы үзгәрешләр кертү белән мавыгу, туган телнең абруен төшерү шартларында әлеге романда тасвирланган 20-40 нчы елларда милли мәдәниятнең үсешенә фидакарьләрчә хезмәт иткән татар улларының күркәм гамәлләре бүгенге милләттәшләребезгә үрнәк була алыр иде.

«Артык кешеләр» романын, анда бәян ителгән вакыйгаларның гыйбрәтле, мавыктыргыч булуы нәтиҗәсендә дә, язучының аларны оста төзелешле сюжетлар корып бирә белүе аркасында да, битараф кына уку мөмкин түгел. Анда сурәтләнгән кешеләр – татар халкының ул еллардагы ялкынлы йөрәкле шәхесләре шулкадәр җанлы булып күз алдына килеп баса, анда сурәтләнгән шаулы вакыйгалар, дәһшәтле хәлләр нык ышандырырлык итеп тасвирлана, хәтта әсәрне укыганда туган тәэсирдән тиз генә арынып булмый, үзеңне Совет властеның беренче унъеллыкларында хөкем сөргән мохиттә, ул чактагы вакыйгаларда катнашкан кешеләр арасында булгандай хис итәсең, әсәрдә тасвирланган уңай геройларның игелекле гамәлләренә шатланасың, ә тискәре персонажларның явызлыгына, мәрхәмәтсезлегенә нәфрәтләнәсең.

Әсәрнең укучыга шулай көчле тәэсир итүе – табигый хәл. Р.Корбан бу романны язуга тәҗрибәле каләм остасы, байтак уңышлы шигырьләр, поэмалар, легендар разведчик Исхак Әхмәров турында бай эчтәлекле, мавыктыргыч роман язган әдип буларак керешкән. Язуга тотынганчы, әсәрнең эчтәлеген тәшкил итәсе бик күп кешеләрнең узган тормышлары белән танышкан, алар яшәгән чорның гыйбрәтле вакыйгаларын өйрәнгән. Язучының элекке тормыш хәлләрен, төп персонажларны җанлы итеп сурәтләвенә күп вакыйгаларның автор яхшы белгән җирләрдә баруы, С. Сәйдәшев нәсел-нәсәбәләренең язучы туып үскән җирләр белән турыдан-туры бәйләнешле булуы ярдәм иткәндер, әлбәттә.

Р.Корбанның «Артык кешеләр» романында иң әһәмиятле сыйфатларының берсе – аның реалистик характерда булуы. Автор вакыйгаларны, персонажларның холык-фигыльләрен, кылган гамәлләрен, чынбарлыкка мөмкин булганча туры килерлек итеп күрсәтүне максат итеп куйган. Анда, кайбер язучыларның әсәрләрендәгечә, картиналарны бары тик ак яки кара буяулар белән генә ясау гадәте юк. Аның аеруча уңай геройларының да кайбер җитешсез яклары, тискәре сыйфатлары күренә. Мәсәлән, 20-30 нчы елларда татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләре Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Кави Нәҗми кебек язучылар да, партия күрсәтмәләрен үтәү өчен кирәгеннән артык тырышып, үзләренең кайбер иптәшләренең вак-төяк, булыр-булмас кимчелекләрен күпертеп күрсәтеп, аларның урынсызга гаепләнүләренә юл куя.

Гомумән «Артык кешеләр» романында сурәтләнгән иң тетрәндергеч хәлләр – 20-30-40 нчы елларда илдә барган коточкыч террор вакыйгалары. Татар әдәбиятын, сәнгатен, мәдәниятен үстерүгә бар көчләрен салып, дәртләнеп иҗат иткән дистәләрчә талантлы татар язучыларының, сәнгать әһелләренең гаепсезгә харап ителүе, ул елларда кылынган гаделсезлек күренешләре турында укыганда җан әрни. Әсәрдә сурәтләнгән явызлык хәлләрен күз алдыннан үткәргәндә, бер үтә аяныч һәм фаҗигале күренешне әйтмичә калып булмый. Революция шаукымына сөенеп, совет властен төзүгә бөтен барлыгын багышлап, татар җөмһүриятен төзүгә, аның рухи тормышын алга җибәрү өчен, үзләрен аямыйча иҗат иткән кайбер милләттәшләр, партиягә кергәннән артык тугрылык сакларга тырышып, үзләренең намусларына каршы килеп, күпмедер дәрәҗәдә иптәшләренә, якын дусларына хыянәт иткән, бер-берсен әләкләп, тикшерү органнарына язып бирә торган булган. Бу күренеш ул еллардагы безнең татар зыялылары тарихында кара тап булып кала. Роман авторы бу ямьсез күренешләрне күрсәтеп дөрес эшләгән. Андый хәлләр хәзерге һәм киләчәк буыннар өчен гыйбрәт булсын, янә кабатланмасын. Бу әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар бүген



90 нчы еллар башында яуланган демократик казанышларыбыздан ваз кичүгә, милли мәгарифебезне какшатуга китерә торган карарлар кабул итеп утырган кайбер хакимият ияләре өчен дә сабак булсын иде.

Укучылар романның «артык кешеләр» дип аталуын дөрес аңлар: әсәрдә сурәтләнгән төп персонажлар – узган гасырның 20-40 нчы елларында илдә ялгыш милли сәясәт үткәргән һәм явыз табигатьле, көнче бәндәләр өчен генә артык кешеләр, ирекле, бәхетле тормыш коруга омтылып яшәүче намуслы затлар өчен исә алар иң кирәкле, иң игелекле, фидакарь кешеләр. Роман авторы аларны, табигый рәвештә, шулар кебек үк ачы язмышлы күренекле шәхес С.Сәйдәшев тирәсенә туплап күрсәтә.

«Артык кешеләр» романының уңышлы булып чыгуы – барыннан да бигрәк авторның татар халкының сөекле улы, милли рух, моң саклаган профессиональ музыкага нигез салган С.Сәйдәшев образын, чынбарлыкта булганча, зур сәләтле, миһербанлы шәхес итеп сурәтләп бирә алуында. Ул – әсәрдә, нәкъ тормыштагыча, талантлы һәм күркәм сыйфатларга ия сөйкемле, матур, затлы кеше. Романны укыганда, аны уеңда үзеңнең якының, туганың кебек кабул итеп, аның уңышларына сөенеп, авырлык-кыенлыкларына, аның өстенә төшкән бәхетсезлекләргә кайгырып утырасың.

Бу асыл затның тормышында чыннан да зур уңышлар да, борчу-хәсрәтләр дә җитәрлек була. С.Сәйдәшевнең татар халкының бөек композиторы булуының асыл сыйфаты, иң әһәмиятле үзенчәлеге шунда: ул һәртөрле жанрдагы камил музыка әсәрләрендә дә табигый милли моңны саклауга ирешә. Аның профессиональ музыкант, композитор буларак даһилыгы бигрәк тә менә шушында. Ул, үзенең үлемсез әсәрләрендә милли моңны, милли рухны катгый караштa торып саклап килүе аркасында күп бәла-казаларга, кайбер сәнгать җитәкчеләренең хакимият вәкилләренең каты тәнкыйтенә, хәтта һөҗүменә дучар була. Сәйдәшев чигенми, иманына турылыклы булып кала. Кайбер җитәкчеләрнең аннан опера музыкасы язуын таләп итүләренә карамастан, татарлар рухына туры килә, халык моңын чагылдыра торган музыка язуын дәвам иттерә. Ул музыкаль драма жанрын барлыкка китерә: дистәләрчә спектакльләрне матур җырлар, увертюралар, сюиталар, арияләр, бию көйләре белән бизи. Аның күренекле драматурглар К.Тинчурин, Т.Гыйззәт белән бергәләп иҗат иткән «Зәңгәр шәл», «Наемщик» музыкаль драмалары – татар сәнгатенең йөзек кашына тиң үрнәкләре, тутыкмас җәүһәрләре.

Сәйдәшев әсәрләре Советлар илендә һәм чит илләрдә яшәүче миллионлаган татарларның иң яраткан музыкасына әверелә. Аның музыкасы Мәскәүнең иң зур концерт залларында яңгырый, аны СССР дәүләтенең беренче җитәкчеләре тыңлый, данлыклы «Кызыл армия маршы» өчен К.Ворошилов кыйммәтле сәгать белән бүләкли. Сәйдәшевнең концерт төркемен Мәскәү Кремлендә «Бөтенсоюз старостасы» М.Калинин кабул итә.

Нинди генә үкенечле хәлләр булмаган безнең татарлар тормышында! Кулга гына күтәреп йөртерлек шушындый талант иясен, ифрат зыялы, инсафлы, кече күңелле кеше, татар халкының мәдәниятен, сәнгатен алга җибәрү өчен, үзен аямыйча, җигелеп хезмәт иткән игелекле С.Сәйдәшевнең дә үзе исән чагында кадерен белү җитми. Башка сыймаслык хәлләр була. Яраткан хатынының, балаларының, иң якын дусларының үлеме кайгыларын кичергән, халыкның сөекле композиторын җитди сәбәпсез эшсез калдыралар, яшәү чыганагыннан, дәртләнеп, үлемсез музыка әсәрләре иҗат итү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр. Нәтиҗәдә бөек композиторның соңгы еллары гаять авыр, кадерсез шартларда уза.

Р.Корбанның «Артык кешеләр» романын тормышыбызда мондый талантлы кешеләрнең кадерен белергә, игелекле эшләренә тиешле бәя бирү зарурлыгын кисәтеп, чаң сугу дип кабул итәргә кирәк.

Рүзәл ЮСУПОВ,
академик.

Үз мәсләгенә тугры калган галим

Г.Тукай әдәби музеенда танылган язучы, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме Ибраһим Нуруллинның тууына 100 ел тулуга багышланган «Моңлы саз чыңнары» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Ул Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты белән берлектә әзерләнгән иде.

● Таһир Гыйләҗевнең яңа китабы чыкты.

● И.Нуруллинның кызы Гүзәл.

Ибраһим ага Нуруллин әдәбият сөючеләргә иң әүвәл хикәяче-прозаик буларак танылa. «Ана тойгылары», «Рәхмәтулла абзый», «Кунакта» һ.б. әсәрләре укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Соңрак аны Г.Тукай иҗаты ныклап кызыксындыра башлый. «Тукайның әдәби пародияләре», «Тукай тәнкыйтендә типиклык мәсьәләләре» «Тукай эстетикасы һәм рус әдәбияты» дип исемләнгән мәкаләләре дөнья күрә. Соңрак әдипнең шагыйрь тормышын һәм иҗатын өйрәнүе тагын да тирәнәя, аның нәтиҗәсе булып исә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә басылып чыккан «Габдулла Тукай» исемле фәнни-әдәби әсәре туа. Ул шулай ук Фатих Әмирхан, Шәриф Камал иҗатларына, әдәбият тарихының һәм агымдагы әдәби процессның аерым проблемаларына багышланган хезмәтләре белән әдәбият белгече, тәнкыйтьче булып та танылa. Ибраһим ага урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар әдәбияты дәреслекләренең авторларының берсе.

Бүгенге урта яшьләрдәге буын Тукаебызны һ.б. әдипләрне И.Нуруллин әсәрләрен һәм хезмәтләрен укып үсте. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла да мәктәптә укыганда ук И.Нуруллинның Тукай турындагы фәнни-әдәби хезмәтен укып белүе турында әйтә. Әсәр ул заманда татар язучысының бөек татар шагыйре турында язган бердәнбер китабы була. «Хәзер Тукайчылар шактый, ләкин бөек шагыйребез дигәндә, иң беренче нәүбәттә Ибраһим ага килеп баса. Ул Тукайның балачагы, тормышы турында хикәяләр, пьесалар да язды. Гомумән, ул Тукай рухы белән яшәде», – диде ул. Р.Зәйдулла шагыйрь Мәхмүт Хәсәен белән бик якыннан аралашып калган. Шагыйрь һәм язучы-галим яшьтәш булганнар, икесе дә Бөек Ватан сугышында катнашкан. Р.Зәйдулла Мәхмүт аганың да И.Нуруллин турында һәрвакыт зур ихтирам белән сөйләвен искә төшерде. Берлек рәисе искәртеп үткәнчә, холык тумыштан килә. Әйтик, Тукай турында истәлекләрдә аның принципиаль булуы турында язалар. «И.Нуруллин белән Тукайның да холыклары туры килгән, минемчә. Һәркем үз дәрәҗәсеннән чыгып Тукайны бәяли, аның турында фикерли. «И.Нуруллинның Тукае – мәйдан уртасында басып торган көрәшче, үз сүзен кистереп әйтә торган шәхес», – дип тәгаенләп үтте Зәйдулла. Бер генә кеше бик тырышса да, үзе генә максатына ирешә алмый, аның янында тарафдарлары, юлдашлары булырга тиеш. «Шуңа күрә Тукайның даирәсе дигәндә, Фатих Әмирхан искә төшә. И.Нуруллин аның турында да китап язган иде», – диде Р.Зәйдулла. И.Нуруллин Советлар берлеге чорында тәрбияләнгән, социалистик реализм тарафдары була. «Фани дөньяга күчкәнче, ул үзенең тоткан мәсләгенә тугры булды. Чын коммунист иде ул. И.Нуруллин кебек үз сүзен әйтә торган кешеләр сагындыра, алар һәр заманда да кирәк», – диде рәис.

КФУның татар әдәбияты кафедрасы профессоры Фоат Галимуллин тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме И.Нуруллинның төп игътибарын, көчен XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә биргән галим булуын белдерде. «Ул зур мирас калдырды. XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнүгә күп көч салды. Урта гасырлар әдәбияты традицияләреннән аңача фикерләүгә күчү вакыты булган бу чор әдәбияты, язучылары фәнебездә күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән булса да, тәпле сүз әйтелмәгән иде. И.Нуруллин әлеге чорның барча катлаулылыгын ача-ача иңләп, бәяләп чыга алды», – диде ул.

XX йөз башы татар әдәбиятын өйрәнү, Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан кебек зур язучылар дәверенә бәя бирү кирәк була. И.Нуруллин шушы эшкә алынган. Хезмәтен китап буларак чыгарган. Аны фәнни җәмәгатьчелек уңай кабул итсә дә, Ибраһим ага үзе канәгать калмаган. «Мин төп сүземне әйтә алмадым», – дигән. «Чөнки И.Нуруллин XX йөз башы әдәбиятына багышланган хезмәтен 1960 еллар ахырында язган иде. Бу – Исхакый исемен телгә алу тыелган еллар. Исхакый иҗаты, аның мирасыннан башка XX йөз башы татар әдәбиятына дөрес бәя бирү мөмкин түгел. Ибраһим ага эзоп теле белән әйтергә тырышып карады, ләкин ул аны да, безне дә канәгатьләндермәде», – диде Ф.Галимуллин.

Ибраһим ага Исхакыйның мирасы кайтарыла башлагач, өр-яңадан шушы эшкә алына. Ул Бөек Ватан сугышында бер аягын югалтып кайткан иде. Бер аягы белән Төркиягә барып, Исхакый эзләреннән йөреп, китапханәләрдә хезмәтләрен өйрәнеп, язучы турында бик күп истәлекләр туплап, кабереп зиярәт кылып кайта. «Ул Исхакыйның Совет хакимлеге чорында нәшер ителгән «Зиндан» китабына кереш сүзне язды, әмма әдәбиятыбыз Исхакыйга бәйле рәвештә, аның иҗатының шифалы йогынтысы ярдәмендә үсеп китүен киң итеп әйтергә өлгерә алмады, гомере өзелде, ниятләгән китабы язылмыйча калды», – диде Фоат ага.

Казан федераль университет доценты, әдәбият галиме Таһир Гыйләҗев И.Нуруллинның гади ассистенттан алып профессор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелүен, совет хакимлеге чорында Исхакый мирасын кайтару эшен башлап җибәргән беренче галим икәнлеген әйтте. Әлбәттә, галимнең принципиальлеге аның үзе өчен төрле кыенлыклар да тудыра. Бу уңайдан Т.Гыйләҗев олуг галимебез Миркасыйм ага Госманов истәлекләрен искә төшерде. И.Нуруллин, Г.Исхакыйның Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын гына булса да кайтарып булмасмы, аңардан башка XX йөз башы әдәби хәрәкәтен генә түгел, ә Тукай иҗатын да тулысынча ача алмыйбыз, дип өлкә комитетына бара. Әмма сөйләшү бик ямьсез, кычкырыш, җәнҗал белән тәмамлана. Нәтиҗәсе булып исә «Чаян» журналында И.Нуруллинга карикатура чыга. «Ибраһим ага үзе тоткан юлыннан беркайчан баш тартмыйча, башлаган эшен принципиаль рәвештә дәвам иткән шәхесләрнең берсе иде», – диде Т.Гыйләҗев. Ул И.Нуруллинның йөрәгендә фән белән бергә иҗат дәрте яшәвен дә искәртте. Ул Казан университетына укырга кергәнче үк, 1944 елда «Совет әдәбияты» журналында аның беренче хикәясе дөнья күрә. Шуннан соң гомеренең соңгы көннәренә кадәр фән белән әдәби эшчәнлекне бергә бәйләп алып бара.

И.Нуруллин турында аның тормыш иптәше, журналист Розалина ханым Нуруллина «Ибраһим Нуруллин», «Томанарга юллар күмелде» дигән истәлек-хатирәләрен бастырып чыгарды. Әмма, Т.Гыйләҗев искәрткәнчә, И.Нуруллинның эшчәнлеге турында күләмле фәнни хезмәтләр язылмаган, диссертацияләр якланмаган. «Мин аның эшчәнлеген күпмедер күләмдә өйрәндем. Кызганыч ки, аерым фәнни мәкаләләр бар, ләкин И.Нуруллинны әдәбият галиме буларак ачкан, аның фәнни һәм гыйльми эшчәнлеген концептуаль нигездә өйрәнгән күләмле фәнни хезмәтләр, диссертацияләр юк», – диде ул.

И.Нуруллин шәкерте, филология фәннәре докторы Т.Галиуллин И.Нуруллинның Мөхәммәт Мәһдиев белән дуслыгы хакында сөйләде. Алар еш кына бергә гәпләшеп дүртенче каттан төшә. Шунда Ибраһим аганың таягын онытып калдырганлыгы исенә төшә. Әлбәттә, дусты Мөхәммәт ага кабат дүртенче катка йөгерә. «Гүзәл яшьлегем Ибраһим абыйның таягын ташып үтте», – дип шаярта торган була ул.

Әдәби-музыкаль кичәдә Т.Гыйләҗевнең яңа гына басылып чыккан «Тукай гыйльмияте» дигән китабы да тәкъдим ителде.

Кичә Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф Югары мәктәбенең студентлары чыгышлары белән үрелеп барды. Алар Мәхмүт Хәсәеннең И.Нуруллинга багышланган «Казанда яз» шигырен, язучы һәм галимнең төп таянычы – Розалина Нуруллина, шулай ук шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов, язучы Зиннур Мансуров, галимә Резеда Ганиеваның язучы һәм галим турындагы истәлекләреннән өзекләр сөйләде. Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров башкаруында баянда уйнап, Р.Яхинның «Китмә, сандугач» җыры яңгырады. Илфак Хафизов җитәкчелегендә «Мизгел» студентлар театры «Тукай Петербургта» драмасыннан өзек уйнавы әдәби-музыкаль кичәнең күркәм бизәге булды.

Кичәдә Розалина һәм Ибраһим Нуруллиннарның кызы Гүзәл катнашты, кичәне оештыручыларга һәм чыгыш ясаучыларга олы рәхмәтен белдерде. Чараны Тукай әдәби музее җитәкчесе Гүзәл Төхфәтова алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Татар дөньясы

Талымхан авылы музейлары

Авылыбызда музейлар икәү, берсе – 20 ел эшләүче мәктәп музее, икенчесе – яңа булдырылган йорт, өй музее. Мәктәп музеен башлангыч класслар укытучысы Тәслимә Мөхәммәджанова җитәкли, ә мини-музей Шамил абый Юскаевның оныгы – 8 нче сыйныф укучысы Илдар Юскаев тырышлыгы белән нигезләнгән.

Хәзерге көндә лаеклы ялда булган Самад Мәхмүтов иске агач мәктәп бинасында беренче эш экспонатларын җыйган, ә яңа таш мәктәп салынгач, 2003 елдан 2013 елгача мин укучылар ярдәмендә яңа зур бүлмәдә музей бизәдем.

Мәктәп музее 2013 елдан рәсми статусы, ә Илдарның өй музее бер бүлмә почмагында гына әле. Түбән районы ветераннар советы 2022 елда СССРның 100 еллыгына багышлап иҗади конкурс игълан иткән. Шул конкурста катнашканы өчен аңа Мактау хаты бирелде.

Мәктәп музее өч экспозициядән тора. Музей экскурсоводлары төрле конкурсларда катнашалар, семинарларда, кичәләрдә чыгыш ясыйлар. Мәктәптә үткән татар теле һәм әдәбияты укытучылары семинарында катнашкан апаларга музейга экскурсия оештырдылар. 8 нче класс укучылары Олеся Ильясова белән Мәдинә Абдразакова «Үлемсез полк», «Безнең чор батырлары» дигән стендларны яктырттылар. Олеся Бөек Ватан сугышына багышланган почмакта халкыбызның үлемсез батырлыгын, төрле авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм иткән, яшәү теләген яктырткан материаллар турында сөйләде.

Музей яшь буынга авыл тарихын белү, халкыбызның гореф-гадәтләрен саклау, күренекле кешеләр турында материаллар туплау максатлары белән эшли.

Рәйсә РӘХИМОВА.
Түбән районы Талымхан авылы "Яңарыш" газетасыннан.

(Ахыры. Башы 15 нче санда).

Ибраһим НУРУЛЛИН

Башкала белән саубуллашканда

Г.Тукай Санкт-Петербургта. Ф.Әминов эше.

– Мин аларны яшел итеп, шау чәчәктә күрәм. Күпме көчәнмә, Пушкиннан уздырып әйтеп булмас.

Люблю тебя, Петра творенье,
Люблю твой строгий,
стройный вид,
Невы державное теченье,
Береговой ее гранит.

Малай вакытта мәчет манарасына менгәнегез булгандыр. Үзенең кыек өен, сукыр күзле мәдрәсәсен, тавык йөзеп чыгарлык инештән башканы күрмәгән малайга бөтен дөнья ачылган кебек була. Мин дә шул малай хәлендә, дуслар! Бөтен Россия уч төбендә төсле. Тыңлагыз әле, бернәрсә язган идем.

Тукай өстәлдә яткан кәгазьләр арасыннан берсен эзләп алды да укырга керешә:

Без Бишенче елны беркөнне
уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне
кемдер изге нам белән.
Эшкә ябышыр чак җитеп,
ямьсез озын төн үткәнен
Күз ачып белдек без, үлчәп
күктәге чулпан белән.
Булса да ул чакта бездә керсез
иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә
саф һәм пакь түгел.
Аңгы-миңге баш белән дә
эшләдек, булсын кабул,
Җәбраил ачкай ул эшләргә
сигез кат күккә юл.
Үтте инде, дусларым, ул үткән
эш, ни булса ул;
Инде эшлик саф, ачык күзләр
белән, чын аң белән.

– Шәп, Тукай!
– Афәрин!
– Өстенә баскансыз!

Аннары Шакир, Габдуллага сиздермичә, иптәшләренә күз кысып куйды да:

– Шулай да бернәрсәне онытасыз, Габдулла әфәнде, – диде. – Ачык күз, чын аңнан башка, тимер кебек саулык кирәк. Көрәш бит ул!

– Тыңла, Габдулла, акыллы сүзләрне, – дип ялгап китте Хәбир. – Сиңа докторга күренеп, ныклап торып дәваланырга кирәк. Юкса, соң булуы мөмкин…

– Кычкырмаса, эче авырта икән. Анысы син буласың инде. Теләсәгез ни әйтегез, егетләр. Петербургка килү минем өчен шифалы булды әле. Кечкенә чакта Сәйфелмөлек китабын укыганда, пәри шәһәре шулай мәһабәт күренә иде. Петербург исә пәри шәһәрен дә оятка калдырды. Хәйран мин, дуслар!

– Яңгыр, җир, салкын, – диде Хәбир.

– Шаярма, мелла Хәбир.

– Бакчаларында – урам себеркеләре, – дип өстәде Шакир.

– Әйттем мин сезгә! – диде Тукай, җиңел генә. – Алып барыгыз докторга, дидем. Кешенеке кештәктә шул.

– Кайчан? – диде Хәбир, аптырап. Шакирның да, Кәримнең дә күзләре көлә иде.

– Шылтырама инде, – диде Шакир, Хәбиргә төртеп. – Чакырдык, Габдулла әфәнде. Озакламый килеп җитәр.

Моннан соң бер-ике авыз сүз алышырга да өлгермәделәр, ишек шаку тавышы ишетелде.

– Ул, – диде Шакир. – Гомере озын булыр. Рәхим итегез!

Чыннан да, доктор иде бу. Юантык кына кеше. Озын мыек, ияк очында гына кыска түгәрәк сакал. Шакир докторның плащын һәм эшләпәсен алып чөйгә элде.

– Исәнмесез, әфәнделәр. Кайда авыру?

– Рәхим итегез, Александр Робертович, – диде Шакир, Тукайга ишарәләп.

– Авыру – молодцом! Юкка килгәнмен, ахры.

– Шулай да карагыз инде, – диде Хәбир, көлеп.

– Врачларның шул инде. Чакыргач – киләсең, чире булмаса – табасың.

– Миннән дә табарсыз микән, доктор?

– Сез – икенче мәсьәлә, яшь егет. Ну-с, әфәнделәр, сез чыгып торыгыз.

– Чишенегез, яшь егет, – диде доктор, үзләре генә калгач. – Ишеттем, ишеттем, татарның зур шагыйре икәнсез. Русның Пушкины кебегрәк…

– Ялганлаганнар. Яхшырак карасын диптер. Доктор көлеп җибәрде.

– Тыйнакланып маташмагыз. Ну-с, карыйк.

Озак азаплады доктор Тукайны. Бер генә кабыргасын да калдырмыйча, бармаклары белән суккалап чыкты. Салкын стетоскобын йә аркага, йә күкрәккә терәп, «сулагыз, суламагыз» ди-ди, озаклап тыңлады. Яткырды, торгызды. Эчен кыскалап карады, тезләренә резин чүкеч белән суккалады, телен чыгартты… Кыланмаганны калдырмады инде.

– Ну что ж… – диде ул, ниһаять, һәм шагыйрьнең ялвару һәм өмет белән караган күзләреннән качарга теләп, өстәл янына барып утырды да ручка алды.

– Организмыгыз шактый таушалган, билгеле… Арыклангансыз. Кан азайган. Мин сезгә Петербургтан китәргә киңәш бирер идем. Көньяк санаторийларның берсенә барып, тоташтан ике ай дәвалансагыз… йөзгә җитәрсез.

– Рәхмәт, доктор, – диде Габдулла, җиңел сулап. – Кымызга гына барсам, ярамасмы?

– Һем-мм, кымыздан да файда алып була… Әмма мин санаторийга барырга киңәш итәр идем.

Доктор тиз-тиз язгалады да:

– Менә сезгә рецептлар… Хәзергә шулардан файдалана торыгыз, – диде.

Тукай киенә калды, доктор коридорга чыкты.

– Хәл җитди, әфәнделәр. – Күп булса, ярты ел яшәр. Бер як үпкәсе череп беткән, икенчесеннән дә ярты гына калган. Иң яхшы курортларның берсенә җибәреп, ике-өч елга гомерен озайтырга мөмкин… Үзенә әйтмәдем. Кайда кул юарга була?

– Шакир аны озата китте. Хәбир Кәримгә карап:

– Йә, нишлибез? – диде.

– Ялта инде. Яисә Швейцария.

– Акча?

– Җыярга кирәк. Шәһәрдә мөселман күп. Приказчиклар, байлар…

– Тссс, үзе…

Тукай ашыгып килеп чыкты да:

– Җилкәдән тау төште, дуслар! – дип кычкырды. – Казан коновалы түгел инде бу!

Аннары докторга каршы атлады.

– Рәхмәт, доктор, яңадан тугандай иттегез.

– Яхшы, яхшы, дускай, тазаругызны телим. Минем әйберләрне чыгарсагыз ла, әфәнделәр.

Шакир плащ белән кечкенә чемодан тотып чыкты да докторга киенергә булышты.

– Хушыгыз, – диде доктор, Тукайга кул биреп, – тизрәк терелегез.

– Рәхмәт, мең рәхмәт.

Хәбир белән Шакир озата киттеләр. Баскычка җиткәч, Хәбир докторның учына нәрсәдер төртте.

– Сез нәрсә?

– Гонорар, доктор…

– Алмыйм. Озатуда кыенлыклар килеп чыкса, мин картны да онытмагыз. Яраттым шагыйрегезне.

Нәзакәт йөзеннән Александр Робертович ачык әйтмәсә дә, дәвалау чыгымын күтәрешергә әзер икәнлеген аңладылар.

Тукай белән Кәрим бүлмәгә кергәннәр иде.

– Кайдан таптың, туган, бу пәйгамбәрне? – диде Тукай, Шакирга карап.

– Университет докторы ул, Габдулла әфәнде.

– Ни җитте төштән түгел икән… Китәм кымызга, күрерсез менә, шишман булып кайтмасам! Аннары эшкә. Ай-һай, күп әле язасыларым!

– Кырымга яисә Швейцариягә китәргә кирәк сиңа, Габдулла. Доктор да шуны куәтли.

– Акча?

– Акча табабыз.

– Сәдака алмыйм.

– Сәдакамыни ул? Эшләрсең – түләрсең. Сиңа нәрсә акча! Бер типтең – алтын тавы хасил була, – диде дә өстәлгә кул изәде. – Бер төн эчендә әнә ничаклы язгансың.

– Хәбир дөрес әйтә, Габдулла әфәнде, – диде Кәрим.

– Кыстамагыз, дуслар, безгә – кара корсакка – кымыз да ярый. Швейцариягә әнә ваше благородиеләр барсын. Доктор әйтте, кымыз да ярый, диде.

Беразга тынып калдылар. Ничек күндерергә, нинди дәлил табарга? Дөресен әйтеп булмый. Соңгы чиккә җиткән шагыйрьне үз кулың белән үлемгә озатырга туры килер микәнни?

– Болай бит, Габдулла. Безгә доктор кат-кат әйтте: көньякка җибәрергә тырышыгыз, диде. Һавасы, даруы, белгечләре…

Тукайның йөзе уйчанлана төште. Чак кына фикергә калып торгач, ул башын күтәрде.

– Юк, туганнар, Кырымнарда, Швейцарияләрдә өстерәлеп йөрергә туры килмәс миңа. Россия манарасына менеп карагач, күзем күпне күрә, колагым күпне ишетә башлады. Әйтер сүзем бермә-бер артты. Өлгерергә кирәк… Һәр минутым санаулы, һәр минутым дөнья бәясе.

– Бик яхшы. Дәваланып кайтасың да…

– Юк! Гөлне туфрагыннан аерсаң корый. Мин дә кибәм анда, корыйм. Белмим мени мин гомеремнең күп калмаганлыгын. Шул гомеремне туган туфракта, туган халкым эчендә үткәрергә тиеш мин. Яктыга, бәхеткә, көрәшкә чакырырга. Дошманнарым белән йөзгә-йөз торып сугышканда гына, күңел җимешләремне бирә алам. Юк, Швейцарияләрдә өстерәләргә туры килми миңа…

Тукайны артык үгетләү файдасыз иде…

Эчкерсез иҗат

Яхшы китап – чын мәгънәдә рухи азык, ул автор өчен генә түгел, укучылар өчен дә шатлык. Берничә атна элек миңа шундый ике китапны уку бәхете эләкте. Икесе дә миңа күптәннән таныш Эльмира Шәрифуллинаныкы иде. Аның «Йөрәк сүзем» дигәнен берничә көнгә генә дустым биргән иде.

– Аның шигырьләре синең хәзерге халәтеңне дә җиңеләйтә алыр, – дип тә өстәде. «Халәт» дигәндә ул 62 ел бергә көн күргән хәләл җефетем Фәүзиянең бакыйлыкка күчүен күз алдында тотты, әлбәттә.

Автор бу китабына бер шигыренең исемен биргән. Аның һәр шигыре кебек үк, тирән фикерле, уйлы шигырь ул.

Үз Ватаным – алтын,
Йөрәк сүзем – ялкын,
Набат суга Таулар, Кыялар:
Кагылмагыз Телгә!
Иң авырткан җиргә,
Имин булсын, дисәк, дөньялар!

Бу строфага бернинди аңлатма да кирәкми.

Китапка авторның соңгы елларда язылган шигырьләре һәм «Тәмуг кисәве», «Инша», «Сөембикә», «Оран», «Ак бүре турында баллада», «Сугыш кырларыннан мин кайтсам», «Бер кычкырды кәккүк», «Без – Тукайлы халык», «Каюм коесы» дигән поэмалары кертелгән.

Эльмира ханымның гомере буе сызланып яшәвенең сәбәбен күптәннән беләм. Ул 1982 елда фаҗигале рәвештә (дөресен әйтсәк, кыйнап үтерелгән) бакыйлыкка күчкән ире, талантлы язучы Фаил Шәфигуллинны югалтты. Фаил «Чаян» журналында эшли иде, ә мин, юмор һәм сатира әсәрләре язып торучы буларак, аның белән очраштыргалап йөрдем.

Уйласаң, бу фаҗигагә ничәмә дистә еллар узды, ә Эльмира ханым шушы көнгә хәтле үзенең җаны кебек күргән Фаилен исеннән дә чыгара алмый! Ул иренең иҗатын барлау һәм бастырып чыгару буенча гаҗәеп зур эшләр башкарды һәм бу эшен хәзерге көндә дә дәвам итә. Ул үзенең «Бер кычкырды кәккүк» поэмасы белән, һичшиксез, ире Фаилгә шигъри һәйкәл куйды.

Шәүләң йөри көн дә, төн дә,
Күз алдымда буй-сының.
Йомшак җилләрнең исүе –
Гүя сулышың, тының... –

ди автор аның «Эзлим» дигән бүлегендә. Гади итеп әйтә, ләкин бу юллардан ук аның иренә булган мәхәббәтен әле хәзер дә күңелендә саклавын, аны юксынуының тирән икәнен бөтен барлыгы белән аңлыйсың. Бернинди «юксынам», «сагынам» кебек тапталып беткән сүзләрдән тыш!

Шагыйрә поэмаларының һәрберсе аерым-аерым бүлекләрдән тора, һәркайсының үз вазыйфасы, үз куәсе, максаты бар һәм алар әсәрнең егәрен арттырырга, эчтәлеген тулы итеп ачарга ярдәм итә. Аларның тематикасы, күтәргән проблемалары төрле. Мәсәлән, «Тәмуг кисәве»н алыйк. Ул елдан-ел арта барган каты бәгырьлелек, рәхимсезлек, кешелексезлек турында. Төрле сәбәпләр белән картлар йортында тәрбияләнүче карт-коры яисә үз-үзләрен карый алмаган инвалидлар барын да беләбез. Шул ук вакытта хәзер арабызда хәтта җитешле тормышта яшәгән кешеләрнең дә ата-аналарын, якыннарын шундый йортларга илтеп тапшырулары турындагы хәбәрләргә дә күнегә башладык бит... Ә кайчандыр мондый кешелексезлек очраклары булырын күз алдына да китерә алмый идек. Җан өшеткеч бәла бу! Поэмада бу проблема картлар йортына китереп ташланган әбинең эчке монологы аша бирелә.

Ул бу йортта өч ел җан асрады,
Ул бу йортта өч төн яшәде, –

диелә поэмада. Аңлашыла: картлар йортында яшәмиләр, җан асрыйлар һәм Ходайдан: «Ал җанымны!» – дип сорыйлар...

Эльмира ханым иҗатына хас бер үзенчәлек бар. Ул язасы темасын энәсеннән җебенә хәтле өйрәнмичә, каләмен кулына алмый. Әйтик, Тукайга багышланган «Без – Тукайлы халык!» поэмасын язу өчен ул Кушлавыч авылында да, Тукай йөргән җирләрдә дә була, аларда яшьлеген үткәргән Тукайның эчке хисләрен үз күңеленнән үткәреп яши-яши генә ак кәгазьгә сала. Бөек мәгърифәтчебез Каюм Насыйрига багышланган «Каюм коесы» дигән поэмасы да шулай туа. Хәер, аның һәр шигыре дә эзләнү һәм кичерешләр аша, димәк, ихлас һәм эчкерсез күңел белән языла.

Безнең халыкта: «Бәла ялгыз йөрми» дигән мәкаль бар. Бәла дигәнең Эльмира ханымны бер дә тынычлыкта калдырмады, киресенчә, ирен югалту кайгысын икеләтә-өчләтә көчәйтеп, икенче яктан китереп сукты: ул Фирүзә исемле кызын да югалткан Ана бит әле... Әлбәттә, шагыйрәнең иҗатында бу кайгы да чагылмыйча калмады. Аның дүрт бүлектән торган, поэмага тартым «Фирүзә» дигән шигырендә:

Хәтфә төсле йомшак чирәм калды
Көтеп синең тәпи эзеңне.
Бу дөньяның назлы җиле калды,
Сыйпый алмый алсу йөзеңне, –

дигән юллар бар. Гомумән, бу шигырьдә бернинди тапталган, купшы сүзләр юк. Искиткеч әсәр!..

Кулыма кергән китапның икенчесе «Толларның да җаны бар» дип атала. Бу китабында, шигырьләреннән башка, вакытсыз вафат булган ире, язучы Фаилгә багышланган «Мизгел»повесте һәм төрле басмаларда дөнья күргән язмалары да урын алган. Аларны, проза белән язылган шигырьләр, диярге дә була. Эльмира ханымның үзен проза өлкәсендә дә шулай иркен «йөзүенә» сокланмый мөмкин түгел, ә бу повестен авторның сөекле иренә прозада куелган һәйкәл дисәң дә ярый. «Яшьлегем тугае» дигән язмасы да шушы кысага керә – ул Фаилнең шул исемдәге җырына багышланган. Халыкчан композиторыбыз Зиннур Гыйбадуллин менә дигән көй язып канат куйган бу җырны белмәгән татар дөньяда юктыр. Аны иң беренче булып Нәфисә Васильева башкарган иде, аннары ул берничә мәшһүр җырчыбызның репертуарына да керде. Фаил Шәфигуллинның данлыклы бу җырыннан башка «Яз җыры», «Мин гармун булыр идем», «Арышлар», «Ялгыз гармун», «Акбүз атым», «Өметем өзелми» һ.б. җырлары бар. Композиторлар аның шигырьләренә бүгенге көндә дә көйләр яза. Бу исә дөньяда нибары 43 ел гына яшәп калган, шулай да 6 повесть тудырган, даими рәвештә журналда эшләгән бу язучының төрле яктан талант иясе булуын раслый.

Бу сүзләр Эльмира ханымның үзенә дә бик туры килә. Эш аның да шактый шигырьләренә көйләр язылуында, җырчылар тарафыннан җырлануында гына түгел. Эш бер үк дәрәҗәдә талантлы шагыйрә дә, талантлы прозаик та булуында – аның прозасы да шигырь сыман укыла. Шуңа күрә аның иҗатына күренекле шәхесләребез дә тикмәгә генә игътибар итмәде. Мәсәлән, бөек шәхесебез Бакый Урманче, аңа хәләл җефете Флора ханым «Мизгел» повестен укыганда тын да алмыйча тыңлап утырганнан соң: «Бу – поэзия, йә проза белән язылган мөнәҗәт», – дип бәя бирә.

«Шигырьдә булсын, прозада булсын, Эльмираның теленә күпләр игътибар итә, – дип язган иде Ләбибә Ихсанова. – Гади, хисле, җыйнак итеп яза белә ул, заманча булсын дип, яңа сүзләр ясап маташмый, халык күңеленең тирән коесыннан чумырып ала да көн дә кулланылган гап-гади сүзләрне шундый мәгънәле итеп бер җепкә тезә ки, ана телебезнең байлыгына, мәгънәви көченә сокланмый кала алмыйсың». Бу сүзләргә берни дә өстәп булмый – язучы-прозаик шагыйрәнең теленә бик дөрес бәя биргән!

«Э.Шәрифуллина чын талантка ия булмаган булса, хәтта шәхси фаҗига да аны шагыйрә ясый алмаган булыр иде». Монысы Нурихан Фәттах сүзләре.

«Эльмираның шигырьләре, поэмалары – калфакларыбыздагы, түбәтәйләребез, суккан сөлгеләребездәге нәфислек чигешләреннән килеп чыкканнар кебек...» – дип биргән иде Әхәт Гаффар аның иҗатына карата үз бәясен.

«Э.Шәрифуллина шигырьләрен башкалар белән бутый алмыйсың: чәчрәп торган хатын-кыз авазы; әниләрне, балаларны, милли гаиләне, әхлак-матурлыкны яклап чаң сугу, камиллеккә яшәүгә өндәү, иманга чакыру аларда», – дип язды шагыйрь Рәдиф Гаташ.

«Китапханәләрдә үткәрелгән тикшеренү буенча, иң укыла торган шигъри китаплар арасында Э.Шәрифуллина китаплары да бар. Очраклы фактмы бу? Юк, әлбәттә. Әмма бездә аңа әллә ни әһәмият бирүче булмады», – дип язган иде Рафаэль Мостафин «Казан утлары» журналында.

Хәер, монда аның иҗатына карата халкыбызга билгеле булган күп шәхесләребез тарафыннан бирелгән югары бәяләрне тагын да китерергә мөмкин булыр иде, тик бу күп урынны алыр дип, бары әйтеп китәргә генә туры килә. Алар – галимнәр Т.Галиуллин, Ә.Мәхмүдов, М.Бакиров, Н.Ханзафаров, Ә.Кәримуллин, шагыйрьләр Ф.Яруллин, Ә.Маликов, З.Мансуров, Г.Рәхим, Зөлфәт, А.Хәлим, Ф.Зыятдинова, Н.Нәҗми, Р.Шәфи, Г.Садә, М.Әгъләм, Б.Ибраһимов, язучы А.Гыйләҗев, Р.Ишморат һ.б...

Күңелдә ирексездән: «Ә шагыйрәнең шундый колачлы һәм җылы, эчкерсез күңел белән язылган иҗаты рәсми рәвештә, ягъни Республика күләмендә ничек бәяләнгән? – дигән сорау туа. – Тормышындагы искиткеч зур фаҗигаләргә дә бирешмичә, сынмыйча-сыгылмыйча иҗат иткән Эльмира ханым нинди премияләргә, дәрәҗәле исемнәргә лаек булган?» «Әдипләребез» дигән китаптан (2009 ел) аның турындагы битне ачып карыйм. Әһә, 1985 елда (димәк, моннан 37 ел элек үк!) шагыйрә СССР Язучылар берлегенә кабул ителгән, 1993 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек дип табылган икән. Ә аннары? Ләкин аннары... ул бернинди премиягә дә лаек дип табылмаган. Менә монысы гаҗәп – иҗатын халык ярата, дәрәҗәле шәхесләребез мактый, ә нәтиҗәдә... Хәер, моңа гаҗәпләнергә дә кирәкмидер – премия чиратларына ни өчендер хатын-кыз каләмдәшләребез бик якын җибәрелми бугай... Хәтта кертелгәннәре дә ала алмый. Мисал өчен ерак барасы түгел: менә дигән шагыйрәбез, күп поэмалар авторы булган Флёра Гыйззәтуллина ничә тапкыр Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә кандидат буларак куелып та ала алмый. Ә бит аның моңа лаек икәнен барыбыз да белеп тора. Юк, шуны тиешле урыннарда раслап күрсәтерлек шәхесләребез юк бугай. Без куйдык, үткәрмәделәр ич, дип иңбашларын җыеручылар гына бар. Ә хәзер без «яраткан», «үз иткән», хөрмәт йөзеннән аның исемендәге премия булдырылган шагыйрә Саҗидә Сөләйманова да Тукай бүләгенә лаек дип саналмады бит...

Эльмира ханымга килгәндә, ул ниндидер премия даулап йөри торган шагыйрә түгел – ул горур һәм эчкерсез булып калды, шулай яши, шулай иҗат итә. Әле шушы яшендә дә, шушы халәтендә дә аңа, киресенчә, этлек эшләүчеләр табылып тора. Күрәсең, аның таланты, үҗәтлеге, горурлыгы да тешләренә тия. Мәсәлән, ул Фаиленең язылып бетмәгән килеш калган «Өй салуның ние бар?..» повесте исеме белән аталган, фәкать аның зур тырышлыгы аркасында гына чыккан китаптан хәтта «Төзүчесе Эльмира Шәрифуллина» дигән җөмләне төшереп калдыралар. Ә бераздан республика газетасында «дуслары җыеп нәшриятка тапшырган китап дөнья күрде» дигән чеп-чи ялган мәгълүмат пәйда була. Бик ачуны китергәне шул: бу юлларны, мәкаләне Фаил иң якын дусты дип йөргән, «Чаян» журналында бергә эшләгән кеше яза... Ул «дуслар» шагыйрә тикшерү-суд юлларында йөргәндә дә бернинди ярдәм күрсәтмәгән...

Тормыш дәвам итә. Мин бу китапларны рәхәтләнеп, бер сулышта укып чыктым, тик күңелдә ризасызлык калды, чөнки алар «Мәгариф-вакыт» дигән шәхси нәшриятта басылган, ә бу исә авторның үз акчасынадыр, дигән уйга этәрде...

Әхәт САФИУЛЛИН.

● Брест крепостеның Көнбатыш капкасы.

● Көнчыгыш фортның тышкы күренеше.

КАЗАННАН БРЕСТКА СӘЯХӘТ

Уйламаганда-көтмәгәндә ерак Беларусь иленә сәяхәт кылу бәхете эләкте. Бөтендөнья татар конгрессы җирле тарихчы-төбәкчеләрнең чираттагы конференциясен Минск каласында үткәрергә карар кылган, ә безнең республикада 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1814 елның 19 мартында Парижны яулап алуда катнашкан «башкорт» җайдакларының тарихын өйрәнүче сыңар галим дә юк бит, ә мин – Минзәлә өязеннән китеп, француз походларында яу йөргән 230 дан артык татар җайдагының исемлеген «Мәдәни җомга» газетасында бастырып чыгарган кеше, менә шул сугышчан поход турында чыгыш ясавымны үтенеп, төбәкчеләр җитәкчесе Альберт Борһанов мин фәкыйрегезне дә ерак сәяхәткә чакырды. Брест каласына да экскурсия ясаячагыбызны белгәч, шундук риза булдым. Гәрчә 2006 елның май аенда Европаның 7 иленә сәяхәт ясаганда Минск һәм Брест калалары аша үтсәм дә, аларда тукталып, ачы тарих белән танышу мөмкинлеге табылмады. Ә Брестны, бик аз микъдарда булса да, татар каласы, татар ирләренең каһарманлык үзәге дип саныйм. Чөнки 1941 елның июнь-июль ае дәвамында Брест крепостен татар майоры Петр Гаврилов җитәкчелегендәге гарнизон калдыгы бер адым да артка чигенмичә һәм Австрия солдатларының тулы бер дивизиясенә каршы кан коеп саклаган. Мондый изге урынга барып баш ию – үзе үк зур савап, шуңа күрә бер дә икеләнмичә ерак юлга чыктым.

● Брест крепосте үзәгенә куелган Хәтер һәйкәле.

Юлда иксез-чиксез Россиянең Чуаш Иле, Түбән Новгород, Владимир, Мәскәү, Смоленск өлкәләре аша үтеп китәсе бар. Смоленск каласыннан 200 чакрым чамасы узгач кына Белоруссия чиге башлана. Шушы чик сызыгыннан Брестка кадәр 630 км ара. Моны Белоруссиянең Польшага кадәр сузылган буе дип аңлагыз. Ә Литвадан Украинага кадәр сузылган киңлеге 350 чакрымнан да артмый. Белоруссиянең бөтен мәйданы 207 мең кв.км тәшкил итә. Безнең Татарстаннан төп-төгәл 3 мәртәбә зуррак. Ә Татарстан белән Башкортстанны кушып куйсак, мөселман иленең мәйданы белорусларныкыннан 11 мең кв.км га күбрәк тә булачак икән әле.

Шушы мәйданда 9 млн да 200 мең чамасы кеше гомер итә. Башта ук кисәтик, Белоруссия – ул Бөек Ватан сугышында иң зур һәм иң коточкыч михнәт күргән төбәк. Сугыш барышында Белоруссиядә һәр өч кешенең берсе һәлак булган. Гитлер гаскәре бәреп кергәннән соң Советлар илендә 70 мең колхоз юкка чыгарылган булса, аларның 28 меңе – Украинага, 20 меңнән артыгы – Белоруссия җирләренә туры килә. Минск каласындагы йорт һәм биналарның 80 проценты җимерелеп беткән, алар мәркәзләрен өр-яңадан, нигезенә кадәр үзгәртеп калкытканнар. Минскиның үзендә коточкыч сугышны хәтерләтүче бер генә хәрабә дә юк, ул – искиткеч гүзәл, мең төрле архитектура үрнәге булган, Европа калалары белән ярыша алырдай, тоташ яшеллеккә күмелгән һәм сыңар гына чүп кисәге дә эзләп таба алмаслык гаҗәеп чиста, мәдәниятле шәһәр!..

Безнең делегацияне Витебск өлкәсенең Дубровно район үзәгендә каршы алдылар. Биредә нәкъ үзәктә Фәрит Яруллин исемендәге сәнгать мәктәбе бар, янында каһарман композиторыбыз хөрмәтенә бюст та куелган, аның нигезенә без чәчәкләр салдык. Үзәктә булдырылган тарих музееннан тыш, районның совет сугышчылары, шул исәптән Ф.Яруллин да җирләнгән Рыленки һәм Копти мемориал комплексларында, өлкә үзәге Витебск каласында һәм анда партизаннар отряды командиры Минай Шмырев хөрмәтенә корылган музейда булдык. Шул

● Көнчыгыш форттагы штаб бүлмәсенә куелган П.Гаврилов портреты.

● Брест каласының гарнизон зиратында П.Гаврилов кабере өстенә куелган һәйкәл.

● П.Гаврилов соңгы көннәрендә яшеренеп яткан ат лапаслары.

Мосафир сәфәрдән кайтты

● Татарлар делегациясе Рыленки мемориал комплексы янында.

кичтә үк Минск каласы янындагы спорт лагерена барып урнаштык, икенче көнне «Мәскәү йорты» дип аталган үзәктә конференция уздырдык. Өченче көндә Минскидан 22 чакрымдагы Волковичи авылы зиратына җирләнгән капитан Әдһәм Кәримов хөрмәтенә булдырылган мемориалны ачуда катнаштык, мәркәзнең тарихи урыннары һәм Җәмигъ мәчет белән таныштык. Дүртенче көндә, ниһаять, каһарман Брест крепостена сәяхәт кылдык. Хронологик тәртип җентекле бәянне менә шушы ноктадан башлауны таләп итә.

Брест крепосте 181 ел элек, ягъни 1842 елда ук нигезләнгән. Мәйданы гаять киң, безнең Казан Кремленнән ким дигәндә биш мәртәбә зуррак. Крепостьны көнбатыш яктан Буг елгасы саклый, көнчыгыш яктарак Мукавец елгасы да кирмән мәйданын икегә ярып уза. Менә шушы ике елга уртасындагы утрауга крепость гарнизоны ике катлы кирпеч казармалар корып урнашкан. Алар дуга кебек җәелгән, ә нәкъ уртада Ак Сарай дип аталган затлы бина торган. 1914 елда башланган Беренче бөтендөнья сугышын туктату максатында Ленин-Троцкий хөкүмәте белән Германия вәкилләкләре менә шушы Ак Сарайда очрашып, Брест-Литовск яки инде халык теленә «Хурлыклы» аты белән кергән солых төзергә мәҗбүр булган. Әгәр бүген Минск белән Брест арасы 355 км булып исәпләнсә, Ленин хөкүмәте Минскига кадәр фәкать 30 чакрым гына ара калдырып, көнбатыш өлешне, шул исәптән Брест каласын да немецлар кулына бирергә мәҗбүр булган. Дөрес, немецлар 320 чакрым киңлектәге барча мәйданны шундук поляклар кулына тапшырган. 1939 елның 17 сентябрендә Гитлер гаскәрләре инде Брест каласын да яулап алган булган. Мәгәр әле шушы яу алдыннан гына Риббентроп һәм Молотов имзалары куелган «Һөҗүм итешмәү турында пакт» төзелгән бит. Ә аның буенча Польшаның көнчыгыш өлешен Сталин яулап алырга тиеш, дип килешенгән. Шул сәбәпле 17 сентябрьдә Брест каласына совет гаскәрләре дә килеп җиткән һәм «пакт шартларын саклау хакына» немец гаскәрләренә кире чигенергә туры килгән. Ягъни, 1939 елның сентябрендә Брест крепосте янә совет гаскәрләре кулына кайтарылган. Шуннан соң инде крепостька 6-7 полк һәм «броняга төренгән» танклар дивизионын кертеп урнаштырганнар. Мондагы гаскәр гомумсаны белән 15 мең солдатка тулса да, 1941 елның нәкъ 20 июнендә андагы 9 меңгә якын солдат «хәрби өйрәнүләргә» дип крепостьтан яланга чыгарылган. Имчәк балаларын һәм карт-корылар, ат караучылар, мич ягучыларны кушып исәпләгәндә дә, крепость эчендә 7-8 мең генә кеше торып калган.

Буг елгасы аръягындагы Польша җирендә 190 дивизия дошман, шул исәптән дистәләгән танк колонналары килеп урнашуны күрми-сизми калса, совет разведкасы сукыр булыр иде. Әлбәттә, күргәннәр һәм Мәскәүгә дә ошбу хакта рапорт юллаганнар. Әмма өстән катгый фәрман төшкән: «Бу – немецларның хәрби өйрәнү үткәрүе генә. Безнең арада «Молотов-Риббентроп пакты» бар. Бернинди дә провокацияләргә бирешмәскә!» 22 июньгә каршы төндә Буг елгасы аша совет гаскәрләре ягына йөзеп чыккан немец ефрейторының кисәтүен дә чынга алмаганнар. Ә таң беленә башлауга, Буг аша инде кораллы солдатлар утырган көймәләр һөҗүмгә ташланган, иртәнге дүрттә крепость өстенә дистәләгән тонна снаряд яуган. 1939 елда гына бирегә берләштерелгән хәрби өйрәнүләр, хәтта немец һәм совет полкларының берләштерелгән хәрби парадлары да үткәрелгән бит, крепость корылышын немец тупчылары яттан белеп торган, гитлерчылар совет солдатлары каршылыгын бер һөҗүм барышында ук юкка чыгару турында хыялланган.

Әйе, чынында да, гитлерчылар һөҗүмен совет сугышчылары явыз сугыш дип уйга да китермәгән. Әмма беренче атака барышында ук йөзләрчә һәм меңнәрчә совет солдаты казармаларыннан чыгып өлгермичә дә һәлак булган. 44 нче укчы полк командиры Петр Гаврилов та һөҗүм башында ук көнчыгыш фортларны саклауга ташланып, үз сугышчыларының төп өлешеннән аерылып калган. Көнчыгыш фортка төрле полк һәм дивизион калдыклары җыелган, хәрби дәрәҗәсе буенча иң югары булганга, алар майор Гавриловка буйсынган. 8 сәгать эчендә юк ителергә тиешле гарнизон 29-30 июньгә кадәр дошманга тын алырга бирмичә дә сугышкан. Көнбатыштагы Буг елгасы аша төзелгән күпер өстеннән хатын-кыз һәм бала-чагаларны куа-куа, немецлар шуларга ышыкланып та һөҗүм итеп караган. Аптырагач, фашист гаскәрендәге 60 см юанлыктагы, 2200 кг лы снарядлар ата торган мортиралар белән крепость ныгытмалары өстенә аждаһадай ут ачкан. Хәрбиләр крепость эчендәге тыныч халыкны немец-австриялеләр кулына куып чыгарган, әмма каршы торуны барыбер туктатмаган. Шуннан соң инде «Үзәк» армияләр төркеме башлыклары Көнчыгыш форт өстенә самолетлардан 1800 кг лы бомбалар ташлаттырган. Снарядсыз, патронсыз калган 389 совет солдаты дошман кулына бирелергә мәҗбүр булган. Нindидер ялгыз ату тавышын ишетеп һәм аның хуҗасын таба алмаганга күрә, немец генераллары Гитлерга «форт башлыгы үзен-үзе атып үтерде», дигән рапорт юллап өлгергән. Асылда исә майор Гаврилов балчык вал аша Көнчыгыш форттан атлар лапасына таба шуышып чыккан. Шунда атлар өчен әзерләнгән солы ашап һәм ур артындагы инештән су эчеп үз-үзен саклаган һәм 23 июльгә кадәр дошманга бирелмичә һәм вак-вак һөҗүмнәр оештырып, һаман каршы торган. Төннәрдә ниндидер ыңгырашу тавышын ишетеп, гитлерчылар аның янына тоткынлыкка төшкән бер совет солдатын юллаган, тегесе: «Немецлар Минск каласын алды, алар хәзер Смоленск каласына һөҗүм итеп ята», – дип үгетләп тә караган, Гаврилов бирешмәгән. 23 июль көнне генә аны гитлерчылар һушсыз көе әсирлеккә алган. Ә аннары – дистәләгән лагерьларда тоткынлык. Ни гаҗәп: гитлерчылар лагерьларда совет тоткыннарына аны «үлми торган кеше» дип таныштырган, хәтта чеметеп карарга да тәкъдим иткән әле...

Партиягә кергән чакта тутырган документларында үзен фәкать «татар» дип кенә күрсәткән Гавриловны 1945 елда америкалылар коллыктан азат иткән. Ни галәмәт, «смерш»ныкылар тоткын майорга әллә ни бәйләнеп маташмаган, аңа хәрби дәрәҗәсен кайтарганнар һәм Иркутскида япон тоткыннары өчен төзелгән концлагерь башлыгы итеп озатканнар. Гаиләсен немецлар бомбага тоту вакытында юкка чыккан дип санаучы Гаврилов яңа бер марҗага өйләнгән, үз балалары булмаганга күрә, ятимнәр йортыннан Николай атлы бер малайны тәрбиягә алган.

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.

Автор фотолары.

● Волковичи зиратында капитан Ә.Кәримов истәлегенә корылган мемориалны ачу тантанасы.

● Вязьма каласында 1630 елда төзелгән һәм барча сугышларны да кичереп исән калган башня.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ҮЛЕМЕ

Акмулланың фаҗигале вафаты һәм аны соңгы юлга озату

Газетабызның быелгы санында басылган мәкаләбездә мәгърифәтче шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың (1831–1895) фаҗигале вафаты һәм аны соңгы юлга озату мәрасиме хакында аерым махсус мәкалә багышларга вәгъдә ителгән иде. Һәм без аны башкарып, укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.

Бу аянычлы вакыйга хакында зур булмаган хәбәр әүвәл тарихчы, филолог һәм журналист Габделбари Баттал (1880–1969) тарафыннан төзелеп, 1904 елда Казанда бастырылган «Акменла әфәндeнең иншад итдеге мәнзумәтилә башка бер кач мәншәдатыны вә кәндесенең тәрҗемәи халене мөштәмил мәҗмугадер» дигән китапта китерелә. Ул шагыйрьнең үлем фаҗигасен бәян итеп, җинаятьнең Уфа вилаяте (губернасы. – Р. И.) Златоуст өязе Мәчетле авылының Гафиятулла Байморад угылы һәм Шәриф авылының Дәүләтшаһ тарафыннан башкарылуын яза. Галим шулай ук мәрхүмнең җеназасын Миасста хәзердә (ягъни китап нәшер ителгән вакытта – Р. И.) имам һәм мөдәррис булган Сәлахетдин бине Сахипзадә әл-Әнкәби укуын белдерә. Әлеге мәгълүмат алга таба башка чыганакларда да артык үзгәртүләрсез урын ала һәм әйтелгән дин әһеленең исеме дә очраштыргалап куя.

Г. Батталның Акмулла белән кызыксынуының нигезле сәбәпләре булса кирәк. Чөнки ул Троицк шәһәре мәдрәсәләренең берсендә белем ала, 1911–1912 елларда шунда ук укыта.

Үткән елда безнең тарафтан төзелеп «Рухият» хәйрия фонды тарафыннан нәшер ителгән «Мифтахетдин Акмулла: тормыш юлы һәм иҗаты» дигән китапка шагыйрьнең казах шәкертләреннән берсе булган Дусмаил Качкынбаев истәлегенең тулы тексты да урнаштырылды. Дөрес, ул фәндә билгеле булса да, моңа кадәр дөнья күргән хезмәтләрдә аннан өземтәләр генә китерелгән иде. Бу истәлек Акмулла турында белгәннәребезне тагын да киңәйтә, яңа мәгълүмат белән баета. Шул исәптән билгеләнгән темага да шактый ачыклык кертә. Шунысын да әйтергә кирәк, Д. Качкынбаев шагыйрь турында мәгълүмат туплый башлавын «Вакыт» газетасының 24 апрель санында бастырган «Шагыйрь Акмулла хакында» дигән мөрәҗәгатендә белдерә. Аерым алганда, ул анда шулай белдерә: «Мәшһүр шагыйрь Акмулланың тәрҗемәи хәлен һәм матбугатка кермәгән шигырьләрен җыеп тәртип итеп бастырмак буламын. Мәрхүмнең тәрҗемәи хәлен мөкәммәл һәм дөрест итеп язу өчен анда асыл ватанындагы агай, энеләренә һәм бу вакытта терек калган гасырдашларына үтенеп мөрәҗәгать итәмен: Акмулла мәрхүм безнең бу якка килгәнче, ягъни 24 яшенәчә булган хәлләре язып йибәрергә үтенәмен...». Алай гына да түгел, ул Акмулланың якташларына, Себер тарафындагы казахларга аерым мөрәҗәгать итә.

Истәлегеннән күренгәнчә, Д.Качкынбаев Акмулла турында күп мәгълүмат туплаган. Шуңа күрә, шагыйрьнең фаҗигале вафаты һәм аны соңгы юлга озату вакыйгасы да, башка чыганаклардан аермалы буларак, шактый этрафлы тасвирланган:

«Мин дә бу елны, 1895 нче елны, 15 үктәбердә ишан хәзрәт мәдрәсәсенә (Троицкидагы Зәйнулла Рәсүли мәдрәсәсенә – Р. И.) килеп тә йиттем. Килгәч, хәзрәт ахшамнан чыкмаган икән. Чыгуына мәчет алдында көтеп, хәзрәткә күрешкәнемдә хәзрәттән: «Дусмаил, Акмулланы Миәстә Сарастанда кеше үтереп киткән, дип, яңа пристав килде, аның якыннары бармы, дип, сорашты», – дип миңа ишеттерде. Мин дә «Раҗигун» аятен укып, нишләргә белми калдым. Мәрхүм әлеге сукыр Хуҗай мулла илә ул кызга ничә мәртәбә барса да, һич бер дә туры китерә алмай, сукырны өенә китереп ташлап, яңадан барырга чыгып, Сарастан стансасында бире бер тегермән булып, ул тирмәннән бире бер елга буенда атын ашатырга куеп, үзе шәм ягып китап карап утырганда аңсыздан ике угыры килеп, карнын пычак белән ярып үтереп. Ике атын, киемнәрен вә гайре нәрсәләрен алып, теге агып яткан җылгага ташлап киткәннәр (Каулә иннә иләйһи вә иннә лиләйһи раҗигун). Биш көн үткәннән соң Миәс һәм Златоуст тарафыннан балаларын мәдрәсәгә китергән башкортлардан сорашып, аның калаенча дәфен ителгәнен сорап мәгълүмат ала башладым. Башкортлар бу тарикъ илә (бу рәвешле – Р. И.) сөйләделәр: «Әүвәл шул елга буенда ничә мәртәбә кунып һәм көндез ат ашатып «Шул тирмән янындагы җылгада ат ашатуга һичбер җир күрмәдем», дип. Иртәгесен тирмәннең маллары чүп (печән – Р. И.) ашарга чыкканында җылгадан су эчкәнендә мәетне күреп, сыерлар үкереп-бакырып ятканында сыер көтүчесе килеп караса, су эчендә бер кеше үлеп ятканын күреп, хуҗасына әйткән. Хуҗасы да Миәстәге приставка килеп мәгълүм итеп, пристав килеп караса, мәшһүр Акмулла икәнен танып, арбасы илә калган нәрсәләрен алып, Миәснең каравыл өенә китерделәр. Китереп куеп, һәр якка публикация иткән 3–4 көннән соң әкъръбәсе (якын туганы – Р. И.) мин дип, һичкем килмәгәч, начальстволар мөселманнар кулына биреп, Миәстәге Сәлах хәзрәт үзенең ике шәкертенә юдырып, мөселман мәкъбәрәсенә (каберлегенә – Р. И.) дәфен иттергән (рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васыйгатән).

Кыш урталарында ишан Зәйнулла хәзрәт таш яздырып, Троискида мәгълүм бәдәлче (ялланып, башка кеше өчен хаҗга баручы – Р. И.) Һади хаҗига алып баргызып башына куйгызган (мин дә 1900 нче елны 6 нчы июльдә хаҗдан кайтышта Миәс стансасында төшеп, остаз мөбарәккә зиярәт итеп, Корьән укып, рухы галиясенә багышлап, каберендә бераз утырып, яңадан вагонга утырып киттем). Шул [18]95 нче елны Акмулланы юган Сәлах хәзрәтнең ике шәкерте ишан мәдрәсәсенә килеп торды.

Берсе Шакир исемле – Самар губернасы, икенчесе Кәбир исемле – әүвәлдә Нургали Буави хәзрәт шәкерте икән. Болардан сораштым калаенча юганнарын. Болар әйттеләр: «Без юарга барсак, караулкада такта өстенә яткызып куйганнар икән. Бер кулы илән карынын тотып катып калган. Дәхидә бер аягын яурынына ябешеп һәм эче пычак илә ярылган урыныннан йодрык хәтле мае чыгып тора икән, – дип.

Шуннан соң су коеп юа башлаган соң кулы илә аягы җебеп сузыла башлады. Аяк-кулларын тәмам урынына куеп, чыккан маен да кайтадан урынына салып тегеп куйдык», – диде.

Бер көнне мәдрәсәдә утырганымда Акмулла мәрхүм үлгән вакытларында Кыйгы (хәзерге Башкортстан Республикасының Кыйгы районында Югары Кыйгы (район үзәге) һәм Түбәнге Кыйгы дигән авыллар бар. Текстта аларның кайсы хакында сүз барганлыгын ачыклау мөмкин түгел – Р.И.) тарафыннан, атын оныттым, Минһаҗмы, Гыйлаҗимы инде, Акмулланың бик дустларыннан иде, мин дә аны күргәч, күземнән яшь чыгып: «Йә агай, Акмулла кайда, кай вакытта үлгәнен ишеттең вә кемнәргә ишеттердең?» – дидегемдә, бичара агай да күңеле йомшарып, күзләре яшәреп: «Мин бераз кешедән борын ишеттем», – диде.

Ишетү белән Залатаустка барып, Бәсимевкә юлыкмакчы булып бара яткканда Бәсимев урамда катайт итеп йөри икән. Алдында торып сәлам биргәч: «Йә, ни йомыш, ни хәл?» – дидегендә, мин дә: «Хәл бер төрле, әфәндем, Акмулланы Сарастанда кеше үтереп киткән, дигәнемдә ап-ак булып каны китеп, төсе бозылып: «Үтерүчеләр табылмадымы?», – дидегендә, «юк» дидем. Алайса, аны үтерүчене дөньяның өстендә булса, миңа табу лазем булсын, дип атын юргызып өенә кайтты», – диде.

Моннан соң күпкә бармай, алар тотылып хибескә ябылган. Аларның кем икәнлеге һәм җәзалары Габделбари әфәндeнең язганнарында мәгълүм. Ул мәлгуннәр илә хибестә бергә яткан казакъ бурларыннан Әлмөхәммәт морза Булат угылы дигән казакъ сөйләп йөргән, дип ишеткәнем бар:

«Без Акмулланы әүвәлдән саклап йөрсәк тә, рәтен китерә алмай идек. Бер көнне Сарастаннан эчеп кич белән килә ятканыбызда ялтыраган утка килсәк – әлеге саклап йөргән Акмуллабыз икән. Күргәч, кызыктык та, иттифакый (бергә – Р. И.) бардык та эчен ярып үтереп, атлары илән затларын алып, бары 25 тәнкә акчасы бар икән, шуны алып киттек», – дип, әйткәнен».

Күренгәнчә, бу канлы вакыйга җәмәгатьчелектә киң яңгыраш алган. Дәүләтнең тиешле оешмалары да мәсьәләгә житди караган. Туганнары килмәсме дип әүвәл тирә-якка хәбәр бирелгән. Өяз полициясе вәкиленең үтерүчеләрне табуны үзенең хезмәт вазыйфасы буларак кына түгел, ә намус эше итеп каравы да күп нәрсә турында сөйли. Нәтиҗәдә җинаятьчеләр тотылып, төрмәгә ябыла. Приставның Акмулланы тануы, шагыйрьнең ул якларда яхшы таныш булганлыгына тагын бер дәлил.

Туганнары димәктән, Д. Качкынбаев истәлегеннән күренгәнчә, 1896 елның кышында Акмулланың бертуган энесе Әхмәди һәм тагын бер кеше шагыйрьдән калган мирасны алырга Троицкига килә. Башта алар Тау Карагайдагы Мыктаган дигән казакъка барып, анда сакланган әйберләрен һәм китапларын алып кайталар. Аннары З.Рәсүли, мәрхүмнең исән вакыттагы васыяте буенча, китапларын өчкә бүлеп, тиешле булганнарын Әхмәдигә бирә.

Бу хосуста Р. Фәхретдинов шундый мәгълүмат китерә: «Акмулланың Әхмәди исемендә энесе Туксанбай авылында гадәти кешеләрдән булып тереклек итәдер. Акмулладан калган бар кадәр байлыкны җыеп алып кайтты, диделәр. Шул җөмләдә китаплары вә мөҗәммегъләре, язулары һәм дә бер чапаны, шәһид ителгән вакытында өстендә булган ак төстә бишмәте булып, бу бишмәтендә үлтерүчеләрнең хәнҗәр берлә санечкән урыннары булганлык та ишетелде».

Аңлашыла ки, Д. Качкынбаев Троицкига Акмулланы җирләгәннән соң якынча 2–3 көн үткәч килгән булып чыга. Шуңа күрә мәгълүматны вакыйганы тәгәл белүчеләрдән алган. Ләкин мәрасемнең ничек башкарылуын, җеназа намазын кем укуын һ. б. турында белешмә китерми. Остазы-

ның каберен шул вакытларда ук зиярәт кылганмы-юкмы, бу да билгесз. Әмма, үзенең хәбәреннән күренгәнчә, 5 елдан соң ул аны бик җиңел тапканга охшый.

Чыганакларда еш телгә алынган Сарастан исә электә Урал казаклары (казачийлары) яшәгән рус авылы. Казах галиме Б. Кенжебаев үзенең хезмәтләрендә, нишләптер, Акмулла шунда җирләнгән дип яза. Аның бу фикере Б. Исхаков тарафыннан да кабатлана.

1924 елда Акмулланың үлүенә 30 ел тулу алдыннан «Башкортостан» газетасының 27 сентябрь санында фольклорчы Сәгыйть Мирасов (1880–1932) «Акмулла» дип аталган мәкаләсендә җинаятьнең Исәнгилде исемле казах старшинасының дусты башкорт старшинасы Буранголның кушуы буенча башкарылуын язып, сәбәпне төрле социаль катлауларның үзара көрәшенә кайтарып калдыра. Бу тенденция алга таба да дәвам иттерелә. Мәсәлән, язучы, әдәбият белгече һәм туган якны өйрәнүче Александр Шмаков (1909–1989): «Күрәсең, шагыйрьне патша власте һәм аның чиновниклары үтерткәндер, ә юлбасарлар һөҗүме турындагы уйдырма чын үтерүчене яшереп калдыру өчен кирәк булгандыр», – дип яза. Әдәбиятчы Мәсгуть Гайнетдинов болай ди: «Акмулла җирле түрәләргә каршы юнәлдерелгән ниндидер бер оппозицион хәрәкәт тәэсирендә булган булса кирәк».

Д.Качкынбаев истәлегеннән күренгәнчә, бу берницы дә «заказлы үтерү»гә охшамаган, җинаятьчеләр шул чорның гап-гади юлбасар угрылары. Язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Галинең (1893–1952) дә фикере шулай. Әмма шунысы билгеле – мондый җинаять өчен юл туп-туры гомерлек каторгага.

Истәлектә шагыйрьнең каберенә таш куйдыру мәсьәләсенә дә ачыклык кертелә. Аны Зәйнулла Рәсүли яздыртып әзерләткәнлеге инде мәгълүм иде. Ә аны илтеп куючы игелекле затның Һади исемле хаҗи булганлыгын беренче мәртәбә беләбез.

Акмулланың кабере 1959 елда язучы һәм галим Кирәй Мәргән (Кирәев Әхнәф Нури улы, 1912–1984) җитәкчелегендәге гыйльми экспедиция тарафыннан ачыклана һәм бу хакта ул матбугатта мәкалә бастыра. Анда кабер ташының аерым, аның янында үзе дә сурәтләнгән фотолар да урнаштырыла. Бу шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен өйрәнү юнәлешендә зур вакыйгаларның берсе була. Чөнки, беренчедән, аның табылуы үзе зур әһәмияткә ия булса, икенчедән, кабер өстенә куелган ташның яхшы хәлдә саклануы әдип турындагы мәгълүматны тагын да тулыландыра. Ташта уйма ысул белән язылган текст шулай:

Къэтле шәһидән
сәнәти 1313-нче фи сәманийәти
җөмадәл-уля фи ләйләти үл-җөмга
мулла Мифтахетдин әл-мәгъруф
би Акмулла ибне Мөхәммәдьяр хәлфә
нәсәбән вә ибне мулла Кәмалетдин
тәрбиятән. Тәммә, тәммә.
(Шәһидләрчә үтерелгән,
1313 [һиҗри] елда сигезенче
җөмадиәл-әүвәлдә, җомга көне кичен
Акмулла исеме белән билгеле мулла Мифтахетдин,
нәсел буенча атасы Мөхәммәдьяр хәлфә, тәрбия буенча
атасы мулла Кәмалетдин. Тәмам, бетте)

Бу мәгълүмат Д.Качкынбаев истәлегендә дә бар. Ул аны язып алгандырмы, яки хәтерендә калганча китергәндерме – мәгълүм түгел. Чөнки анда зур булмаган кайбер төгәлсезлекләр күзәтелә.

Тарихчы галим М.Госманов (1934–2010) 1980 елның җәендә, археографик экспедиция вакытында Акмулланың каберен

● Саләхетдин Бәширов.

зиярәт итеп, ташны яңадан тикшереп укып чыгуларын яза. Ул шулай ук аның сурәтен дә алдыра.

К.Мәргән мәкаләсеннән аңлашылганча, алар каберне үзләре эзләп тапкан. М. Госманов та аның ничек табылуы хакында мәгълүмат китерми. Бу уңай белән шундый урынлы сорау барлыкка килә: Миасс шәһәрендә яшәүче татар һәм башкорт җәмәгатьчелегендә шагыйрь каберенең зиратта тәгаен кайдалыгы буыннан-буынга тапшырылып килмәдеме икәнни? Ничек кенә булмасын, таныш булмаган зиратта нинди дә булса каберне аны белгән җирле кешедән башка табу бик үк мөмкин булмаганлыгы билгеле факт.

Әйтергә кирәк, таштагы текстның эчтәлеге Р. Фәхретдиновка мәгълүм булган булса кирәк. Бу хакта ул шулай яза: «Моның кабере өстенә шәех Зәйнулла хәзрәтләре исем вә нәсәбене һәм дә тарих вафатыны яздырып таш утырттыды, диләр». Нәкъ шундый ук мәгълүматны Г. Баттал да китерә.

Акмулланың тууына 150 ел тулу уңае белән аның кабере өстендә төзекләндерү эшләре башкарыла. Ләкин шул вакытта андагы элекке таш алынып, Миасс шәһәренең туган якны өйрәнү музеена куела. Шагыйрьнең 175 еллык юбилеенда ул янә үз урынына кайтарыла.

Акмулланың җеназа намазын укып, аны соңгы юлга озаткан шәхесләрнең берсе булган Сәлахетдин әл-Әнкәби кем соң ул?

Бу шәхес, чыганаклардан күренгәнчә, 1862 елның 29 сентябрендә Сембер губернасының Атабай-Әнкәбә авылында крестьян гаиләсендә туган. Буа шәһәрендә 1 нче Җамигъ мәчет каршындагы «Нурия» мәдрәсәсендә танылган дин галиме, мәгърифәтче педагог Нургали Хәсәновта (1852–1919) укый, дини белем ала. Аның Миасс якларына барып чыгуы, барыннан да элек анда мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан анда мәчет төзелү белән бәйле.

Билгеле булганча, мөселманнарның үтенече буенча, Оренбург Губерна идарәсе 1891 елның 18 октябрендә Миасс заводында Җамигъ мәчет төзергә рөхсәт бирә. Бу күркәм һәм саваплы эшне башкару өчен Троицк шәһәренең 2 нче гильдия сәүдәгәре Галиулла Уразаев (1842–1910) ярдәмгә килә. Ул мәчет һәм башка каралтылар өчен җир сатып ала. 1894 елда Аллаһ йорты файдалануга тапшырыла.

Шәһәр мөселман җәмәгатьчелегенең вәкаләтле вәкилләре Шакирҗан Әдеһәмов һәм Хәйретдин Солтанов Сәлахетдин Бәшировны мулла итеп сайлау турында мәхәллә халкы тарафыннан җыйган приговорны губерна хакимиятенә җиткерәләр. Уфа шәһәрендә Диния нәзарәтендә тапшырган имтихан нәтиҗәсендә Губерна идарәсенең 1894 елның 20 декабрендә имзаланган 1268 санлы карары нигезендә ул Җамигъ мәчетекә ахун, имам-хатыйб һәм мөдәррис итеп билгеләнә.

Журналист Фәрит Фаткуллин «Кызыл таң» газетасының 2006 елгы 14 сентябрь санында бастырган «Азия белән Европа чигендә» дигән мәкаләсендә С. Бәширов турында сүз алып барып, шулай яза: «...Акмулла турындагы китапларда Бәширов фамилияле мулла телгә алына. Заманында ул Франциянең Сорбонна университетын тәмамлаган тирән белемле, бай китапханә тоткан шәхес булган. Миасстагы мәчетне дә ул салдырган, шәһәргә килгәндә Акмулла шул муллага фатирга төшә торган булган. Күптән түгел шул мулланың фоторәсемен һәм оныгын тапканнар». Бу мәгълүматның күп өлешен расльй, яки кире кага торган чыганаклар әлегә безнең карамакта юк. Һәрхәлдә, ул әйтелгән югары уку йортында белем алган булса, заманында аның юридик факультетын тәмамлаган Садри Максуди, физика-математика бүлеген тәмамлаган Сара Шакулова кебек күптән мәгълүм булыр иде.

Дөрес, ул китаплар да язган, наширлек эше белән дә шөгыльләнгән. Әйтик, аның «Бәянел-Хикмәт моталәга» китабына иң югары шәрех» исемле хезмәте 1892 елда Казанда басылып чыккан.

Кайчандыр Ш. Мәрҗанинең кайбер фикерләре белән килешмәвен ачыктан-ачык белдергән Н. Хәсәновны тәнкыйтьләп, аңа аерым шигырь багышлаган Акмулланы соңгы юлга озатучылар арасында соңгысының шәкертләре булуы язмышның бер гыйбрәтле күренеше булса кирәк.

Безгә үткән елның 25 октябрендә Миасс шәһәрендә Төбәкара II Акмулла укулары конференциясе эшендә катнашырга туры килде. Әлеге чара вакытында өйлә намазыннан соң Акмулла каберен зиярәт итәргә һәм киң җәмәгатьчелек белән берлектә аның рухына дога кылырга насыйп булды.

Шулай итеп, Акмулланың фаҗигале вафаты һәм аны соңгы юлга озату вакыйгалары, аларга бәйле кайбер шәхесләр турында әлегә кадәр билгеле булмаган яңа мәгълүмат белән таныштык. Шагыйрьнең тормыш юлын өйрәнү юнәлешендә бу мөһим әһәмияткә ия.

Рәмил ИСЛАМОВ,
филология фәннәре докторы

Атнаның сәяси мизгелләре

Юмакайлык галәмәте

Узган җомгада дин кардәшләребез Ураза гаетен бәйрәм итте. Бер карагандa, сәясәткә моның берниндй дә катнашы юк кебек. Әмма, мәчетләрдә урын җитмәү сәбәпле, күп кешеләрнең гает намазын ишегалдында һәм урамнарда кылырга мәҗбүр булуы инде Аллаһ йортларының җитешмәве турында сөйли. Мондый хәл Мәскәүдә аеруча нык күзгә чалына. Чиркәү һәм мәчетләр нисбәтендә диспропорция анда ачык күренсә дә, башкалада төзелергә тиешле мәчетнең нәсара динендәге агрессив төркем ризасызлыгы нәтиҗәсендә урыны үзгәртелүе җәмгыятьтә төрле диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрнең сәламәт булмавы турында сөйли. Дөрес, ниндидер компромисс табылды да кебек. Әмма андый компромисслар нигәдер һәрчак берьяклы килеп чыга.

Игътибарны җәлеп иткән икенче нәрсә – татар теленә мөнәсәбәт. Кайчандыр Урталык җирләрендә гасырлар буена милләтара аралашуның төп чарасы булып хезмәт иткән татар телен бүген инде мәчет-мәдрәсәләрдән дә кысрыклап чыгару сәясәте үткәрелә. Дөрес, аны мәктәп-гимназияләрдән кугандагы кебек, мәчетләрдә прокурорлар инде йөрми дә шикелле. Әмма, бу җирләрдә мәчет-мәдрәсәләрдә кайчандыр традицион төстә татар һәм гарәп телләре кулланылган булса да, хәзер тавыш-тынсыз гына, татар теле урынына урыс телен индерү бара. Әйе, Татарстанда әле, гает хөтбәләрен татарча алып бару саклана да кебек. Тик бериш имамнар анда да вакыт-вакыт урысчага «салулап» ала.

Әлбәттә, исламны урыс теленә күчерүдә соңгы елларда бу телдә күпләп житештерелә торган видеороликлар вә язмалар да зур роль уйный. Урыс телле аудитория өчен алар, әлбәттә, бик кирәк. Әмма бериш надан милләттәшләребез социаль челтәрләрдә алар белән саф татар тәрҗемәнләрен дә тутыра. Ә инде үзенең татарга «иблис хезмәте» күрсәтеп, Аллаһ тарафыннан бирелгән газиз ана телебезнең кулланыш даирәсен ата-бабаларыбыздан мирас булып калган хак динебездә дә тарайтуының нинди зур гөнаһ булуын андыйлар каян аңласын?

Атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. Россия тышкы эшләр министры С.Лавров Латин Америкасы илләренә турне вакытында Бразилия, Венесуэла, Никарагуа һәм Кубада үткән очрашуларда катнашкан. Белгород каласы өстеннән очып барган Су-34 хәрби очкычыннан, зур егәрле бомба ычкынып китеп, урамнар чатына төшүе нәтиҗәсендә, диаметры 20 метрлы чокыр барлыкка килгән һәм тирә-юнь йортларга зур зыян салынган. «Зур җиделек» илләре лидерларының майда узачак очрашуында Россиягә экспортны тулысынча диярлек тыю турында карар кабул итәргә җыенулары мәгълүм булды.

С.Лавров БМО КШда «БМО уставы принципларын яклау аша нәтиҗәле күпкырлылык» дигән темага үткәрелгән ачык фикер алышуларда рәислек иткән һәм, Украина мәсьәләсен геосәяси контексттан аерып карарга ярамый, дип белдергән.

Фоат УРАЗАЙ.

Сөембикә манарасы башындагы кара кош сурәтен алу

Укучыларны Нәкый Исәнбәт архивында табылган яңа чыганак белән таныштырырга булдык. Аның эчтәлеге Хөсәен Габдүшнең 1939 елда Харбинда язган «Үзебез өчен» хикәясенә аваздаш булганы ачык күренә. Бу талантлы инсанның әсәре 1974 елда Төркиядә «Kazan» журналында басыла. Н.Исәнбәт үзенең чыганагын Җәгъфәр Садыйкның кульязма дәфтәреннән 1975 елның 1 октябрендә күчерә. Җәгъфәр Садыйк Мамедов – XX гасырның 60-70 елларында Бакуда яшәгән милләттәшебез. Ул «Ибн Фадлан сәяхәтнамәсен 1960 еллар ахырында татар теленә гарәпчәдән тәрҗемә иткән. Хезмәтенең бер өзеге Н.Исәнбәт тәкъдиме белән «Казан утлары» журналында дөнья күрә (1972. № 8).

Композитор Мәсгудә Шәмсетдинова архивында Ильясова Наҗия Таһир кызы тарафыннан тапшырылган кульязма саклана. Ә.Еники хатыны искәрмәсендә бу язманы 15 ел элек Рокыя Гыйльман кызы Сабитовада (1903) сакланган язмадан күчереп алуы турында әйтеп үтә. Аның абыйсы Юныс Мөхәммәд улы Баһавветдинов (Ш.Мәрҗани оныгы) белән бик якын мөнәсәбәттә булуы фактына таянып, Н.Т.Ильясова 1917 елдагы вакыйганы Юнысның абыйсы Габделхәмид Баһавветдинов язган булу ихтимал дип фаразлый.

Башка язмалардан аермалы буларак Н.Исәнбәт кульязмасында вакыйга белән бәйле җитди сөйләшүләр тасвирлана һәм Казан губернасының җәмәгать хәвефсезлеге комиссарының урынбасары Кәлимулла Гомәр улы Хәсәнов роле ассызыклана. Чыганакларны тел ягыннан чагыштырып карасак, инкыйлаб чоры сулышы Н.Исәнбәт язмасында ныграк сизелә, Хөсәен Габдүш белән Н.Т. Ильясова язмалары гади сөйләм теле белән язылганын күрәбез. Өч чыганакта да хәтирәнең авторы кем икәне күрсәтелмәгән. Н.Исәнбәтнең язмасын галимнең искәрмәләре белән бастырырга булдык.

Сөембикә манарасының сәмруглы рәсеме.

Февраль инкыйлабыннан соң рус самодержавия галәмәте булган кара кош (орел) сурәтен бөтен Россия шәһәрләрендә һәркайдан ала башладылар. Шул җөмләдән Казандагы Сөембикә манарасының башында ничә гасырлар торган кара кош сурәте алынды. Кара кошны алу ничек булды?

1917 нче сәнәдә Корбан бәйрәменең өченче көнендә, 16 сентябрьдә көндез сәгать 2 дә Сөембикә манарасы өстеннән кош сурәте алыначагы игълан ителгән иде. Кара кош сурәте бик зур булганлыктан, аны алу өчен хәзерлекләр бәйрәмнән элек үк күренә башланган вә манараның югары тәрәзәсеннән чыгарып балкон ясалган иде. Никадәрле хәзерлекләр алдан күрелеп килгән булса да, кош сурәтен алу эшенә сәгать 2 дә үк керешергә мөмкин булмады, бәлки сәгать 2/4 тә генә ул эшкә керешелде.

«Сәгать 2 дә кош сурәте алына башланачак, дип игълан ителгән булса да, сәгать 12 ләрдә үк Сөембикә манарасы янына халык җыела башлаган иде. Халык артканнан артып, сәгать 2 ләрдә инде анда 15–20 мең кеше җыелды. Бөтен крепость эче уртадан юл калдырылып мөселман солдатлар тарафыннан цепь ясалган иде, цепьнең арты халык белән тәмам тулды.

Кош сурәтен алган вакытта, кирпеч кебек нәрсәләр төшеп бәхетсезлекләр булмасын өчен, халык сабикъ (элекке) губернатор сарае ишек алдына кертелмәде. Анда тик Казан Хәрби Комитеты, Хәрби Шура әгъзалары, манарага менәчәк берничә кеше генә булды. Сәгать 2 дә үк ике оркестр музыка нәүбәтләшеп «Марсельеза» вә башка сәяси көйләрне уйнап торды. Сәгать 3 нче яртыларда бер кызык вакыйга да булып алды.

Губернский комиссар (В.А.Чернышев) бик ашыгыч бер кәгазь җибәреп, ул кәгазендә шундый сүзләрне язган: «Фәрык (аерымлык, партия - Н.Исәнбәт искәрмәсе.) вә милләт мөәссәсәләреннән (учреждения - Н.Исәнбәт иск.) чыккан һичбер әмер мөвәккыйт (вакытлы - Н.Исәнбәт иск.) хөкүмәт тарафыннан муәфәкать (муафикъ күрелү, мәслихәт табылу, килешенү - Н.Исәнбәт иск.) ителмәстән элек гамәлгә куелырга тиеш түгелдер. Революцион хөкүмәтнең бәянәте (бәян итү, аңлату - Н.Исәнбәт иск.) буенча, губерна комиссарлары тарафыннан ризалык алынмыйча эшләнә алмыйлар, хәлбуки Казан Хәрби Комитетының Сөембикә манарасыннан кош сурәтен алырга карар биргә бары безгә белдерелә генә, хәтта бездән бу эшкә муәфәкать тә соралмый. Мөселман комитетының бу (хәзер үк кичектермәстән кош сурәтен алу) хәрәкәтен законга сыймый торган хәрәкәт дип белгәнлектән, хәзер үк кичектермәстән кош сурәтен алу өчен башланган эшне туктатып торырга вә кош сурәтен алып ай куярга карар бирүнең сәбәпләрен тизлектә миңа белдерүне тәклиф итәмен (өскә йөкләтү, мәҗбүр итү, боерып әшләтү - Н.Исәнбәт иск.). Бу мәгълуматларны алганнан соң гына хөкүмәт властьның карарына карап, манарадагы орелны алу мәсьәләсе хәл ителер». Шул вакытта комиссар мөгавины (урынбасар - Н.Исәнбәт иск.) Кәлимулла Хәсәнов (Кәлимулла Гомәр улы Хәсәнов (1878-1948) 1917 елда Казан губернасының җәмәгать хәвефсезлеге комиссарының урынбасары булып хезмәт иткән) килеп, бу эшне кузгатулары белән гаскәриләрнең аны читен хәлгә төшергәнлекләрен хәтта, ихтимал, шуның өчен урынын ташларга да мәҗбүр булачагын сөйләде. Хәрби Комитет вә Хәрби Шура әгъзалары үзләренең фикерләреннән кайтмаячакларын белдергәч: «Мәсъүлиятне (җаваплылык - Н.Исәнбәт иск.) үз өстегезгә аласызмы?» дигән сөальне бирде. «Алабыз» дигән катгый җавапны ишеткәч, шуның белән канәгатьләнде.

Халык никадәр күп булса да байларымыздан кешеләр аз иде. Хәтта бәгъзе бер байлары аның шәһәрдән дачага качканнары да беленде. Буның сәбәбе исә шул көнге «Камско-Волжская речь» газетасында чыккан кечкенә генә бер мәкалә сәбәпле күңелсез вакыйгалардан куркып качканлыклары мәгълүм булды. «Камско-Волжская речь» газетасында ошбу мәкалә басылып чыккан иде: «Сөембикә манарасына касыд».

«Казан мөселман хәрби Комитеты 2 сентябрьдәге мәҗлесендә Сөембикә манарасындагы кош сурәтен алып аның урынына ай куярга карар биргән иде вә инде эшкә дә керешә. 10 сентябрьдә ул бу хакта бәгъзе бер мөәссәләргә, шул җөмләдән Казан университетының археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә дә карарын җибәрде. Бу эшкә мөәссәләр ничек караганнардыр, ул мәгълүм түгел. Археология җәмгыятенең шурасы исә тарихи ядкәрнең тышкы рәвешен үзгәртергә катгый сурәттә протест бирергә карар бирде. Менә бу протестны Казан руслары якларга тиеш. Сөембикә манарасының исеме татарча булса да, татарның тарихына вә татар Казанына аның һичбер төрле мөнәсәбәте юк. Ул үзенең төзелеше белән Мәскәү Кремлен искә төшерә торган рус асари готикасе (искедән калма ядкәрләр - Н.Исәнбәт иск.), ул XVII гасырда эшләнгән нәрсә түгел, голландияле Витрәннең «Шәркый вә гарби (көнчыгыш вә көнбатыш - Н.Исәнбәт иск.) Татарстан» исемле 1692 нче, 1905 нче елларда нәшер ителгән әсәренә гыйлавә (кушымта - Н.Исәнбәт иск.) ителгән Казан рәсемендә ул манараның сурәте юк, шулай булгач Мөселман хәрби Комитетына ул манараны үзенеке итәргә во аның өстенә ислам галәмәте булган ай куярга һичбер төрле юл юк. Монда стильләрне аермау вә тарихи дәверләрне белмәү өстенә бөек вә хаким булган рус халкының хакына тәҗавез (басып керү - Н.Исәнбәт иск.) дә бар. Уйлап карагыз әле: алар алырга теләгән кош сурәте кара кош (орел) Россия дәүләтенең гербы бит! Ул никадәр какшаган булса да, аңа мозаффарият (өстенлек - Н.Исәнбәт иск.) казанырга, кирәк мөселман диненә булсын, кирәк татар халкына булсын, әле вакыт җитмәгән. Мөселман хәрби комитетына ашыгыч рәвештә ясаган вә миңа мәгълүм булдыгына күрә рус халкының ачуын китергән бу карарын җиткерүенә туктатып торырга вакыт үтмәгән әле».

●1917 елның сентябрендә Сөембикә манарасы башыннан сәмругъ кошны кисеп төшерүчеләр. Уртада утыручы солдат – Ибраһим Зәйнулла улы әл-Болгари, ул – Сәрдәр Вәисовның урынбасары. Рәсем «Человек в революции. Казанская губерния» китабыннан алынды.

Профессор К. Харламповский (Бу тәхәллүснең профессор Константин Васильевич Харлампович булуы ихтимал. «Камско-Волжская речь» газетасы белән тыгыз элемтәдә Казан университетының археология, тарих һәм этнография җәмгыяте житәкчесе М.М. Хвостов булганы билгеле.).

Самодержавие галәмәте булган кош сурәтен алырга карар бирүчеләр, әлбәттә мондый гына түгел, бундан катырак тәгаррызлар (куркыту, тыкшыну, янау - Н.Исәнбәт иск.) булачагын да алдан ук уйлап куйганнар иде (Акт (протест) Братства св. Гурия от 16 сентября 1917 г. по поводу предполагаемого водружения на башне Сююмбике полумесяца взамен орла (государственного герба) // 100-летие образования ТАССР: Сборник материалов и документов. – т.1. - Казань: Заман, 2017. - С. 373.). Шул сәбәптән аларга бу сүзләр генә тәэсир итмәде, карар, карар көенчә калды, хәзерләкләр тәмам булу белән эшкә дә шыруг ителде.

Өч сәгать тә чирек тә өч мәртәбә барлык җыелган халык тарафыннан кычкырып тәкбир әйтелде вә дога кылынды. Моннан соң кошны төшерүгә башлап менүче Габдулла Исмәгыйлов 2 рәкәгать намаз укып, манарага менеп китте. Манара очындагы кошны (орелны) кисеп алырга уйланганлыктан, ул пычкы белән тимерне кисәргә кереште. Ярты сәгатькә якын эшләгәннән соң, арыганлыктан ул төште. Аның урынына нәүбәттә торган матрос (Хәрби Шура әгъзасы) Заһретдин Минһаҗетдинов менеп, ул кисә башлады. Ул төшкәннән соң Ибраһим Зайнуллин (Вәиси) менеп, ул да бераз кисеп төште, аннан соң Гарифулла Валиуллин дигән кеше дә менеп, бераз кисте. Бу вакытта ул тимерне кисеп чыгару өчен, бик озак вакыт кирәге мәгълүм булды. Нәүбәттә торган Газибәк Салтыйковский (Н.Т.Ильясова язмасында Газибәк Салтыйковский артист дип бәяләнә) берлән Лотфрахман Габдрахманов (тупчы) дигән солдат кош кебек баскычтан, бер-бер артлы менеп киттеләр. Аларның беренчесе менеп житү белән туп-тугры кошның канатларына ябышып эләрелеп, кошның муенына менеп атланды. Вә кошның башларыннан тажларны берән-берән кубарып алып иптәшенә бирә башлады. Иптәше дә баскычтан югары, кошның астындагы түгәрәк шарга гына басып тора иде. Аның астындагы баскыч иң югары тәрәзәдән чыгарып ясалган балконга беркетелгән иде. Шул баскычны очында торган өченче кешегә сүтеп алынган нәрсәләрне биреп торды. Ике таҗ алынганнан соң ул түбәнгә төшеп, Габдрахманов менеп эшли башлады. Ул иң баштагы сары шарны тотып торган тимернең винтларын чыгарып, шарны алып төшерде. Вә моннан соң шар беркетелгән тимер берлән бергә ясалган кошның ике башы арасындагы зур тажның хачын (тәресен) бергә кубарып ала башлады. Бу вакытта бәхетсезлек аз гына булмый калды. Габдрахманов борып чыгарган вакытта шул хачны тимернең черегән винты сынып китте. Габдрахманов тимерне ташлап ычкындырып җибәрмәсә, авырлыгы белән Габдрахмановны түбәнгә тартып егып төшертү бик ихтимал иде. Ул тик тимерне кулыннан ычкындырып түбәнгә төшереп җибәреп кенә котылып калды.

Бу тимерне төшергәннән соң, инде кошны алу өчен, аның зур таҗын кигезгән тимер колгасыннан чыгарып аласы гына калды. Зур таҗын чыгарып алу өчен колганың сынган тимер винтыннан югары ягын кисеп алырга кирәк иде. Бу эшне Хәбибулла Ибраһимов (тупчы) гаҗәп бер мәһарәт берлән эшләде. Аның яртылай киселгән тимерне сындырып алу өчен кошка ябышкан көенчә манара очында атынуы, кош тирәсендә зырылдап әйләнеп йөрүе һәркемне искиткеч гаҗәпкә калдырды. Бу тимерне сындырып зур тажны алганнан соң, ул төште. Кошның үзен алу өчен Лотфрахман Габдрахманов белән Габдулла Исмәгыйлев икесе менделәр. Аларның кошны югары таба күтәрелгән вакытта нечкә бер колганың ике ягында әйләнүләре, икесе авыр кошны әкертен генә күтәреп бер якка янтаеп элеп куюлары чынлап та искитәрлек бер йөрәклелек берлән эшләнде.

Алар 35 сажиннан артыграк биек урында аяклары көчкә генә сыярлык бер урында басып кына торсалар да, фәүкыльгадә (гадәттән тыш - Н.Исәнбәт иск.) бер суык канлык белән бер җирдә торып эшләгән кебек эшләделәр.

Кошны бер якка янтайтып элеп куйганнан соң чыгырдагы бауга бәйләп алып, кош үзләрен бәреп төшермәсен өчен, манарага төштеләр. Бундан соң манараның балконында торып, баудан тартып, кош колгасыннан ычкындырылды вә чыгыр берлән түбәнгә төшерелде.

Самодержавие галәмәте булган кошны төшергән вакытта, туктаусыз ике оркестр тарафыннан музыка «Марсельеза» тавышлары һаваны яңгыратып торды. Кич 7 ярым сәгатьтә бу эш тәмам булды. Бундан соң халык бик зур шатлык белән таралды.

Хәрби Шура һәм Хәрби Комитет рәисләре кошны эшчеләр, солдат һәм Крестьяннар Шурасы (Советы) идарәсенә тапшырдылар.

Ошбу кара кошны (орелны) алган көннең һавасы зәп-зәңгәр, күктә һичбер болыт әсәре юк, бик гүзәл, якты кояш җылысы һәм нуры белән бу көнне искиткеч рәвештә зиннәтләгән иде.

(Бу язманы 1975 елның 1 октябрендә Казанда Җәгъфәр Садыйк кулъязма дәфтәреннән күчереп алдым. 1917 елда Сөембикә манарасы башыннан рус самодержавиясе галәмәте булган кара кошны алып, аның урынына ай куюо вакыйгасы күргән кешенең сөйләве буенча язылган. Н.Исәнбәт искәрмәсе).

* * *

Бу чорга караган тагын бер чыганакны таптык. Ул профессор И.Покровскийның миссионер Е.А.Маловның үлеме уңае белән язылган мәкалә. Вакыйганың датасын бутаса да, бу әзектә иҗтимагый кәефләр тарихчы тарафыннан бик дөрес тасвирлана: «Покойному о. Е[вфимию] А[лександрови]чу, как миссионеру, тяжело и больно было видеть и переживать разрушение того, над чем он усердно трудился более полустолетия. Его, как миссионера, до глубины души и до слёз оскорбило надругательство над Русской Православной Церковью и верою православно-русского народа, когда, в день церковного празднования пятидесятилетия существования Казанского Братства Св[ятителя] Гурия, так много сделавшего для христианского просвещения приволжских инородцев, в Казани, в Кремле с башни именуемой почему-то Сумбеккиной, но на самом деле здания позднейшего русского происхождения не ранее 30-х гг. XVIII в., татарами-мусульманами снят был государственный герб с тем, чтобы заменить его полумесяцем. Сделано это было торжественно мусульманами, когда рядом в Благовещенском соборе совершалось торжественное богослужение по случаю пятидесятилетия Братства (4окт[ября] 1917 г.) » (Покровский И.Профессор Казанской Духовной Академии. Протоиерей Евфимий Александрович Малов // Памяти о Господе почивших/ Известия по Казанской Епархии. - 1918. - № 11 - 12 (8 - 22 июня). - С. 284 - 285.).

1917 елның 16 сентябрендә татар-мөселманнарга каршы Братство святителя Гурия шундый Акт (Протест) язган:

«Общее торжественное собрание Братства свидетеля Гурия по случаю 50-летия Братства, основанного 4 октября 1867 г., выслушав внеочередное сообщение о том, что вопросы постановления Казанского Общества истории, археологии и этнографии при Университете и Казанской Городской думы и затем, несмотря на заявленный протест русских жителей Казани, татары-мусульмане хотят сегодня поместить на расположенной в Кремле башне Сюем-Бика религийный символ мухамеданства в виде полумесяца, выражаем свой протест перед Казанским Губернским Комиссаром по поводу такого поступка татар-мусульман, и постановляет по телеграфу обратиться с просьбой к Поместному Церковному Собору о защите от таких демонстративных решений иноверцев, во избежание эксцессов».

Айны Сөембикә манарасына ярты ел узгач кына – 1918 елның 8 мартында урнаштыралар.

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,
әдәбият белгече.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

29 апрель (шимбә). ***Шәүвәл аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,12.07 сәгатьтә калка, 3.46 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.09 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Яшәрү рецепты

Тибетта бик киң таралган дәва. 100 әр грамм ромашка, сары мәтрүшкә, шиңмәс үлән, каен бөресен кушып, тарттыралар. Кич шуның 1 аш кашыгын ярты литр кайнар суга салалар, 20 минуттан соң тукыма аша (марля аша түгел!) сөзеп, сыгалар. 1 стаканын агызып алып, 1 чәй кашыгы бал кушалар һәм эчәләр. Шуннан соң ашарга да, эчәргә дә ярамый. Иртән калган өлешен җылытып, 1 чәй кашыгы бал кушалар, ашарга 15-20 минут кала эчәләр. Катнашма беткәнче, көн саен шулай дәваланалар. Нәтиҗәдә матдәләр алмашы яхшыра, организм май һәм известь утырмаларыннан чистара, кан тамырларының тышчасы сыгылмалыракка әйләнә, күз күреме әйбәтләнә, организм яшәрә.

30 апрель (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,13.24 сәгатьтә калка, 3.55 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.13 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

1 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 11нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 14.42 сәгатьтә калка, 4.02 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.18 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Майда бакча эшләре (1)

Үсә баручы Айда (1-4; 20-31 май): җимеш агачларын ялгыйлар; куак һәм чәчәкләр утырталар; ачык грунтка полиэтилен яки агроспан астына кыяр, ташкабак, патиссон, кабак чәчәләр; соң өлгерә торган кәбестә орлыгын үрентегә чәчәләр; түтәл-газоннарны әзерлиләр; файдалы бөҗәкләрне җәлеп итә торган укроп, суган, кишер, фацелия чәчәләр; кыяр, помидор, борыч, баклажан үрентеләрен теплицага чыгарып утырталар. 5 һәм 19 майда бернәрсә дә чәчәргә, утыртырга, күчереп утыртырга ярамый.

2 май (сишәмбе). ***Шәүвәл аеның 12нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 14.42 сәгатьтә калка, 4.02 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.22 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Майда бакча эшләре (2)

Кими баручы Айда (6-18 май): корткычларга каршы һәм авырулардан саклау чаралары уздыралар – алмагач һәм грушаларга бор кислотасының 3 процентлы яки бордо сыеклыгының 1 процентлы эремәсен сиптерәләр; барлык җимеш агачлары төбенә нитрофосфат кертәләр; бакча җиләге өстенә көлле су сибәләр һәм коңгызга каршы сода эремәсе (10 литр суга 1 аш кашыгы) сиптерәләр; крыжовникны ончыл чыкка каршы кальций тозлары һәм сабын эремәсе белән эшкәртәләр; үлән бетләре күренсә, җимеш агач-куакларының яшь ботакларын дегетле сабын суы белән юалар; кара карлыганның артык зураеп бүрткән бөреләрен һәм каралган чыбык очларын җыеп алып яндыралар. Һәр 5 көн саен редис чәчә башларга була. Бәрәңге утырталар, шалкан, чөгендер, кишер чәчәләр. Җылылык яратучы культураларны кыраудан саклау чараларын күрәләр, бакчага төтен җибәрәләр, иртән һәм кичен су сибәләр.

3 май (чәршәмбе). ***Шәүвәл аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында,17.19 сәгатьтә калка, 4.12 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.26 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Яраны төзәтү

Кан агуны туктату һәм җәрәхәтләрнең төзәлүен тизләтү өчен, яңа җыелган меңьяфрак үләнен иттарткычтан чыгарып, яраны шуның белән бәйлиләр, көненә 2-3 тапкыр алыштыралар. Яки кылыч үлән тамырын киптереп, төяләр, шуны ярага сибәләр. Җәрәхәт тизрәк җыелсын өчен, мүк җиләге ашау, аның согын эчү файдалы. Эренле ярага исә алоэ яфрагын урталай кисеп ябу килешә.

4 май (пәнҗешәмбе). ***Шәүвәл аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 18.42 сәгатьтә калка, 4.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.30 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

5 май (җомга). ***Шәүвәл аеның 15 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 20.10 сәгатьтә калка, 4.26 сәгатьтә бата. 20 сәгать 34 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 15.34 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Яшел коймак

Берәр бәйләм петрушка һәм яшел суган, шпинат, 2 бүлем сарымсакны вак кына турап, 2 йомырка сыталар, 1 аш кашыгы томат пастасы, бераз он, тәменчә тоз, борыч өстиләр. Әйбәтләп болгатып, көнбагыш маенда ике ягын да икешәр минут кыздырып алалар. Табынга каймак яки соус белән бирәләр.

Шәфкатьле талант иясе



Укымышлы, милли җанлы, үз тарихын белгән, сәясәтне аңлаган, кешелекле, гаделлек белән яши торган фикердәш шәхесләргә күңел тартыла. Милли хәрәкәттә катнашып йөрүчеләр арасында, төрле очрашуларга, кичәләргә барганда, профессионал җырчы, артист Зөфәр Ядкәр улы Сафин белән очрашырга туры килә. Гарәп теленнән тәрҗемә иткәндә, аның исеме «җыңүче» дигән мәгънәгә туры килә. Андый кичә-очрашуларда булганда, ул мәгънәле матур җырлар башкара, мөнәҗәтләр дә әйтә.

Күптән түгел Мәрҗани урамындагы инвалидлар (чукрак-телсез) оешмасында ифтар ашына багышланган кичәдә очрашкан идек. Ул анда җыелган кунаклар алдында, барыбызның күңелләрне күтәреп, мөнәҗәтләр башкарды. Бу кичтә Зөфәрнең үзе белән дә сөйләшеп алдык. Ул монда һәр атнаның җомга көнендә килә икән. «Чакырган җиргә бармый калганым юк», – ди ул.

Сүз уңаеннан, мондагы очрашулар, бу оешманың директоры Лилия Харис кызы һәм Әдеһәм Әгъзам улы тырышлыгы белән үткәрелә. Әдеһәм ага монда ясаган чыгышларны кул-бармаклары ярдәмендә тәрҗемә ясап аңлатып тора. Әдеһәм ага университетта телсез-чукракларга, шул исәптән чит төбәкләрдән килгәннәргә дә, югары белем алырга булыша икән.

Зөфәр Сафин иганәчелек эшен 2009 елда башлап җибәрә. Лаеш район үзәгендәге мәдәният йортында, Чулпан һәм Пушкин исемендәге мәдәният йортларында, Дубравный урамындагы картлар йортында, ветераннар һәм инвалидлар өчен иганәчелек концертларында катнашып йөри ул. Мондый концертларда чыгыш ясаучы Айгөл Бариева, ИлСаф, Илсур Сафин, Рөстәм Насыйбуллин белән бергә, дөм сукыр инвалид Альбина Абрамованың да булуы шаккаткыч. Андый концертларга кызны әтисе озатып йөри.

З.Сафин Казан консерваториясендә һәм Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтында белем алган профессионал башкаручы, милли һәм дини җанлы шәхес, исемсез халык җырчысы ул. Филармониядә эстрада бүлеге җитәкчесе булып эшләгәндә, бу эстрада бүлеге бетерелә (2003 елда). Шул елларда, аңа «атказанган» исеме бирү буенча документлар әзерләнә башлаган була. Шул вакытлардан соң хатыны Наилә ханым белән мәктәптә балаларга җыр сәнгате буенча белем бирәләр. Зөфәр турында мәкаләләр дә басыла, радио-телевидениедә дә аны күргәлибез. Шәфкатьлелеге белән аерылып торган, кыерсытылган-кимсетелгән кешеләрнең күңелен күрү эшен дәвам иткән затка карата хөрмәт, акча өчен җырлап, төрле дәрәҗәле исемнәр алучыларныкыннан түбән дәрәҗәдә булырга тиеш түгелдер бит инде.

Быел гыйнварда Зөфәр 55 яшьлек гомер бәйрәмен каршы алды. Ел ахырына кадәр аның юбилей елы санала. Хөрмәтле җитәкчеләребез дә Зөфәр Сафинны искә алыр, лаеклы хезмәтен бәяләр, дип өметләнәм.

Рәфкать ИБРАҺИМ.

Сугыш чорын онытырлык түгел

Әлмәт районы Миңлебай авылы китапханәсендә «Сугыш чоры балалары» дип исемләнгән чара уткәрелде. Чарага авылыбызның ак әбиләре берсеннән берсе матур күлмәкләрен киеп, ап-ак яулыкларын бәйләп килделәр. Катнашучылар үзләренең сугыш вакытында үткән авыр балачаклары турында бик үтемле итеп сөйләде.

Сугыш чорында туган балалар өлкәннәргә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Хуҗалык эшендә булышу, колхоз басуларында уңыш җыю, ат җигеп, хайваннарга азык алып кайту, өйне җылыту өчен ягулык ташу – балалар һәркайда үзләреннән өлеш кертә. Аларның ачлы-туклы, хәлсез килеш иртәннән алып караңгыга хәтле эшләүләре, киярга киемнәре дә булмавы турындагы сүзләр һичкемне битараф калдырмады.

Ул вакытта сугыш читләтеп үткән гаиләне табу кыен була. Кемдер әтисен, кемдер ирен, абыйсын, туганнарын сугышка озата. Апалар кичләрен чыра яки лампа уты астында, күршеләре, туганнары белән җыелышып, әтиләре, абыйлары язган хатларны укулары турында сөйләде. Ватаннарына тугры булып, туган җирләренә кайта алмыйча, яу кырында ятып калган геройларны искә алып дога кылдылар, мөнәҗәтләр укыдылар. Бу кичәдә «Алар Ватан өчен көрәштеләр» дип исемләнгән альбомнан фотосурәтләрен карап, сугыштан исән кайткан авылдашларыбызны искә алдылар. Хәзер аларның барысы да бакыйлыкка күчкән инде.

Өлкән апалар яшь чакта уйнаган уеннарын искә төшереп, күңелле итеп уйнап алды, мәзәкләр сөйләде, җырлап-биеп тә җибәрделәр. «Сорауга-җавап», «Җәза бирәм», «Лоторея» уеннарында катнаштылар. Очрашу ахырында әбиләребез үз куллары белән пешереп алып килгән тәмле коймаклар, кабартмалар белән чәй эчте.

Лилия ГАБДУЛЛИНА,
Әлмәт районы Миңлебай авылы китапханәсе мөдире.

Китаплар да җанлы...

Зур Күккүз китапханәсендә туган якны өйрәнү, китапларга карата хөрмәт, кызыксыну уяту, китаплар тарихын өйрәнү, әдәби мирасны саклап калу, аны яшь буынга өйрәтү, туган җиргә горурлык хисе тәрбияләү максатында «Китап музее» оештырдык. Әби-бабайлардан калган борынгы китапларын музейга бирүләрен үтендек. Авыл халкы үтенечебезне кире какмады: китап музеенда хәзер кульязмалар, әдәби әсәрләр, дәреслекләр, хатлар белән беррәттән китапханәбезнең иң зур, иң кечкенә һәм иң беренче китаплары, үзебез таш, балчык, такта, каен тузыннан эшләгән һәм төргәк китаплар бар.

Өлкәннәр ярдәме белән туган авыл тарихын өйрәнеп, «Күккүземнең чал тарихы», «Күккүз мәчетләре тарихы», «Китапханә тарихы», «Бөек Ватан сугышы чорларында китапханә» дип аталган хезмәтләр, папкалар урын алган. «Унике кыз» – дип аталган бер китап тәрҗемә ителде. Милли мәдәниятләр һәм гореф гадәтләр елы уңаеннан «Гасырларны кичкән китаплар» әдәби тематик кичә үткәрдек.

«Кульязмалар ни сөйли» дигән бүлектә укучылар борынгыдан калган кульязма китаплар белән танышты.

Балалар каен тузыннан эшләнгән һәм төргәк китапларга үз куллары белән язып карады, китап язуның нинди авыр эш булганына инанды, ташка, балчыкка рәхмәт белдерми торып, китап тарихы турында сөйләргә мөмкин түгеллегенә төшенде.

Кичәгә борынгы китапларны укый ала торган хөрмәтле кешеләребезне чакырдык. Алар безгә гарәп әлифбасында, гарәп телендә язылган китаплар укып һәм шуларны аңлатып та бирде. Гарәпчә китапларны кычкырып уку кичәгә ямь өстәде.

Китаплар турында мәгънәле әйтем мәкальләр, табышмаклар буенча үткәрелгән уен-квестта балалар бик теләп катнашты. Очрашулар алар күңелендә матур хатирәләр калдырды.

Балаларда борынгы китапларга карата кызыксыну бар. Музейда булган һәр истәлек турында сораулар бирәләр. Димәк әле безнең мирасыбыз буыннан-буынга күчә, дәвамлы киләчәк булу күңелне сөендерә.

Галия ҖӘЛӘЛИЕВА.
Апас районы Зур Күккүз авыл китапханәсе

БЕРЛӘШҮ ҺӘРЧАК ОТЫШЛЫ

«Самарбикә» хатын-кызлар оешмасы «Тарих күзлегеннән чыгып караганда акча һәм рухи байлык төшенчәләре» дип аталган түгәрәк өстәл уздырды. Әлеге оешма эшчәнлеге белән танышу өчен, җитәкчесе Зөлфия Таштабанова белән элемтәгә кердек.

– Без, Самара дәүләт экономика университетының кафедра мөдире, профессор Наилә ханым Таһирова белән башта икәү утырып киңәштек, аннары унлап хатын-кызны чакырып, уй-фикерләребез белән уртаклаштык та Самара өлкәсендә татар телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнү һәм киләчәк буыннар өчен саклап калу нияте белән «Самарбикә» дип аталган хатын-кызлар җәмгыяте оештырырга уйладык. Оешмада катнашу ирекле булачак. Без тәкъдим иткән темалар кызыклы икән – димәк кеше тагын киләчәк, тормыш аның алдына куйган сорауларга бергәләп җавап эзләячәкбез. Мин һөнәрем буенча педагог һәм психолог кына түгел, мәдәниятара коммуникацияләр белгече һәм менеджер да. Шулай ук арабызда тарихчы-галим Наилә Таһирова, педагог Тәслимә Мостафина, җырчы Шамилә Ибраһимова, Лилия Кидрячева кебек белгечләр бар, – дип сөйләп китте әңгәмәдәшем.

– Зөлфия ханым, Самарада «Ак калфак» оешмасы бар. Сезнең эшчәнлек аларның юнәлеше белән кисешмәячәкме?

– Юк, әлбәттә. Без эшебезне «Саф татарча сөйләшик» онлайн клубы оештырудан башладык. Хәзер үзара тик татарча сөйләшәбез, татар шагыйрьләре, җырчылары, зыялы аналар турында сүз алып барабыз. Без татар халкының тарихын тирәнрәк өйрәнергә телибез. Мәсәлән, Казахстанга Г.Тукай музеена баруны планга керттек, шулай ук Казан музейларына, театрларына, мәчетләренә сәфәрләр оештырырга планлаштырабыз. Оешма әгъзалары тәкъдим иткән бер тема да җавапсыз калмаячак. Бүгенге темабыз да катлаулы – ул акча һәм рухи байлык темасын күтәрде, түгәрәк өстәлгә килүчеләрдә зур кызыксыну уятты.

...Чарага килгән утызлап кеше арасында ана теленә битараф булмаган актив хатын-кызлар, эшкуарлар, хәйриячеләр, хәзрәтләр, студентлар һәм мәктәп укучылары бар иде. Яхшы эшнең башы бисмилла белән башланды. Наил хәзрәт Биктаев сүрәләр укып, дога кылганнан соң, сүз Зөлфия Таһир кызына бирелде. Ул утырышта катнашучыларны «Самарбикә» оешмасының планнары белән таныштырып үтте һәм бүгенге чара темасына да тукталды. «Татар оешмалары эшчәнлегенә карап, бөтен өлкәләрдә дә хәйриячелек кирәк булуына игътибар итәсең. Сабан туйлары, спорт ярышлары, фестивальләр һәм конкурслар үткәрү, мәчетләр төзү һәм аларның көндәлек яшәешен тәэмин итү кебек милләт эшләре бай эшмәкәрләр һәм гади халык җыйган акча исәбенә эшләнә. Элек тә шулай булган, бүген дә. Шуңа күрә беренче темабыз Коръәндә күп тапкырлар кабатланган «Хәйриячелек» темасына багышлана, – диде ул.

Наиләгә Таһироваға акча тарихы турында сөйләп үтте: «Цивилизациянең соңгы 500 елы – акчаның «коллыктан чыгып, хуҗага әверелү тарихы, – диде галим. – Халыклар кайчан потларга табына башлаган? Рухи байлык белән матди байлыкның урталыгын табып буламы? Фабрикант Акчуринның феномены; «Самара Рокфеллеры» кем булган? Хәйрия акчасына торгызылган биналарны Самара ничек саклый? Кеше өчен нәрсә мөһим һәм кеше булып яшәү өчен нәрсә кирәк?» – бу сораулар күпләрне уйланырга мәҗбүр итте.

«Болгар мирасы» оешмасы җитәкчесе Гомәр Батршин, үз гаиләсе, үз проектлары үрнәгендә, хәйриячелек әһәмияте турында сөйләп үтте. Ул яшьләрне дә хәйрия эшләренә тартырга өндәде. Гомәр әфәнде яңа оешма ачылу белән котлап: «Самара татар оешмаларына хатын-кызлар кулы җитми иде, – дип билгеләп үтте. – Безнең шәһәрдә хатын-кызлар игътибарыннан читтә калган ятимнәр, тулы булмаган гаиләләр, авырулар күп. «Самарбикә»ләләр аларга да җан җылысын бирә алыр», – дигән өмет белдерде.

Шулай ук «Туган тел» җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүров та, «Дуслык» җәмгыяте президенты Фәхретдин Канюкаев та милләтебез өчен күп яхшылыклар эшли. Милли бәйрәмнәр оештыру, «Яктылык» мәктәбенә ярдәм итү, «Бердәмлек» өлкә татар газетасын һәм «Самара татарлары» журналын, «Ялкынлы яшьлек» һәм «Идел» ансамблен яшәтү өчен, алар үз кесәләреннән күп акча чыгарып тора. Нәкъ менә алар – бүгенге меценатларыбыз һәм халкыбызның милли рухын ныгытучылар.

Беренче түгәрәк өстәл утырышы җанлы һәм мәгълүматка бай булып үтте. Хәерле юл сиңа, «Самарбикә»!

Эльмира ШӘВӘЛИЕВА.
«Бердәмлек».

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

28 апрель – Уфа «Нур» Татар дәүләт драма театрының «Галиябану» спектакле (М.Фәйзи).
29 апрель – Шәрык клубында 15.00 – Балалар өчен рәсем остаханәсе. 18.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
30 апрель – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
2 май – «Көл» (К.Митани).
3 май – «Күзгә кайтаваз» (Р.Галиуллин).
4 май – «Тормышмы бу?..» (Г.Исхакый).
5 май – Шәрык клубында 18.00 – «Артист» (Г.Кариев). 19.00 – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

29 апрель – «Тоска» (Дж.Пуччини).
3 май – «Аида» (Дж.Верди).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

28 апрель – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
2 май – 13.00 – «Татар теле – сәхнә теле» (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
3 май – «Полиционер» (И.Зәйниев).
4 май – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

28 апрель – «Рөстәм маҗаралары» (аталы-уллы Гадел һәм Рөстәм Кутуйлар, А.Әхмәдиев һәм Т.Кулов инсценировкасы).
29 апрель – 13.00 – «Әлифба» (Л.Әхмәтҗанова, Э.Яруллина, Ф.Насыйбуллин). 18.00 – «Җырлап яшик!» (Р.Латыйпов).
30 апрель – «Йосыф» (Кол Гали).
3 май – «Тимур һәм комета» (П.Коротыч).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

28 апрель – 11.00, 13.00 – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). 19.00 – «Әлфия» (И.Зәйниев).
29 апрель – Фойеда – «Идет коза рогатая» (М.Потасова). Зур залда – «Конек-Горбунок» (П.Ершов әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы).
30 апрель – Зур залда – «Буратино» (А.Толстой). Кече залда – «Камыр Батыр» (С.Хөсни).
1 май – Фойеда – «Добрый день!» (Н.Егорова). Зур залда – «Приключения Барона Мюнхгаузена» (Р.-Э.Распе).
4 май – «Аладдин» (Гарәп әкиятләренә нигезләнгән).
5 май – Зур залда 11.00 – «Аладдин» (Гарәп әкиятләренә нигезләнгән), кече залда 12.00 – «Мактанчык әтәч» (Аманулла), 19.00 – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

28 апрель – «Идел» XII халыкара татар һәм башкорт җыры фестиваль-бәйгесе лауреатларының гала-концерты.
30 апрель – Джаз кичәсе.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

28 апрель – Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Халкыбыз мирасы» дип исемләнгән концерт-презентациясе.
29 апрель – И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте укучылары башкаруында Мөгаллим һәм остаз елына багышланган «Добрые традиции» исемле концерт. Катнашалар – көллиятнең симфоник оркестры (дирижер – Д.Железнов), катнаш хоры (җитәкчесе Д.Венедиктова), скрипкачылар ансамбле (җитәкчесе Р.Молчанова) һәм аерым башкаручылар.
30 апрель – Зур Пасха фестивале. Программада Казан, Чабаксар, Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләреннән хор, инструменталь һәм бию коллективларының чыгышы.

Алтыннан кыйбатрак

Алтын һәм агалтынның планетада иң кыйммәт металлар булуы һәркемгә мәгълүм. Алтынның килограммы хәзер якынча 4 миллион 870 мең сум тора. Әмма без шуның кадәр кыйммәтледер дип уйламаган матдәләр дә шактый. Мәсәлән, принтер буявының литры 165 мең сумга бәяләнә. Әлеге буяуны җитештерү бик арзанга төшә, югары бәяне исә аны саткан акчага типография тикшеренүләре үткәрү, язу карасы һәм буяуларның яңа төрләрен уйлап табу мөмкин булсын өчен куялар. Эзләвә, табуы һәм химик эшкәртүе бик катлаулы булган терекөмешнең литры өчен исә 50 мең сум түләргә кирәк. Инсулинның литры 140 мең сум тора, элегрәк аны сыер һәм дуңгызларның ашказаны асты бизеннән алганнар, 1963 елдан бирле синтетик юл белән табалар. Дөньяда иң яхшылардан саналган "Шанель №5" хушбуеның литры 400 мең сумга бәяләнә. Ә иң кыйммәтле сыеклык – чаян агуы, аның литры 587 миллион сум булыр иде, тик аны ул кадәр күләмдә табу мөмкин түгел. Чаян агуы ялкынсынуга каршы тору һәм авыртуны басу үзлекләренә ия, ул хәтта яман шешне үсүеннән туктатырга сәләтле.

("The Local").

Искиткеч хәтерлеләр

Көньяк Африка сәясәт эшлеклесе Ян Христиан Смэтс картайган көнендә 5000 китапны яттан өйрәнә. Япон Хидеаки Томоери "пи" санының өтердән соңгы 40 мең тамгасын яттан белә. 1967 елның 14 октябрендә Анкарадан Мәхмәд Гали Халиси 12 академик каршында 6 сәгать эчендә Коръәннең 6666 аятен яттан укый. Валерий Лавриненко 100 санны 2,5 минутта, 200 санны 3 минутта хәтерендә калдыра, нибары 2-3 кенә хата җибәрә. Кытай Гу Янлинь Харбинның 15 мең телефон номерын хәтерли. Тасманиядә оператор Паула Прентис 128603 абонентның исемен, телефон номерын, адресын, оешма исемнәрен яттан белә, ә менә үзенең телефон номерын хәтерендә калдыра алмый. Америкада Барбара Мур, пианинода уйнап, 1852 җырны яттан җырлый, әлеге "концерт" 1988 елның 25 октябреннән 13 ноябренә кадәр дәвам итә. Польшадагы "Гурник" футбол клубы кассиры Леопольд Хелд үзенең 12 ел эшләү дәверендәге клуб уеннарының нәтиҗәсен генә түгел, һәр матчтан кергән табыш суммасын да төгәл хәтерли. Дөньядагы бөтен казинолар инглиз Доминик О'Брайенга үзләренә керүне язма рәвештә тыйган: ул, искиткеч хәтергә ия булганга, карталарны хәтерендә калдыра барган һәм гел күп акча откан. Доминик бер сәгатьтә чит телдән 300 сүзне хәтеренә сеңдерә, 2-3 көннән яңа телдә укырга өйрәнә. 1994 елда Хәтер буенча дөнья чемпионатында Доминик җиңгән: 15 минутта кытайча 152 сүз өйрәнгән.

("Die Presse").

Картаюны туктатып булачак

Берклидагы Калифорния университеты галимнәре, тикшеренү үткәреп, картаю процессларын һәм шикәр чире үсешен туктатып була, дигән нәтиҗә ясаган. Белгечләр билгеле бер аксым белән картаю арасындагы бәйләнешне ачыклаган. Әлеге NLRP3 инфламмасома иммун аксым комплексы организмга янаган куркынычларны ачыклау өчен җаваплы. Өлкән яшьтәгеләрдә, стресс кичергәндә яки әйләнә-тирә мохитнең уңайсыз шартларында бу аксым комплексы даими гиперактивлаша, нәтиҗәдә иммун системасына авырлык килә һәм хроник ялкынсыну башлана. Әгәр әлеге аксым комплексын "сүндерсәң", картаю процессын, яман шеш һәм диабет, шулай ук Альцгеймер һәм Паркинсон чирләре үсешен туктатып була икән. Галимнәр, тычканнар белән тәҗрибәләр үткәреп, әлеге нәтиҗәне дәлилләгән. Белгечләр фикеренчә, NLRP3 инфламмасомасын "сүндерергә" сәләтле препарат уйлап табылса, картаюны туктатып булыр иде.

("Cell Metabolism").

Патша йолдыз

● Җир һәм Кояш.

Кояш системасы массасының 99 проценты Кояшның үзендә тупланган икән. Хәтта Юпитер һәм Сатурн кебек гигантлар да аның янында ком бөртегедәй генә булып кала. Һәр секунд саен Кояш 4 миллион тонна матдәсен югалта, әмма бу аның өчен бернәрсә дә түгел. Чынлыкта Кояш ап-ак төстә, атмосфера спектрның кыска дулкынлы өлешен йотканга күрә генә аның нурлары безгә сары булып күренә. Кояш гравитациясе Җирнекеннән 28 тапкыр көчлерәк, ә менә магнит кыры 2 тапкырга гына куәтлерәк. Кояш яктылыгы якынча сигез минутта килеп җитә. Бу йолдызның нурланышы бөтен терек табигать өчен куркыныч, әмма Җир атмосферасы куркыныч нурларны үткәрми. Анда су Җирдәгедән күпкә күбрәк, әлеге молекулалар нигездә Кояш тапларында урнашкан. Якынча 1100 миллион елдан соң Кояшның яктылыгы шулкадәр артачак ки, бу безнең планетадагы бөтен тереклекне һәлак итәчәк. Кояш Киек Каз Юлындагы йолдызларның 85 процентыннан яктырак. Җиргә кадәр Кояш нурларының 40 проценты гына килеп җитә, калганы космоска чагылдырыла.

("Простая наука").



● Кояш һәм планеталар.



Коры кыйтга

Яңгыр яки кар иң озак яумаган урын кайда? Кайберәүләр Сахараны, белдеклерәкләр исә Чилинең төньягындагы Атакама чүлен атар – анда яңгыр берничә дистә елга бер генә ява. Чынлыкта исә Җир шарында иң коры урын – Антарктида, анда явым-төшем булмаганга ике миллион ел икән. Әлеге кыйтганың Мак-Мердо бугазы янындагы Коры үзәннәрендәге тау араларында карның инде 8 миллион ел ятканы юк – анда төшкән бөтен нәрсәне тизлеге сәгатенә 320 чакрым булган искиткеч суык җил бөтереп алып китә. Коры үзәннәрнең ландшафты Марс өслеген хәтерләткәнгә, NASA анда үзенең сынауларын үткәрә. Антарктидадагы карлы үзәннәрнең күпчелегендә кар түгел, бәлки ап-ак конденсат ята – еллар дәвамында атмосферадан туңдырылып хасил булган әлеге матдә нәкъ менә совет суыткычларындагы конденсатны хәтерләтә, әмма күләме генә гаять зур, тау-кыялар кадәр.

("Fishki.net").

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

1 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.30 «Мин бәхетле». 12+
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Заман көзгесе». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.35 «Әдәби хәзинә». 6+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Алып калыр өмет». Айдар Фәйзрахманов җырларыннан концерт. 16+
10.00 «Семь дней». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 0.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.00 Спектакль «Йөрәк маем». 16+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
18.20 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 16+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.25 Спектакль «Күрәсем килгән иде». 16+
23.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.10, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НЯНЬКИ». 16+
11.15, 0.30 «Живая вода».
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 16.10 «Жара в Баку». 12+
14.10 «НА КРЮЧКЕ». 16+
15.40 «Магия вкуса». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «МОЛОДОСТЬ ПО СТРАХОВКЕ». 16+
23.00 «КОРПОРАТИВ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «20 лет спустя». 16+
6.40 «ПОЛОСАТЫЙ РЕЙС». 12+
8.15 «ВЕСНА НА ЗАРЕЧНОЙ УЛИЦЕ». 12+
10.15, 12.15 «ЦАРЕВИЧ АЛЕКСЕЙ». 12+
12.35 «ЦАРСКАЯ ОХОТА». 16+
14.40 «БЕДНЫЙ, БЕДНЫЙ ПАВЕЛ». 12+
16.40 Юбилейный концерт Филиппа Киркорова в Кремле «Золотые хиты». 12+
19.15 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ».
21.00 «Время».
21.35 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
22.35 «НЕФУТБОЛ». 12+

«РОССИЯ»

5.35 «ЛЮБОВЬ С ИСПЫТАТЕЛЬНЫМ СРОКОМ». 12+
9.20 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.45 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА».
13.45 Концерт «Юбилей в кругу друзей». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
21.05 Вести. Местное время.
21.20 «ВЫ МНЕ ПОДХОДИТЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Мультфильмы.
8.10 «КРАСАВЕЦ-МУЖЧИНА».
10.15 «История русской еды».
10.45 «ГУСАРСКАЯ БАЛЛАДА».
12.20 «Глухариные сады».
13.00 Концерт Государственного академического ансамбля народного танца имени Игоря Моисеева в Государственном Кремлёвском дворце.
14.25, 23.00 «Три минуты тишины».
14.30 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.35 Искатели. «Под вуалью Незнакомки».
16.25 «Виталий Мельников: по волнам памяти».
17.05 «СТАРШИЙ СЫН».
19.15 «Романтика романса». «Композиторы одного хита».
20.20 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ».
21.40 Пласидо Доминго на сцене Арена ди Верона.
23.05 «БРАК ПО-ИТАЛЬЯНСКИ».

«НТВ»

5.25 «ПЛЯЖ». 16+
7.00 «Тайны любви». «Позднее счастье Бориса Галкина». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20, 10.20 «ОТСТАВНИК». 16+
10.30 «ОТСТАВНИК-2». 16+
12.30 «ОТСТАВНИК-3». 16+
14.35, 16.20 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ». 16+
17.00 «ОТСТАВНИК. СПАСТИ ВРАГА». 16+
19.35 «ОТСТАВНИК. ЗАЩИТА ДЕДОВА». 16+
22.30 «Авторадио - 30 лет. Классика». 12+

Сишәмбе

2 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Манзара». 16+
8.00 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.30, 21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+
15.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00 Баянда Максат Гомәров уйный. 6+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
15.00 «Сандугач булып сайрармын». Гөлшат Имамиева җырлый. 6+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «НА КРЮЧКЕ». 16+
11.00 «Наукограды». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 0.30 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
14.35 «Русь». 12+
15.00 «История русской еды». 12+
15.30 «22 победы танкиста Колобанова». 12+
16.30 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ЛАЧУГА ДОЛЖНИКА». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
23.00 «Маэстро». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЕМ ПО 50». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.05 Мультфильмы.
8.00 Легенды мирового кино.
8.30, 14.45 «Д'АРТАНЬЯН И ТРИ МУШКЕТЕРА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «История русской еды».
10.40 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ».
12.00 Исторические курорты России. «Старая Русса».
12.45 Большие и маленькие.
13.45, 22.50 «Три минуты тишины».
13.50 «Подлинная история д'Артаньяна».
16.15 «Мифологические существа».
17.15 Линия жизни.
18.05 «ОНА ВАС ЛЮБИТ».
19.45 «Маэстро».
20.10 Валерий Гергиев и Симфонический оркестр Мариинского театра. «Абсолютный Прокофьев». Симфонии №1 и №7.
20.55 «Наука Шерлока Холмса».
21.25, 22.55 «ШЕРЛОК ХОЛМС».

«НТВ»

4.45 «ПЛЯЖ». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 0.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БИМ». 16+
22.15 «Спасибо, родная...» Песни Виктора Резникова. 12+

Чәршәмбе

3 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00, 0.25 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.00 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.00 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Дунай». Наил Дунаев турында телевизион очерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
15.25, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.30 «Гаилә учагы». 16+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАЧУГА ДОЛЖНИКА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПТИЧКА ПЕВЧАЯ». 12+
14.35 «Русь». 12+
15.00 «История русской еды». 12+
15.30 «История войск связи». 16+
16.30 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЕМ ПО 50». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 15.30 «Пешком...»
7.05 «Остров сокровищ».
7.55 Легенды мирового кино.
8.25, 13.50 «Д'АРТАНЬЯН И ТРИ МУШКЕТЕРА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «История русской еды».
10.40 «ОНА ВАС ЛЮБИТ».
12.00 Исторические курорты России. «Сестрорецк».
12.45 Большие и маленькие.
13.45, 22.50 «Три минуты тишины».
15.55 «Война Элины Быстрицкой». Рассказывает Надежда Михалкова.
16.15 «Мифологические существа».
17.15 85 лет Аркадию Инину. Линия жизни.
18.10 «НЕ СОШЛИСЬ ХАРАКТЕРАМИ».
19.50 Валерий Гергиев и Симфонический оркестр Мариинского театра. События жизни. Концерт в Цхинвале.
20.55 «Наука Шерлока Холмса».
21.25, 22.55 «ШЕРЛОК ХОЛМС».

«НТВ»

4.45 «ПЛЯЖ». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 0.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БИМ». 16+
22.15 «Михаил Шуфутинский 75». 12+

Пәнҗешәмбе

4 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.10 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ӨЧ ЮЛ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Классный час». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
21.10, 0.25 «Соотечественники». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
15.25 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.05 «Музыкаль мәйдан». 16+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАЧУГА ДОЛЖНИКА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ПОСЛЕДНИЙ ДОВОД». 12+
14.35 «Русь». 12+
15.00 «История русской еды». 12+
15.30 «История войск связи». 16+
16.30 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЕМ ПО 50». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 15.30 «Пешком...»
7.05 «Остров сокровищ».
8.15 Легенды мирового кино.
8.45, 13.50 «Д'АРТАНЬЯН И ТРИ МУШКЕТЕРА».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «История русской еды».
10.40 «НЕ СОШЛИСЬ ХАРАКТЕРАМИ».
12.00 Исторические курорты России.
12.45 Большие и маленькие.
13.45, 22.50 «Три минуты тишины».
15.00 «Отцы и дети».
16.00 «Война Юрия Никулина». Рассказывает Андрей Миронов-Удалов.
16.15 «Мифологические существа».
17.15 Линия жизни.
18.20 «ПРОЩАЛЬНЫЕ ГАСТРОЛИ».
19.50 Валерий Гергиев и Симфонический оркестр Мариинского театра. События жизни. Концерт в Пальмире. 2016 г.
20.55 «Наука Шерлока Холмса».
21.25, 22.55 «ШЕРЛОК ХОЛМС».

«НТВ»
4.45 «ПЛЯЖ». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 0.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «БИМ». 16+
22.15 Праздничный концерт. 12+

Җомга

5 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
15.45 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
22.10 «ПАПАШИ». 12+
23.55 «СИНЬОР РОБИНЗОН». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 15.25, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00, 19.05 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЛАЧУГА ДОЛЖНИКА». 12+
11.30 «АКАДЕМИЯ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ВОЕННО-ПОЛЕВОЙ РОМАН». 12+
14.40 «Русь». 12+
15.05 «История русской еды». 12+
15.35 «Перемышль. Подвиг на границе». 12+
16.30 «ПРАКТИКА». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе». 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 17.30, 20.00 Вести.
11.30 «НОВЫЙ МУЖ». 12+
15.00 «Измайловский парк». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
21.20 «ВСЕМ ПО 50». 12+
23.25 «НЕВОЗМОЖНАЯ ЖЕНЩИНА». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 15.30 «Пешком...»
7.05 Мультфильмы.
8.00 «ПРОЩАЛЬНЫЕ ГАСТРОЛИ».
9.10 «Живописная история Александра Аверьянова».
10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 «Забытое ремесло».
10.35 «СВИНАРКА И ПАСТУХ».
12.00 Исторические курорты России. «Кисловодск».
12.45 Большие и маленькие.
13.45, 22.50 «Три минуты тишины».
13.50 «КАПИТАН ФРАКАСС».
15.00 «Отцы и дети».
16.00 «Война Владимира Заманского». Рассказывает Иван Стебунов.
16.15 «Мифологические существа».
17.15 «Дело Деточкина».
17.55 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ».
19.50 «Песня не прощается... 1973».
20.55 «Наука Шерлока Холмса».
21.25, 22.55 «ШЕРЛОК ХОЛМС».

«НТВ»
4.45 «ПЛЯЖ». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «БИМ». 16+
23.20 «Своя правда». 16+

Шимбә

6 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин. 12+
12.00, 0.45 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Уроки истории». 6+
15.55 «Татар сүзе». 6+
16.00 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «ИВАНОВЫ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Мизгелләр». Ренат Харис. 16+
7.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Ак кәгазьдә шагыйрь җаны сызна». Ренат Харисов турында телеочерк. 16+
17.20 «Газинур Фарукшин җырлый». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Яңа татар җыры» конкурсының гала-концерты. 12+
22.45 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР». 16+

«ЭФИР»
5.00 «Русь». 12+
5.30, 16.30 «Великие полководцы». 16+
6.00, 17.00 «Мемориалы России». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Планета Ай».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Забытое ремесло». 12+
8.15 «ЗЕМЛЯ ОБЕТОВАННАЯ ОТ ИОСИФА СТАЛИНА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.10 «ЖИЗНЬ И СУДЬБА». 16+
15.45 «Амет-Хан Султан. Гроза «мессеров». 12+
17.30 «Родина или смерть». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КРАЙ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10 «ПроУют».
12.15 «Видели видео?»
13.35 «МУЖИКИ!..».
15.30 «Алексей Леонов. Космос внутри». 12+
17.00 «Все звезды русского космоса». 12+
18.20 «Кто хочет стать миллионером?»
19.20 Церемония вручения премии «Шансон года». 12+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.35 «Эннио. Маэстро». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «ПЕРЕКАТИ-ПОЛЕ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ПРИЗРАЧНОЕ СЧАСТЬЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Мультфильмы.
7.20 «БЕРЕГИСЬ АВТОМОБИЛЯ».
8.50 «Мы - грамотеи!»
9.35 «ЧАЙКОВСКИЙ».
12.05 «Знамёна великих побед».
12.45 Большие и маленькие.
13.45, 22.40 «Три минуты тишины».
13.50 «КАПИТАН ФРАКАСС».
14.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.25 «Здравствуйте, я ваша тетя!» Как сюда попала эта леди?»
17.05 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, Я ВАША ТЕТЯ!»
18.50 «Моя Маяковка. Первый век мы уже отыграли...»
19.50 Спектакль «Истории».
22.45 Клуб «Шаболовка, 37».
23.50 «ВЕРЬТЕ МНЕ, ЛЮДИ».

«НТВ»
4.45 «ПЛЯЖ». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 12+
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
11.50 «Квартирный вопрос».
13.00 «Страна талантов». 12+
15.20 «Игры разумов».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Секрет на миллион». 16+
22.25 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

7 май

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 Спектакль «Умырзая». 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Ватандашлар». 16+
13.55 «Татар сүзе». 6+
14.00 «Созвездие - Йолдызлык-2023». 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30, 0.35 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ОТЕЦ СОЛДАТА».

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Җырлашып яшик, туганнарым!» Георгий Ибушев концерты. 16+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Ватандашлар». Рәшит Ваһапов. 16+
14.05 Спектакль «Умырзая». 16+
16.20, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
21.50 «Яшик сөенеп кенә». Рифат Зарипов концерты. 16+

«ЭФИР»
5.30, 16.35 «Великие полководцы». 16+
6.00, 17.05 «Мемориалы России». 12+
6.30 «Тайны нашего кино». 12+
7.00 «Планета Ай».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Забытое ремесло». 12+
8.15 «ЖДИ МЕНЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 22.50 «ЖИЗНЬ И СУДЬБА». 16+
15.50 «Под грохот канонад. «Синий платочек» против «Лили Марлен». 12+
17.30 «АТЫ-БАТЫ, ШЛИ СОЛДАТЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ШПИОН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 Подкаст.лаб «Космические истории». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
13.35 «Леонид Быков. «Арфы нет - возьмите бубен!» 16+
14.35 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ОГНЕННАЯ ДУГА». 12+
16.20 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПРОРЫВ». 12+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Польша. Отравленные ненавистью». 16+
23.35 «Уроки музыки». 16+

«РОССИЯ»
6.05 «ДЕВУШКА В ПРИЛИЧНУЮ СЕМЬЮ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Большие перемены».
12.45 «ПЕРЕКАТИ-ПОЛЕ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
22.00, 23.25 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
22.45 «За лентой». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Приключения волшебного глобуса, или Проделки ведьмы».
7.45 «АЛЕКСАНДР ПОПОВ».
9.20 Диалоги о животных.
10.00 «ЗДРАВСТВУЙТЕ, Я ВАША ТЕТЯ!»
11.40 Невский ковчег. Теория невозможного. Борис Федоров.
12.10 «Любимый подкидыш».
12.50 Большие и маленькие.
13.45, 22.50 «Три минуты тишины».
13.50 «ВЕРЬТЕ МНЕ, ЛЮДИ».
15.40 «Первые в мире».
15.55 «Пешком...»
16.25 «Кубанские казаки». А любовь девичья не проходит, нет!»
17.05 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ».
18.55 «Паровозных дел мастер. Алексей Грук».
19.50 Концерт «Вахтангов. Путь домой».
22.55 «ЧАЙКОВСКИЙ».

«НТВ»
4.55 «ПЛЯЖ». 16+
6.30 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «Страна талантов». 12+
15.20 «Игры разумов».
16.20 «Следствие вели...» 16+
17.15 «Основано на реальных событиях». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.30 «И только так!» 16+

Казанның Дәрвишләр бистәсендәге 11 нче татар гимназиясендә «Дөньяда сүзебез бар» дип исемләнгән Хатыйп Миңнегулов исемендәге IV Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция бу юлы да әдәбият, сүз сәнгате галимнәрен, язучылар, педагоглар һәм укучыларны бергә җыйган иде. Географиясе елдан-ел киңәя барган гыйльми җыенга быел 343 эш килгән. Гаризалар Татарстаннан тыш, Чуашия, Самара, Мәскәү, Саха (Якутия), Ульяновск, Оренбург якларыннан кабул ителгән. Аларны Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви бәйләнешләр институтының Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы галимнәре, Совет районы мәгариф бүлеге хезмәткәрләре бәяләгән. Хезмәтләр «Әдәбият һәм чор», «Татар әдипләре иҗатында публицистика», «Х.Миңнегуловның басма китапларына рецензияләр һәм бәяләмәләр эшләү», «Галим сүзендә хикмәт бар» дигән темаларга бүлеп каралган. Нәтиҗәдә 133 е финалга үткән. Алар «Дөньяда сүзебез бар» җыентыгында басылып чыккан.

Галим сүзендә хикмәт бар

КФУ журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбенең милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы Васил Гарифуллин «Әдәбият һәм чор» секциясенә килгән мәкаләләрне тикшергән. Ул Хатыйп аганың төрле мәмләкәтләрдә узган конференцияләрдә катнашуы, эш сәфәре белән йөрүе, югары дәрәҗәдәге шәхесләр белән очрашуы, татар халкының мәдәниятен, әдәбиятын пропагандалау буенча күп эш башкаруы турында сөйләде. Соңгы елларда төрки дөнья галимнәре татар халкын Хатыйп аганың тирән белеме, сөйләм осталыгы аша күзаллый. Ул төрки зыялыларны берләштерү юнәлешендә дә актив. «Хатыйп ага – бүген татар фәненең, милләтенең илчесе. Киләчәктә дә безне үз артыннан ияртеп барырга язсын», – диде В.Гарифуллин. Ул алдагы елларда конференцияне халыкара дәрәҗәдә үткәрергә кирәклеген дә искәртте. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров та Х.Миңнегуловның татар мәгърифәтчеләре арасында аерым урын алып торуын белдерде. «Хатыйп абый – ялыктырмый һәм ялындырмый торган галим. Татар фәнен дөнья күләмендә таныткан кеше. Юмор хисе дә бар, әмма җиңел кеше дип тә әйтеп булмый. Дөреслекне боргаланмый-сыргаланмый гына күзеңә карап әйтә», – диде ул.

КФУ профессоры Ләйлә Минһаҗева Х.Миңнегуловны энциклопедист-галим дип атады. «74 китап, 600 гә якын фәнни хезмәт – бу Хатыйп абыйның гомер буе тел, әдәбият өлкәсендә эшчәнлеген күрсәтеп торучы дәлил. Кайсы гына төрки мәмләкәткә барсаң да, Хатыйп абый турында сүз чыкмыйча калмый. Аның безгә, яшьләргә мөнәсәбәте бик гади, эчкерсез», – диде ул.

Китап дигәннән, Хатыйп ага хезмәтләрен туплап җыентыклар чыгару традициясенә быел да тугры калган. Конференциягә ул «Татар әдәбиятының үткәне һәм хәзергесе» дигән саллы һәм затлы, әле табадан гына төшкән китабын алып килде.

Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат университетта укыганда, Х.Миңнегулов аларның төркеменең кураторы булган. «Ул елларда Хатыйп абый безгә, авылдан шәһәргә килгән таянычсыз яшьләргә, икенче эти булды. Безгә өлкән булып күренсә дә, аның үзенә дә ул елларда 37 яшь кенә булган. Ул безне биш ел буена күпмедер дәрәҗәдә тәртәдә тотып, укытып чыгарды. Аның дусты Рәдиф Гаташ мине, кулдан диярлек өстерәп, иҗатка алып керде. Аларга бик рәхмәтлемен», – диде Г.Морат.

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, Казан федераль университет профессоры Тәлгат Галиуллин Х.Миңнегуловны укытуын искә төшерде.

Хатыйп Миңнегулов 1959 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегенә студент итеп кабул ителә. «Хатыйп Миңнегуловның – олуг галим, Рәдиф Гаташның зур шагыйрь булып ирешүенең сәбәпчесе – мин. Алар – минем укучылар», – диде ярым шаярып Тәлгат ага. 1960 елда академик М.Зәкиев Т.Галиуллиннан татар теле кафедрасында укытырга калуын сорый. Яшь педагог өченче курсның үзеннән әз генә кече студентларга лекция укый башлый.

Язучы һәм тәрҗемәче Фатих Кутлу Х.Миңнегуловның кешелеклек ягына игътибарны юнәлтте. Ул аның һәр кешегә, гамәлгә игътибарлы булуы турында сөйләде. Татар язучыларының төрек теленә тәрҗемә ителгән әсәрләреннән җыентык әзерлибез, дигән хәбәр килеп ирешкәч, Ф.Кутлу иң әүвәл Хатыйп абыйга мөрәҗәгать иткән. Ул Фатих Хөсни, Шәриф Камал, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗевнең әсәрләре кергән исемлек төзеп биргән. «Татар язучылары әсәрләре тәрҗемә ителгән саен, Хатыйп абый күңелләрне күтәреп торды. Бик тә кешелекле шәхес», – диде Фатих бәй.

Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ белән Х.Миңнегулов 62 ел иңгә-иң торып яшәгән. «Ул студент чагыннан ук галим иде. Мин аңа шигырьләр өйрәтәм, ә ул мине фән, борынгы татар әдәбияты, Көнчыгыш шигърияте белән тәрбияләде», – диде ул. Шагыйрь үз иҗатының һәр яңа тәлгәше белән дустын таныштырып бара торган булган, туры сүзле Хатыйп ага дустының тәнкыйтьчесе дә, мактап күңелен күтәрүчесе дә булган, иҗаты турында бик күп мәкаләләр язган.

Тарих институтының М.Госманов исемендәге Алтын Урда һәм татар ханлыкларын өйрәнү үзәге җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Илнур Миргалиев Х.Миңнегуловның Алтын Урда чорында яшәп иҗат иткән Сәйф Сараи буенча иң киң мәгълүматлы һәм зур хезмәтләр язган галим булуын белдерде. «Урта гасыр әдәбиятында аерым урын алып торган шәхес – Сәйф Сараи бар. Тарих институтында без аны актив өйрәнәбез. Ул Туктамыш ханның илчесе булган, Мисырга киткән, кабере дә шунда. Күп кенә галимнәрнең фикерләренә таянып, аның туган ягы Самара өлкәсе Камышлы авылында дигән фикергә килдек, шул якта Сәйф Сараи укуларын уздыра башладык. Бу эшләрне башлап йөргәндә Хатыйп абыйның хезмәтләре булышты», – диде ул.

Галимнәрнең Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәре буенча спектакль әзерләп куярга да ниятләре бар икән. Профессор, җырчы Идрис Газиевның та бу эшкә алынырга теләге бар. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәре күләмле булмаса да, анда милләтпәрвәрлек, ватанга мәхәббәт хисләре көчле бирелә, фидакярлек тә бар. Уй-ниятләребез тормышка ашар», – диде И.Миргалиев. Ул шулай ук Хатыйп аганың тынгысыз галим булуын да ассызыклады. Яшь аралары зур булса да, аның белән һәрдаим аралашып торулары, көндәлек матбугатта чыккан кызыклы язмаларны укып, күзәтеп баруы турында сөйләде.

Гомере буе студентларга борынгы әдәбиятыбыз турында лекцияләр укыган, яшьләребезгә үз фәнен яраттырган Хатыйп ага Мәгарифне үстерү институтында укытучыларны тәрбияләү, аларга белем бирү өчен дә вакыт тапкан, ул җәмәгать эшләрендә дә һәрвакыт актив булган. «Заманалар үзгәргән саен, дәүләт алып барган сәясәт тә бер төсле генә тормады. Әмма мөнәсәбәтләр үзгәрешсез булды, Хатыйп абый тиешле югарылыкта укытуын дәвам итте. Бүген татар теле һәм әдәбияты укытучылары әдәбият фәнен тирәнтен белеп укыталар икән, бу – Хатыйп аганың хезмәте нәтиҗәсе», – диде Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгының эксперт советы әгъзасы, доцент Рәсимә Шәмсетдинова.

Татар әдәбияте галиме, филология фәннәре докторы Х.Миңнегуловка багышланган конференцияләрнең 11 нче татар гимназиясендә узуының үз сере бар. Галим биредә 21 ел дәвамында фәнни консультант булып тора. Дәрвишләр бистәсендәге бу гимназиягә нигез салынган вакытта Хатыйп ага фәнни җитәкче буларак балаларны шушы уку йортына чакыруда, милли мәктәпне таныту юнәлешендә дә күп өлеш керткән. Уку йорты галимебезгә дә игътибарын кызганмый.

Филология фәннәре кандидаты Рәҗәп Бәдретдинов остазының тирән белем бирүе, таләпчәнлеге белән бергә, шәхси үрнәге белән дә тәрбияләвен искәртте. Быел 11 нче татар гимназиясенең бер бүлмәсендә профессор Х.Миңнегуловның музее эшли башлады. Биредә аның шәхси әйберләрен – кульъязмаларын, эш өстәлен, язу машинкасын, шкатулкасын фотоларын, шахмат уйнау кирәк-яракларын, сәгатен, дипломнарын күреп була. Хатыйп ага музейга үзе өчен аеруча кадерле ядкәрләрне дә бүләк иткән. Әйтик, әнисенең кулдан тукыган кызыл сөлгеләре, яулыгы, орчыгы, самовары, туй сөлгесе, фоторәсемнәре – шундыйлардан. Хатыйп аганың һәм университет фотолары төшерелгән бокал исә – студентлар истәлеге. Аны алар укытучыларына 2010 елда бүләк иткән. Анда «Сагынырсыз әле сез дә бер», – дип язылган.

Әлбәттә, бу сүзләрдә хаклык бар. Чөнки галимнең яртысы гасырдан артык гомер юлы Казан университеты белән бәйле. «Олуг уку йорты минем өчен һәрвакыт иң кадерле урын һәм дәрәҗә булды, иң мөһиме – студентларга белем, тәрбия бирү иде, яшьләребезгә һәрчак шәхес итеп карадым. Аларны, тел, әдәбият белгечләре итеп кенә түгел, милләт өчен җан атучы кешеләр итеп тәрбияләргә тырыштым. Бүген алар белән горурланабыз», – диде Х.Миңнегулов.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Мәдәни җомга
28 апрель
№16, 2023

Милли киемгә мөкиббән рәссам

Әдәби иҗат чын сәләт таләп итә. Әйтик, барыбызның да диярлек «Унесённые ветром» кинофильмын караганы бар. Роман авторы – М.Митчелл иң әүвәл әлеге әсәренең соңгы бүлеге өчен төп җөмләләрне язып куйган, шуннан соң тугыз елга якын әлеге бердәнбер әсәренең калган бар текстын иҗат иткән, өстәвенә, үз-үзенә тәнкыйть күзлегеннән караучы ханымның күңеле романның беренче бүлеген алтмыш тапкыр төзәтеп күчерергә кенә тынычланган... Менә шушындый тырышлык үрнәкләре хакында укыгач, җитди китапларның җиңел язылмавын аңлыйсың. Тик тиздән язучылык белән шөгыльләнмәгән кешеләр дә «әсәр» тудыра алсын өчен, үзенчәлекле китап булыр төсле. Мондый китапны рәссам Әнвәр Сәйфетдинов нәшер итергә ниятли.



«Кеше әлеге китапка кертелгән берникадәр иллюстрацияләремә карап, андагы сызыклы буш битләргә үзе уйлап чыгарган берәр сюжеттагы тарихны яки мавыктыргыч әкиятне яза алачак. Бу очракта инде кем нинди фантазия куәтенә ия... Һәр язма китап үзенә бер төр эчтәлектә генә булуы белән дә аерылып торачак», – ди Әнвәр Камил улы. Бу үзенчәлекле китап әлегә эшләнеп кенә килә, шуңа күрә рәссамнан башка иҗади планнары хакында белешәм. «Минем гомер бәйрәмем якынлаша. Шуңа күрә быел Казан Кремле музей-тыюлыгында урнашкан Татарстан дәүләтчелеге тарихы музеенда шәхси күргәзмәмне ачарга җыенам. Иҗатымны халыкка күрсәтеп, кешеләрнең күңелләрен сөендерәсем килә. Шушы язгы күргәзмәмә әзерләнә башлап, бу араларда борынгы милли киемдәге хатын-кыз образларын иҗат итәм. Моннан берничә ел элек әниемнең портретын язган идем, аны да күргәзмә түренә эләчәкмен. Минем бар иҗади уңышларымда да әниемнең өлеше зур. Әнием беренче булып: «Син үскәч, рәссам буласың!» – диде, минем ничек укуым белән гел кызыксынып торды, гел иҗади биеклектә булуымны теләде, аннары яңа күргәзмәләрем тантаналарының берсен дә калдырмады. Кызганыч, ул инде вафат...

Тәүге картиналарымны искә алганда, 1994 елда иҗат ителгән «Татар кәләше» картинам бар, аны күпләр хәтерли булыр. Озак еллардан соң шушы картинам өчен модель булган Сәидәне урамда очраттым. Ул бер дә үзгәрмәгән, шундый ук нурлы йөзле, шат күңелле, искиткеч мөлаем! Минем өчен модельнең рухи матурлыгы булуы да мөһим.

Соңгы сулышыма кадәр милли киемле туташ-ханымнарны сурәткә төшерүемне дәвам итәчәкмен, әмма иҗатым алга барсын өчен, миңа милли кием үрнәкләре җитми. Менә шушы арада танылган татар рәссамнарның берсе чигешле алъяпкыч биреп торды, моңа шулкадәр сөендем, аны юып, үтүкләп үк куйдым инде. Образны каршымда торган модельгә карап кына ясарга күнеккән рәссам мин. Тик бу көннәрдә борынгы татар милли костюмнарыбызны каян алырга белмичә кәефем төшә... Аңлашыла ки, дәүләт музейлары мондый экспонатларны рәссамнарга бирә алмый. Һичьюгы, модель аларны берникадәр вакытка гына киеп торса, фотосурәт итеп тә төшереп алыр идем. Моннан күп еллар элек Татарстан Милли музее директоры Г.С.Муханов, башка милләт кешесе булса да, андый гозеремне кире какмаган иде. Ул чакта татар костюмнарын яхшырак өйрәнеп калдым, иҗатчыга күп төрле милли киемнәрне күрү бик мөһим, бу даими, динамик процесс булырга тиеш... Аннары тирә-юнемдәге үз тамашачыларым белән әңгәмәләр дә кормыйча калмыйм, аларның сәнгатемә нинди караштa, нинди бәяләмәдә булулары белән кызыксынам. Ә инде остаханәдә эшләгәндә тынлык урнаша. Бу бик мөһим. Киндерләргә майлы буяулар белән сурәт төшергәндә, һәр иҗатчы яңа әсәрен, үз уй-кичерешләре аша гына үткәреп, сакраль тынлыкта гына тудыра ала.

Татар мәдәнияте темасы һәрвакыт иҗатымның үзәгендә. Әлбәттә, башка хезмәтләрем дә бар һәм булачак та, аларда Идел буенда яшәүче дус һәм тугандаш халыкларның милли киемнәрендәге хатын-кызлар сурәтләнә, аннары бу эшләрнең барсын бергә бер серия итеп туплаячакмын.

Мин өч телдә нәшер ителгән «Әнвәр әлифбасы» китабым аша ана телебезне пропагандалавымны да дәвам итәм, әйтик, былтыр Казан (Идел буе) федераль университеты каршындагы Н.И.Лобачевский исемендәге лицей укучылары һәм Казанның башка урта мәктәп балалары белән очрашулар үткәрдем, бу эшчәнлегемне быел да туктатмыйм, татар теле һәм әдәбияты, рәсем дәресе укытучылары бу нисбәттән миңа мөрәҗәгать итә ала».

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 28.04.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2615

16+